# Ягъсуф Шәфыйков
# КАЛАЛАРДА ТАШ КАЗАРМА…

Повестьлар, хикәяләр, юмористик хикәяләр

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2004

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Ш 29

**Шәфыйков Ягъсуф**

Калаларда таш казарма...: Повестьлар, хикәяләр, юмористик хикәяләр.— Казан: Татар.кит.нәшр., 2004.— 207 бит.

Танылган публицист Ягъсуф Шәфыйков дистәгә якын китап авторы. Бу китапка тупланган әсәрләрдәге һәр вакыйганы диярлек үз башыннан кичергәнгә күрә, язучы тормышны белеп яза, укучыны үзе белән ияртеп бара.

ISBN 5–298–01376–7
© Татарстан китап нәшрияты, 2004

Кадерле әнием, дустым һәм
киңәшчем Мөнирә Хуҗахмәт кызының
якты истәлегенә багышлыйм.
*Автор*

Чынындамы-чынында, дүрт гасырлык золым-җәбер кичергән татар халкы өчен XX йөз башы һәм шул йөзьеллыкның соңгы ун-унбиш елы Бөек Уяну чоры булды. Боз кузгалды. Татар баласы күзенә нур кунды. Ул үзенең изелгән милләт вәкиле булуыннан оялмыйча, мәйданнарга чыгып, парламентлар мөнбәренә күтәрелеп: «Әйе, мин — Татар!» — дип, горурланып әйтергә өйрәнде. Саный китсәң, сөенеп-шатланып әйтерлек мондый уңай үзгәрешләр бихисап. Иң әүвәле туган телебезгә игътибар, аңа булган ихтирам вә мәхәббәт хисе бермә-бер артты. Шушы якты үзгәрешләр җиле, рухи дөньябыз капкасын иркен-киң ачып, күпме шәхесләрне, күпме исемнәрне ил-көнгә танытты.

Әлеге гүзәл исемнәр дисбесендә нәкъ менә шушы ун-унбиш ел дәвамында аеруча бер дәрт белән рухланып-канатланып иҗат иткән йөгерек вә үткен телле каләм әһеле, танылган журналист һәм язучы Ягъсуф ага Шәфыйковның да исеме бар.

Кадерле укучым! Менә бүген син кулыңа алган шушы күркәм китап аның каләме белән язылган. Моннан ике ел чамасы элек кенә миңа, әйе, минем өчен бөтенләй таныш булмаган әлеге авторның Дон казакларына багышланган күләмле язмасын тәрҗемә итәргә туры килде. Сүз уңаеннан шуны да әйтим әле: узган гасырның бөек әдибе Михаил Шолохов зурлап язган «Тын Дон» романы каһарманнары тарихи чыгышлары белән безнең халыкка да бәйле икән ләбаса. Дон дигәнебез нәкъ безнеңчә Тын елгасы икән, ә казаклар атамасы ерак болгар бабаларыбыз чорыннан калган качаклар сүзеннән алынган. Шул рәвешчә, мин Ягъсуф Шәфыйковның тарих белән тирәнтен кызыксынучы, киң колачлы һәм гаять гыйлемле каләм әһеле булуына инандым.

Ул — бүгенге көндә күпне күргән, күпне кичергән халкыбыз язмышы һәм тарихы турында, бүгенге чордашларыбыз хакында бик тә мавыктыргыч итеп язылган бер дистә китап авторы. Укучы үзенчәлекле, хәер, курыкмыйча әйтү фарыздыр, талантлы бу язучының китапларын үз итеп өлгерде. Бүгенге көн күзлегеннән караганда, шактый зур тираж белән чыккан бу китаплар кибет шүрлекләрендә тузан җыеп ятмый.

Ягъсуф Шәфыйковны хаклы рәвештә Ибраһим Нуруллин белән Рашат Низамиевтан соң әдәбиятыбызда «Атаклы кешеләр тормышы» турында язылган китаплар сериясен

уңышлы дәвам иттерүче дип әйтергә кирәктер. Әйе, аның тарафыннан халкыбызның хәзергәчә игътибар үзәгеннән читтәрәк калган байтак каһарманнары хакында саллы җыентыклар иҗат ителде. Мәсәлән, әдипнең Бөек Ватан сугышы батыры, 1945 елның маенда беренче булып Рейхстагка Җиңү байрагы элгән милләттәшебез Гази Заһитов, шулай ук ике бертуган олуг шәхес — генерал-полковник Рәсим белән мәшһүр кардиохирург Ренат Акчуриннар турындагы, шулай ук 49 көн буена бер тәгам ризыксыз, идарә ителми торган катерларында рәхимсез Тын океан дулкыннарында өч иптәше белән бергә йөзгән һәм язмыш алдында сыгылып төшмәгән кыю диңгезче Әсхәт Җиһаншин хакындагы язмаларын дулкынланмыйча уку мөмкин түгел.

Авторның Илбашы Минтимер Шәймиев белән якыннан аралашып, халык һәм җир язмышы хакында иҗат ителгән күләмле фәлсәфи-гыйльми язмасы укучы күңелендә матур хисләр уята. Шундый ук фикерне ТР Фәннәр академиясе президенты, күренекле галим һәм җәмәгать эшлеклесе Мансур Хәсәнов турындагы повестена карата да әйтәсе килә. Бу китапта автор төп игътибарны татар халкының уяну чорына, аның озак гасырлар буена дәвам иткән көрәшенә юнәлтә һәм, әлбәттә, М.Хәсәновның милләт хакына башкарылган күпкырлы, игелекле хезмәтләрен укучы күңеленә җиткерә.

Әйе, язучының иҗат офыгы киң. Бер караганда, XIX йөздә Дагыстанда яшәгән һәм патшага каршы көрәшкә күтәрелгән имам Шамилне бернәрсә дә татар дөньясы белән бәйләми кебек. Баксаң, андый бәйләнешләр шактый күп икән. Ягъсуф Шәфыйков, шушы бөек шәхеснең тормышын тирәнтен өйрәнеп, Шамил варислары һәм оныкларының безгә бәйле күп якларын ача. Алар Казанда хезмәт иткәннәр һәм гомер кичергәннәр, алай гына да түгел, татар кызларына өйләнеп, туганлык җепләрен өзелмәслек итеп бәйләгәннәр.

Автор иҗатында мондый мисалларны күпләп китерергә була. Әйтик, Мәскәү мэры Юрий Лужков белән Санкт-Петербургтагы Эрмитаж директоры, исеме бөтен дөньяга билгеле Михаил Пиотровскийның да татар халкына нинди якынлыклары бар соң дип уйларга мөмкин. Әмма әлеге ике очракта да Ягъсуф ага үзенә тугры булып кала: эзләнә, таба һәм исбатлый. Беренче очракта ул Мәскәүдә гомер кичергән татарлар тарихын җентекләп өйрәнә, шул ук вакытта безнең милләттәшләребезгә карата Лужков тарафыннан әйтелгән бик күп фикер һәм бәяләмәләрне куллана. Нәтиҗәдә чор сулышы белән сугарылган гаҗәеп үзенчәлекле әсәр иҗат итә.

Икенче очракта исә әлеге публицистик әсәр туу тарихы тагын да кызыклырак. Мәгълүм булганча, совет чорында әйтергә дә ярамаган бер зур теманы күтәреп чыга, беренчеләрдән булып изге Коръәнебез хакында «Мин бер могҗиза беләм...» дигән исем белән рус һәм татар телләрендә искитмәле җыентык бастырып чыгара. Хикмәти Ходa! Тагын биш елдан соң аның Коръән хакында шундый зур хезмәте барлыгын белмичә һәм аның белән танышмыйча, академик, Шәрекъ дөньясы белгече М.Б.Пиотровский да мөселманнарның изге китабы турында зур хезмәт яза. Ә соңыннан шушы ике шәхес бергә күрешкәч, Михаил Борисович каләмдәше әсәренә югары бәя бирә, ул язган китапның укучы өчен күпкә аңлаешлырак һәм үтемлерәк булуын әйтә. Әнә шулай алар якынаеп-дуслашып китәләр. Ә инде Төньяк башкаланың 300 еллык бәйрәме алдыннан Ягъсуф Шәфыйков, махсус рәвештә Эрмитажга барып, андагы бихисап рухи байлыкларны өйрәнә. Сөземтәсен әйтәсе дә юк, ул бик тә уңышлы-уңдырышлы килеп чыга. Автор моңарчы безгә аз билгеле булган Алтын Урда чоры, хәер, аннан да элгәрерәк Кубрат хан идарә иткән дәвер хакында чын мәгънәсендә тирән эчтәлекле популяр-гыйльми хезмәт яза.

Академик М.Б.Пиотровский үзе дә безнең милләтне бик нык хөрмәт итә, хәтта сөйләшкәндә: «Мин татар җанлы кеше»,— дип әйтергә ярата. Шушы игелекле зат безнең Илбашыбыз М.Шәймиев белән якын мөнәсәбәттә булып һәм аның турыдан-туры булышлыгы белән башкалабыз Казанда Эрмитаж фондларында сакланып килгән экспонатлардан Кубрат хан дәвере, Алтын Урда чоры, гомумән, Шәрекъ дөньясы турында сөйләүче, бәяләп бетергесез хәзинәләрдән торган берничә күргәзмә оештырды. Әнә шулай итеп, аерым кешеләр дә, алардан бигрәк гомер буе күрше булып яшәгән халыклар бер-берләренә якыная-лар. Безнең тарихи бергәлек әнә шул ерак заманнардан ук килә. Шушы гүзәл миссиядә

үзеңнең дә бер тамчы өлешең булуын күрү сөенеч түгелмени?! Әлбәттә, нәкъ шулай. Моны мин әдипнең бер бәхете дияр идем.

Россия Язучылар берлеге әгъзасы Ягъсуф Шәфыйковның күпчелек әсәрләре тормыштан алып язылган, аларга публицистик рух һәм документальлек хас. «Калаларда таш казарма...» дип аталган әлеге китап та башлыча чын хәлләргә, документаль вакыйгаларга нигезләнеп язылган. Шуңа да китапның ышандыру көче искитмәле зур. Бүгенге чорда исә укучыларны нәкъ шундый рухтагы, шундый эчтәлекле китаплар кызыксындыра.

Шунлыктан минем үземнең дә әдиптән: «Ни өчен Сез күбрәк тарихи вакыйгалар, алай гына да түгел, халык өчен фаҗигале хәлләр турында язарга яратасыз?» — дип сораган чакларым булмады түгел, байтак булды.

— Һай, энем,— диде ул миңа,— безнең яшьлек бик авыр, канлы чорларга туры килде. Язганнарымның күбесе үз башымнан узды. Күпме чордашларымны вакытыннан элек югалттым. Бу чәчләрем дә тикмәгә генә агармагандыр. Ә кулыма каләм алуымның бер сәбәбе шунда: хәзерге яшь буын безнең дәвер хаталарын кабатламасын иде. Мин әлеге китабым белән яшьләргә шушы фикерне җиткерәсем килә. Әйе, мин бу юлы да китабымны документларга нигезләнеп яздым. Күз алдына китерәсеңме? Безнең XX гасыр бәхеттән бигрәк кайгыны күбрәк китерде. Элеккеге СССРда тулы бәхет белән яшәгән гаилә булдымы икән? Юктыр! Кемнәрдер яу кырында башын салды, кемнәрдер бер гаепсезгә төрмәләргә озатылды, кемнәрдер шуның өчен гомер буе җәфа чикте. Мәгърифәтле вә мәдәниятле Көнбатыш илләрендә Россияне күп гасырлар дәвамында халыклар төрмәсе булды дип тикмәгә генә язмыйлардыр. Шуңа да мин бу китабымда үз башымнан кичкән хәлләрне, халкым йөрәге аша узган фаҗигале вакыйгаларны тасвир кылдым...

Автор миңа әнә шулай ачынып сөйләде. Хәер, укучым, син үзең дә «Калаларда таш казарма...» повестен укып чыккач, моны йөрәгең аша уздырып: «Йа Раббым, мондый хәлләрне безгә кичерергә язмасын!» — диярсең. Хәер, китапта адәм балаларының яшәеше-көнкүрешенә, әхлакка һәм вөҗданга кагылышлы хикәяләр, публицистик язмалар һәм үткен телле юмористик хикәяләр дә урын алган...

Чыннан да язучы күзе күпне күрә, барысы да аның күңел дәфтәрендә языла бара. Мөгаен ул, үзенең «Хуш, Агыйдел» повестенда тасвир кылганча, туган ягы — Агыйдел буендагы Актаныш районында бик күп татар авылларының, Түбән Кама гидроэлектростанциясе төзелгәч, бөтенләйгә һәм мәңгелеккә су астында калуларын күреп сызлангандыр, шуңа да кулына каләм алгандыр.

Хәер, ни генә булмасын, әдипнең үз чордашларына әйтер сүзе бар.

— Җиребезне, туган телебезне, тарихыбызны уяу саклыйк! — ди ул.

Хәзерге вакытта без Ягъсуф әфәнде белән республикабызның визит карточкасы булып саналган «Татарстан» журналында бергә эшлибез. Мине аның кайнап-ташып торган көчкодрәте, энциклопедик гыйлеме һәм, әлбәттә, язу осталыгы сокландыра.

Автор һәрвакыт юлда. Командировкалардан кайтып керми. Шул юлларда аны язылачак яңадан-яңа әсәрләренең каһарманнары көтеп тора.

Әнә шуңа күрә дә мин бу асыл узаман егетнең юллары гел уң, каләменең һәрчак йөгерек булуын телим!

*Госман Садә*

## *Хуш, Агыйдел!*

### *Беренче бүлек*

Уттан кала, судан калмый.
*(Халык әйтеме)*

Агыйделнең, гадәттә, һәрвакыт буш була торган уң як ярында искергән солдат бушлаты, кирза итекләр һәм колакларын артка яткызып бәйләгән бүрек кигән кешене Рамил белән Мирсәет ничектер шәйләми тордылар. Кармак белән балык тотканда тирә-юньдәгеләргә кем игътибар итсен инде. Туендыручы елганың салкын суында тирбәнүче кызыл калкавычларда иде аларның игътибары. Ниндидер

бер эт тәфкелдәп куйгач кына, алар карашларын каршы як ярга төбәделәр һәм елга кырыендагы чуерташлы ком өстеннән арлы-бирле йөрүче кешене күрделәр. Аның бөкрәя төшкән гәүдәсенә, аяк басуларының бик үк нык булмавына караганда, ул кешегә җитмеш-җитмеш биш, ә бәлки артыграк та бирергә мөмкин булыр иде. Карт белән янәшә, ялагайланып, аның аякларына сыйпана-сыйпана һәм койрыгын бертуктаусыз болгый-болгый, матур гына себер лайкасы бара. Вакыт-вакыт өргәләп куя.

Көз ахырында Агыйделнең теге як ярында кешенең күренүе балыкчыларны нык гаҗәпкә калдырды. Бүген-иртәгә елга тулып сил* килә башлаячак. Бу инде җәйнең кояшлы көннәре кире борылып кайтмаячак, күңелсез көз үзенең хокукларын кышка бирә дигән сүз иде. Биредә, Агыйделнең түбәнге агымында, аның Камага койган җирендә соңгы елларда җәен дә кеше бик сирәк күренгәли иде. Ә монда, мә сиңа! Елга шушы көннәрдә йокыга талырга тора, ә бер акылдан язганы, этен ияртеп, елга буйлап йөренә.

Чаллыда Кама аша плотина төзегәннән һәм Түбән Кама ГЭСы корылмаларын сафка керткәннән соң, су беренче билгеләмәгә — 62 метрга күтәрелде. Шулай итеп, Агыйделнең түбәнге өлеше күз иңләмәс киң дәрья булып җәелде. Күп кенә күлләр, күллекләр, Агыйделнең борынгы юлы тоташ су белән капланды. Суы күптәннән кипшенергә һәм өсте үләннәр келәме белән ябылырга өлгергән ерганакларга бәреп керде.

Зур су килгәнчегә кадәр монда меңәрләгән гектарларда тирә-юньгә хуш ис таратып торган болыннар җәйрәп ята иде. Бөдрәләнеп-бөдрәләнеп куаклыклар үсә иде. Мондагы шомыртны, баланны, гөлҗимешне җыеп бетерерлек түгел иде.

Сугыштан соңгы ачлык елларда Актанышның кыр як авыллары халкы, әнә шушы су баса торган болыннарга килеп, капчыгы-капчыгы белән юа җыеп китәләр иде. Аннан аш пешерәләр. Пешермичә ашарга да бик тәмле иде ул. Болынның бөтен тәмен үзенә туплаган бу гүзәл үләнне рәхәтләнеп чәйнисең-чәйнисең дә, хозурланып, саф һава сулап куясың.

Җәй ахырында йөзләгән кеше шомырт, балан, гөлҗимеш уңышы җыя иде. Бу тирәләрдә шомыртның аерым төре үсә. Ул эре һәм сусыл. Бәяләп бетергесез бу җимешләрне күпләп җыеп киптерәләр. Ә кышкы кичләрдә үзләре ясаган кул тегермәннәрендә — ярма ташында тарттыралар иде. Кышын аның оныннан кесәл пешерәләр. Бәрәңге, алабута кушып пешерелгән көлчәгә дә өстәп җибәрәләр иде.

Баланны сил алдыннан, аның кызыл тәлгәшләренә төнге салкыннар тия башлагач, җыялар.

Бу болыннардан җыелган печәннәрнең исәбе-хисабы юк иде. Балан, шомырт һәм гөлҗимеш плантацияләре арасында, ниндидер бер әкияти проспектны хәтерләтеп, кибәннәр тезелеп киткән була иде. Кыш җиткәч, әле кар бик үк тирән булмаганда, печәнне чанага җигелгән атлар белән колхоз фермаларына ташыйлар. Агыйделнең түбәнге өлешендә, Өшәр авылы янында, Татар Әҗбие, Урдалы авылларыннан арырак Кама буйларында, үзенең искитмәле тарихы булган Көләгеш күле тирәсендәге болыннарда зур мәйдан биләп торган Актаныш районының барлык колхозлары һәм совхозлары да үзләренең печән биләмәләренә ияләр иде.

Язгы чәчү төгәлләнеп, Сабантуйларын күңелле генә уздырып, туган-тумачаларны, авылдашларны Сарапул, Ижау, Пермь, Кизел шәһәрләренә, шулай ук ерак Кузбасс һәм Донбасс якларына озаткач, авылларның хезмәткә яраклы барлык кешеләре Агыйдел, Кама болыннарына печәнгә ашыгалар иде. Эш барышында бергәләшеп яшәү өчен яңа гына чабылган хуш исле печәннән зур-зур шалашлар ясыйлар. Алар үзләре бер авылны хәтерләтеп торалар иде. Мондый «өйләрдә» ничек ял ителүе, нинди төшләр керүе хакында шундый әкияти шалашта үз гомерендә бер тапкыр гына булса да кунган кеше генә сөйли ала. Дөрес, кичләрен озынборыннар кирәкне бирә бирүен.

Кама, Агыйдел буйларындагы болыннарны чалгы белән үлчәп чykканнан соң, яр буена утырып, колхозчылар зур-зур учаклар ягалар. Төтенле булсын өчен анда ара-тирә яшел ботаклар ташлыйлар иде.

Тормыш хәлләре турында сөйләшкән арада, Дербешка пристаненнан, Агыйдел белән Кама кушылган җирдә судноларга ягулык салу станциясе ягыннан килгән пароход гудокларына колак салгалыйлар. Көпчәк калагы белән суга шап-шоп бәргәләп, үзе артыннан дәү-дәү баржалар, Каманың югары очында әзерләнгән салларны сөйрәп буксир пароходлары үткәли. Бу минутларда печән чабучылар тын гына утыралар. Пароходның көпчәк калагы тавышы ишетелми башлагач кына, тагын сүз башлап җибәрәләр.

Кайбер көннәрдә печән чабучыларның шушы сәер «авыл» яныннан палубаларында ут тәлгәшләрен җемелдәтеп, борынындагы ресторанының матурлыгын, ян-як палубалары буйлап ял итеп йөрүче пассажирларын күрсәтеп, шуның белән бик күпләрне кызыксындырып, пассажир пароходы да үткәли иде. Бу минутларда барысының да күзе кичке караңгылыкта аккошка охшап баручы шушы могҗизага төбәлгән була. Кайберләре тирән итеп сулап куя. Мөгаен, үзләрен шуның пассажирлары итеп хис итәләрдер һәм каядыр еракларга баралар кебек сизәләрдер...

Әле күптән түгел генә, утыз еллар элек кенә, Агыйделдән пароходлар Казанга, Мәскәүгә, Пермьгә йөриләр иде.

Йокларга ятар алдыннан печән чабучылар, таяк башына коры үлән бәйләп, факел кабызалар. Ул кичнең кизләүчеләре, ут төртеп йөрүчеләр сымак, шул факеллар төтене белән, һәр шалашка кереп,

озынборыннарны куып чыгаралар. Шуннан соң яңа чабылган хуш исле печән өстенә яталар. Үләннең төтен катыш хуш исе озак вакытлар борынны кытыклап тора.

Печәнне кибәннәргә куйганнан соң, авыл кешесенең уракка кадәр бер-ике атна вакыты кала. Бу вакытны ул киләсе кыш өчен утын әзерләүгә файдалана.

Агыйделнең түбәнге өлешендә бу якларга гына хас аерым бер төр тал үсә. Ул юан һәм озын була, катылыгы ягыннан имәннән бер дә калышмый. Кыска гына итеп әйткәндә, менә дигән утынлык ул. Өстәвенә әле ул кискәннән соң да бик тиз үсеп китә. Төп кәүсәне кисеп алганнан соң, ян-як ботаклары, шунда ук хәл алып, юанаеп, тиз генә матурлана. Бер-ике елдан алар инде элекке хәленә кайткан булалар. Монда яшәүче татарлар гомер-гомергә аның тагын бер үзлегеннән файдаланганнар: төрле-төрле кәрҗиннәр үргәннәр. Сатар өчен дә, үзләре өчен дә. Аларның нindиләре генә булмаган: кырга тирес төяп чыгара торганнары да, каз бәбкәләрен сала торганнары да. Җиләк җыю, хуҗалыкта вак эшләрдә куллану өчен эшләнгәннәре бигрәк тә матур булган. Бөтен көньяк Удмуртия — Сарапулдан алып Ижауга кадәр халык һөнәрчеләрнең шушы әйберләреннән файдаланган. Гомумән, ул авыл халкы өчен төзелеш материалы да булган. Талдан үрелгән читән белән өй тирәләрен тотып алганнар, ике кат читән үреп һәм арасына салам тутырып, маллар өчен менә дигән абзарлар корганнар. Сыерлар, сарыклар, кәҗәләр һәм казлар өчен моннан да җылы торакларны табуы кыен булган. Нинди генә чатнама суыкларда да маллар туңмаганнар.

Әйе, үзенең матурлыгы белән чагыштыргысыз як бу. Хозурлыгы белән ул кешеләрнең күңелен күтәреп кенә калмаган, гасырлар буена аларны туендырган да. Җирендә үскән җиләк-җимешләреннән тыш, аның сулары — Агыйделе, Камасы, санап бетергесез күлләре төрле-төрле балыкларга гаять бай булган. Нәкъ менә шушы якларда патша балыгы дигән чөгә балыгын тотканнар һәм кышын, чаналарга төяп, удмуртларның Каракүл һәм татарларның Красный Борыннан тере килеш Петербургка озатканнар. Патша өстәленә җиткәнче тәмен югалтмасын өчен, мичкәләрендәге суны алыштырып торганнар.

Агыйделнең Камага коя торган урынында чөгә балыклары әле дә байтак. Корбан балыклары, сазан балыклары турында сөйлисе дә юк — алар белән бөтен елгалар тулган. Бу тирәләрдә җәен-кышын Чаллыдан, Ижаудан, Сарапулдан, Уфадан килгән балыкчыларны очрату гадәти хәл.

Күпчелек авыллар, күлләр, елгалар биредә нинди дә булса балык исемен йөртәләр. Мәсәлән, Сарапул шәһәренең исеме борынгы Болгарда сары балык, ягъни хәзер бик күпләп тотыла торган чөгә балыгын аңлаткан. Каракүл, ягъни Каракулино — Удмурт Республикасы район үзәге — кара күл дигәнне аңлата. Чыннан да, бу район үзәге янында, Каманың икенче ягында, Притыкино авылы янында, зур гына бер күл бар. Ул бик карачкыл төстә. Хәтта кояшлы көнне дә ул күгелҗем-кара булып күренә.

Шунысын да әйтергә кирәк, Кама-Идел Болгариясе барлыкка килгәндә, бу якларда, дөресрәге, Кама белән Агыйдел арасындагы өчпочмакта, зур Көләгеш күле ярларында болгарлар белән бергә угро-фин халыклары вәкилләре — марилар да яшәгән. Көчле Мадьяр мәдәнияте туа һәм ул өч йөз ел яши. Соңрак, унынчы гасырда бу өчпочмакта яшәүче угро-фин халыклары вәкилләре һәм борынгы болгарлар Дунай ярларына күчеп китәләр, үзләре белән бергә Болгария халкының да бер өлешен ияртәләр (хәзерге Татарстанның көнбатыш өлешеннән). Алар хәзерге Венгриянең башкаласы Будапештка нигез салалар. Ул Дунайның бер ягында урнаша һәм Пешт дип атала, ә икенче як ярында соңрак Буду шәһәре барлыкка килә. Еллар үтү белән, Дунай ярлары, әкияттәге сымак, челтәрле күперләр белән тоташтырыла. Аларның матурлыгы Сена аша салынган Париж күпереннән һич тә ким түгел. Шулай итеп, ике шәһәр көчле мегаполис барлыкка китерә. Будапешт — хәзер Европада иң матур шәһәрләрнең берсе.

Болар турында әле бүген дә сокландырырлык итеп яшәп ятучы, бөтен матурлыкларын саклаган Мари Суксу авылы һәм Татар Суксуы хәтергә төшерде. Аларның бабалары ни өчендер зур бер төркем белән бергә Дунай ярларына күчеп китәргә теләмәгәннәр.

### *Икенче бүлек*

Агыйдел. Ак Идел. Син минем күңелемнең сагышы, син минем күңелемнең шатлыгы. Агыйдел — Татарстан Республикасының көнчыгыш чикләрендәге көмеш билбавы. Күпме еллар инде менә актанышлылар үзләренең туган якларына булган мәхәббәтләрен моңлы көйләргә салып җырларда җырлыйлар. Ул моңда сагыш та, шатлык та, сагыну да бар. Безгә, монда туып үскәннәргә, табигатьнең матурлыгы тагын да кадерлерәк. Бу якларга килеп чыккан атаклы кешеләр дә мондагы матурлыкка сокланмый түзә алмаганнар.

«Анда, Агыйделдә, урыннар шулкадәр матур ки, ах итәрсең... йөз тапкыр ах итәрсең!» — дип язган Максим Горький.

Агыйдел. Ак Идел. Минем ак сагышым. Минем күңелемнең ак юксынуы. Бу чибәребезнең исемен шундый шигъри юллар белән атаганда, без аңа карата шундый мәхәббәтнең каян килүе турында уйламыйбыз. Чыннан да, анда су кушылдыкларындагыга караганда яктырак, ачыграк. Бу бигрәк тә Агыйдел белән Кама кушылган җирдә ачык күренә. Һәр җәйне биредә, үземнең туган якларда булганда, шушы ике елганың матурлыгына, көченә сокланып туя алмыйм. Каманың кургаш суына кушылганнан соң да

ул, ак су бәйләме булып, ун чакрымнарга, бәлки, аннан да арыракка ыргыла. Үзенең чишмә башыннан алып Камага кадәр бу ак елга 1420 чакрым юл үтә. Түбәнге сазлыклы үзәнлектән башланып, Агыйдел көньяк Урал таулары каньонына ярәшеп, известнякларь, карбонатлар һәм доломитлар арасыннан үзенә юл ала, көчәйгәннән-көчәя барып, аларны үз юлыннан алып ыргыта, юа, суына кушып еракларга алып китә. Менә шушы тау токымының мирокисәкчекләре Агыйделне ак итәләр. Чыннан да, елга Башкортостанның башкаласы Уфага кадәр ак булып килә, аннары тау холкын баса төшә, сабырлана, як-як ярларында табигатьнең кабатланмас гүзәллеген тудырып, тыныч кына ага бирә.

Түбән Кама ГЭСы сусаклагычын күтәрү белән бәйле (әлегә 62 билгесенә кадәр) рәвештә килеп туган борчулы, трагик хәлләргә кадәр Агыйдел белән аның элек аккан юлы арасында зур бер утрау була. Өшәр дип аталган зур бер татар авылы да шунда урнашкан иде. Бу утрау үзенең тигезлеге, зурлыгы, печәнгә, балан, шомырт, гөлҗимеш агачларына байлыгы белән башкалардан аерылып тора. Ул Актаныш районының иң бай хуҗалыгына — Киров исемендәге совхозга карый. Кара туфраклы уңдырышлы җирләре белән данлыклы бу хуҗалык Актаныш районының көнбатышында, борынгы Сәфәр авылыннан ерак түгел, Башкортостан белән чиктәш Сөн елгасы ярына урнашкан. Утрау ермакланып беткәч, андагы күп кенә күлләр бергә кушылгач, кировлылар Агыйдел ярларыннан бераз читләштеләр. Соңгы вакытта болын печәне белән бик мавыкмыйлар, маллар өчен кукуруз, күпьеллык үләннәр үстерү буенча бик остарып киттеләр. Шулай итеп, аларның печәнлекләренең бер өлешен Актаныш районының далалы якларына урнашкан авыл кешеләре үзләштерә башладылар. Болыннарның күп өлешен район хакимнәре рөхсәте белән торба салучы нефтьчеләр алдылар. Аларның да менә дигән ярдәмче хуҗалыклары бар. Нефть торбалары салучыларны да ничек тә булса туендырырга кирәк бит.

Беренче суыклар башланганчы, кар төшкәнче дип, нефтьчеләр бик авырлык белән генә утрауга төягече, сәнәге, арбасы булган «Беларусь» тракторын китерделәр. Исәпләре кибәннәрне якынгарак, иске Агыйдел тирәсенәрәк күчереп, бер урынга өеп кую иде. Бу эшләрне башкаруны тракторчылар Рамил Әхмәтов белән Мирсәет Шакировка тапшырдылар. Алар тактадан ашык-пошык кына ясалган, туфрак белән күмелгән өйдә яшиләр иде. Ашарларына пешерү өчен мич-плитәләр дә бар. Аларның бу өй дигәннәре Чирәм Колак дип аталган элеккеге татар авылы урынына салынган иде. Кайчандыр ул зур гына авыл булган. Республиканың иң көнчыгышында, Татарстан белән Башкортостан чигендә бик матур бер утрауда урнашкан. Чиялек һәм Өшәр халкы да шул тирәдә көн күргән. Әнә тегендә, Агыйдел аръягында Башкортостан Республикасы. Сулдарак, Каманың теге ягында Удмуртия Республикасының Каракүл районы территориясе. Ә менә монда, Кама белән Агыйдел арасындагы өчпочмакта, Татарстан Республикасы.

Сугыштан соңгы елларда Чирәм Колак авылында кырыклап хуҗалык бар иде. Үзләрендә колхоз иде. Җидееллык мәктәпләре бар иде. Авылның бөтен ир-атлары да Бөек Ватан сугышыннан кайтмадылар дип әйтергә була. Ә аларның балалары, үсә төшкәч, бәхет эзләп, шәһәрләргә таралыштылар. Гомеребезне инде шунда төгәлләрбез дигән карт-корылар да ыруглары тормыш иткән әкияттәгедәй шушы гүзәл якны ташлап качарга мәҗбүр булдылар. Аларны Түбән Кама ГЭСы суы басып китә икән дигән коточкыч хәбәр куркытты.

Тракторчылар Рамил белән Мирсәетнең солярkalары бик тиз бетте. Мөгаен, беренче көннәрне, зур эшләр белән мәшгуль булып, китерергә вакыт тапмаганнардыр. Кем белә? Бәлки, алар эшләгән предприятиедә аларның барлыгын бөтенләй онытып җибәргәннәрдер. Механизаторларның ипи-сохари запаслары да бетте. Ярый әле печән чапканда, шаярыпмы, чынлапмы, утыртылган бәрәңгеләре, ашка дигән беркадәр ярмалары бар иде. Менә шулай итеп, алар зур утрауда Робинзон Крузо белән Җомга тормышын башлап җибәрделәр. Ярый әле үзләре белән кармаклар алганнар иде. Һәр көнне уха пешерделәр, балык кыздырдылар. Шунысына да бик шат булдылар. Бер атна дигәндә, ул да туйдыра башлады. Кыздырган балыкның исе генә дә укшытыр дәрәҗәгә җиткерә иде.

Солярканы һаман китермиләр. Хәзер бөтен өмет көннең суытып җибәрүендә. Менә елга боз белән капланыр да алар шома боз өстеннән Зур җиргә чыгарлар. Ләкин әле яшәргә кирәк иде. Телисеңме, теләмисеңме — Агыйделгә балык тотарга төшәсең.

Рамил андый-мондый кирәге чыкса дип, завхоздан иске бинокль алган иде. Менә хәзер ул аны сумкасыннан алды да күзләренә куйды. Окулярларын боргалый-боргалый теге як ярга карады. Нindидер бер карт, чүгәләгән килеш, балыкчыларга карап тора иде. Ул елый иде булса кирәк, куллары белән аратирә күз яшьләрен сөртеп ала. Битен аның ак төкләр каплаган иде. Эте дә, хуҗасына ярарга теләгәндәй, карт белән янәшә утырып, су өстен күзәтә.

— Ниткән могҗиза?! — диде Рамил һәм бинокльне Мирсәеткә бирде. — Кыш якынлашып килгәндә, бу карт, этен ияртеп, каян килеп чыккан монда? Нәрсә кирәк икән бу мескенгә? Елый да түгелме соң ул?

Чыннан да, җәйге челләдә дә монда кешене сирәк очратасың. Ә хәзер көзнең соңгы көннәре, бүгениртәгә елга тулып сил агарга тора. Шуннан соң елга калын боз панцирь белән капланачак. Каян килеп чыкты соң әле бу мескен карт. Башкорт нефтьчеләренең Агыйделеннән яки удмурт ягыннан бирегә ту-

рыдан-туры килеп булмый. Агыйделнең теге ягы да Түбән Кама гидроэлектростанциясе плотинасын төзү нәтиҗәсендә ерганаклар белән чуарланып бетте. Аларны да көймә белән генә үтәргә мөмкин.

Печән чабучылар җәен хәзер карт чүгәләп тора торган җирдән уңдарак землянка барлыгын күргәннәр иде. Сарапулдан килгән балыкчылар үзләренең тиз йөрешле «Казанка»ларын шунда туктаталар иде.

Мирсәет игътибар белән теге як ярны күзәтте, картның ни эшләвен белергә тырышты. Карап торуга аңа җитмеш биш яшьләр иде. Ул бер урында утыруын дәвам итте, күз яшьләрен сөрткәләп алды. Карт чыннан да елый иде.

Мирсәет, су кырыена ук килеп, кулларын рупор ясап авызы тирәсенә куйды да:

— Бабай, син кайдан килдең? Нигә елыйсың? — дип кычкырды.

Күп тә үтмәде, Мирсәетнең сүзләре кайтаваз булып бу якта яңгырады: «Бай-бай си-си-син... лыйлыйсың».

Аръяктагы бабай талпынып куйды, аннары, әкрен генә торып, яр кырыена ук килде һәм нидер кычкыра-кычкыра кулларын болгады. Бу урында Агыйдел бик киң иде, шуңа күрә балыкчылар картның аңлашылмый торган кайтаваз катнаш өзек-өзек сүзләрен генә ишеттеләр. Картның «шяр», «ошяр», «үләргә», әллә инде «ләргә» кебек өзек-өзек сүзләреннән кала алар берни дә ишетә алмадылар. Хуҗасының сүзләрен җөпләгән сымак эте дә балыкчыларга карап улап куйды.

Рамил белән Мирсәет кармаклары турында бөтенләй оныттылар. Аларның уй-фикерләре карт турында иде. Кайдан килүе мөмкин? Ни өчен килгән? Аның «шяр», «ошяр», «ларга», «үләргә» дигән сүзләре нәрсә аңлата? «Шәр», «өшәр» беркадәр аңлашыла да шикелле. Елганың теге ягында, моннан өч чакрым ярымнар ераклыкта зур су киткәнчегә кадәр мең хуҗалыклы Өшәр авылы булган... Хәзер анда бер әйбәт, ике ташландык, кыйшайган йорт бар. Әйбәт дигәне — күптән түгел салынган йорт. Анда туксан өч яшьлек әнисе белән Габдулла Хәйбуллин яши. Ул әле карт түгел, 62 яшьлек тап-таза ир-ат. Аны күпме генә кумасыннар, зур судан соң да ул беркая китмәде. Җәй айларында алар янына Сарапулдан өйләнмәгән улы белән сеңелесе Гөлүдә кайта.

Рамил белән Мирсәет картка ярдәм итә алмыйлар иде. Көймәләре юк.

Мирсәет кулларын рупор ясап авыз кырыена куйды да картка тагын бер тапкыр бар көченә кычкырып карады:

— Бабай, янәшәдә землянка бар. Землянка! Землянка! Шунда кун. Иртә белән нәрсә булса да уйларбыз...

Бабай елга комы өстеннән әрле-бирле йөри торды, балыкчыларга карап башын иде, дога кылды булса кирәк, куллары белән битен сыйпаштыргалады.

Елга өстенә әкрен генә булып караңгы төште, гүя Агыйдел ике як ярдан пәрдәләр белән ябылды. Тиздән карт белән эт тә кичке караңгылыкта эреп күренмәс булдылар.

Рамил белән Мирсәет киңәшкәннән соң, иртә торгач, «Беларусь» тракторының арткы көпчәкләрен сүтәргә булдылар. Камераларын һава белән тутырып, ишкәкләр ясап, теге якка чыгарга һәм бабайның нишләп йөрүен, ни өчен елавын белергә, әгәр кирәк икән, ярдәм итәргә булдылар. Шушындый планнары белән алар үзләренең такта йортларына йокларга кереп киттеләр.

### *Өченче бүлек*

Агыйделгә төшә торган текә ярдагы землянкага карт теге яктагы нефтьче-балыкчылар аны күргәнче үк кереп чыккан иде инде. Су буена төшкәнчегә кадәр үзе һәм Спутник атлы дүрт аяклы дусты өчен әзерләнгән азык-төлек тутырылган армия котомкасын салып куйды. Фатих исемле кеше иде ул. Кәримов Фатих Салих улы. 1926 елда туган. 1945 елның сентябрендә япон-совет сугышында катнашуын, әсоңыннан Ерак Көнчыгыш хәрби гарнизоннарында хезмәт итүен санамаганда, ул үзенең бөтен гомерен диярлек Агыйделдән өч чакрым ераклыкта урнашкан Өшәр авылында уздырган.

Теге яктагы тракторчылар җитмеш өч яшьлек Фатих бабай кычкырганнарны чама белән дөрес аңладылар:

— Өшәргә кайтам. Үләргә кайтам.

Ашык-пошык кына һәм бик тупас итеп ясалган ишекне ачып, Фатих бабай зажигалкасын кабызды. Землянка бик оста казылган иде. Ян-як стеналары буйлап караватка охшатып тумбалар ясалган, ә уртада өстәл урынына файдаланырга диптер инде, тагын бер түмгәк куелган. Нәкъ менә совет чорларында корылган кунакханәләрнең ике кешелек бер бүлмәсе иде. Сарапулның балыкчылары сукыр лампа, тоз һәм шырпы да калдырганнар. Карт лампаны кулына алып селкеп карады. Ниндидер сыекча бар иде. Ул зажигалкасын лампа филтәсе янына китерде. Бермәл черт-черт итеп алганнан соң, ул кабынды. Җир асты «кунакханә»се кызгылт-сары төс алды. Спутник шатланып шыңшып куйды, хуҗасының гамәлләрен хуплагандай, койрыгын болгады. Землянка почмагында мичкә охшаш бер нәрсә тора иде. Аңардан 200 миллиметрлы торба күтәрелә, ул «кунакханә» түбәсен тишеп тышка чыга. Әзер утын юк иде. Хәер,

мичкә ягуның да әллә ни кирәге юк әле. Җир асты бүлмәсендә чагыштырмача җылы. Караватларга коры печән җәелгән. Гомумән, ятак әзер иде.

Карт алдан ук өендә, Сарапулда әзерләгән бер кирпеч икмәген, бер кисәк «Доктор» колбасасын өстәл өстенә чыгарып салды. Аннары шулар янына ук ике литрлы баллонга тутырылган чәйне, ярты литр аракы китереп куйды. Беренче эш итеп, ул икмәгенең яртысын дусты Спутникка ваклап бирде. Тегесе аны ашап бетергәннән соң карт аңа бераз деликатес — «Доктор» колбасасы каптырды. Эт, туйгач, бусага буена сузылып ятты. Шуннан соң гына Фатих бабай котомкасыннан пластмасс стакан алды һәм йөз грамм аракы салды. Аны тамак кырып эчеп җибәрде һәм ипи белән колбаса чәйни башлады. Бабайның ашыйсы килми иде. Аппетит өчен йөз грамм да ярдәм итмәде.

Керосинның бетүеннән куркып, Фатих бабай өстәлдәге ашамлыкларын тиз генә җыеп капчыгына салды. Спутнигын «караватка» чакырды. Эт, урыныннан торып, әкрен генә килде дә югарыга сикерде. Шуннан соң карт, филтәгә өреп, аны сүндерде. Җир асты патшалыгы караңгылыкка чумды. Кинәттән генә баз исе чыкты. Спутник ир-атлар сымак стена буена сузылып ятты. Карт битен эткә каратып яткач, тегесе, ачу белдереп, ырылдап куйды һәм хуҗасына арты белән борылып, танавын җир стенага терәде. Эт кечкенә вакытыннан ук спирт исен яратмый иде. Кайчакларда Фатих шәһәрдә якташларын очратып, кафега керә дә, сөйләшә-сөйләшә, бер-ике рюмканы җибәрә. Аннан чыккач, дүрт аяклы дусты белән шаяра. Эте аның андый вакытларын яратмый. Ырылдый, усаллык белән булмаса да, йомшак кына итеп тешләп ала, башын селки-селки читкәрәк китеп баса. Ә бервакыт шулай да булды: җиңелчәрәк кенә салмыш хуҗа өендә эте белән артыграк шаярып җибәрдеме, Спутник аның аягын шәп кенә тешләп алды. Шуннан соң хуҗа да, эт тә бер-берсе белән озак, дүрт көннәр чамасы булыр, аралашмадылар. Ишегалдына чыккан хуҗасын күрсә, Спутник башын ия дә, каш астыннан гына кырын карап, үзенең оясына кереп китә. Аңлавы кыен иде: әллә инде ул салмыш хуҗасының тупас уйнавына, йонын тискәре якка сыйпавына, танавына сугуына үпкәли, әллә инде аягын тешләгәнгә үзен гаепле санап йөри?!

Үз чиратында карт та аның янына бармады, тегенең ачуын китерәсе килмәде. Көннәр үтә торды. Вакыт үтү белән, ике арадагы үпкәләүләр дә үзеннән-үзе юкка чыкты. Кем әйтмешли, вакыт бар җан иясе өчен дәва.

Фатих бабай да, сөякле сыртын этенә терәп, кирегә борылып ятты, күзләрен караңгылыкка төбәде. Аларның икесенә дә җылы иде. Кинәт картка бу җир астында бик куркыныч булып китте. Үзен бөтенләйгә шушында тере килеш күмелгәндәй хис итте. Менә ул шушында үләр дә сөякләренең кая ятканын да, җанының кайларда йөрүен дә берәү дә белмәс кебек. Аның башына тагын да куркынычрак уй килде: җаны гәүдәсен ташлар да, нинди дә булса бозга утырып, Агыйдел буйлап түбән таба агып китәр. Җанының еракларга агып китүен теләмәде. Ул аның янында булырга тиеш. Ул үзен бабалары, әбиләре, инәкәе, хатыны, кызлары һәм улы җирләнгән авыл зиратына күмүләрен теләде. «Нигә әле мин курка калдым,— диде карт эченнән генә һәм чынбарлыкка кайтты.— Үземнең туган ягыма үләргә дип кайттым түгелме соң?» Карт иртәдән алып шушы җир асты «кунакханә»сенә килеп «карават»ка ятканчыга хәтле вакытын күз алдыннан үткәрде.

...Сарапулда ул бу көнне бик иртә торды. Алдан әзерләп куелган азык-төлекләрен капчыкка тутырды. Вакыт үтү белән саргаерга өлгергән фотолар тулы гаилә альбомын да шунда салды. Дусты Спутнигын ашатты. Ишекне башта өске бигенә, аннары асылмалы йозак белән бикләде. Баскыч өстенә утырды. Бермәл тын гына торганнан соң, Коръәннән үзе белгән аятьләрне укыды. Этне чылбырыннан ычкындырып, урамга чыкты. Капка келәсен төшереп, күршеләргә юнәлде. Алар йоклыйлар иде әле. Фатих бабай кыяр-кыймас кына янәшәдәге кечкенә ян капканы шакыды. Тавышны ишетеп, күршесе Василий карт чыкты.

— Таң тишеге белән кая җыендың? Балыккамы әллә? — дип сорады Василий.

— Юк,— диде Фатих бабай.— Туган авылыма китүем. Ары монда яши алмыйм. Җанны ниндидер сагыну сызландыра. Үлем сагышы. Үлем дигәне килеп җиткән, күрәсең. Шулай менә, Өшәргә киттем. Кем белгән, күңел тынычланса, бәлки, кайтырмын да әле... Капылдан гына түгел,— диде Фатих бабай, ишетелер-ишетелмәс кенә,— күңелдә сагыш тора...— Бермәл тын торганнан соң дәвам итте: — Рәшит улым кайтса, әйт, авылга китте, диген. Өй ачкычлары аңарда бар. Ә Спутникны мин үзем белән алам. Юлдаш булыр.

Соңгы кырык ел эчендә Фатих бабай берничә эт тотты. Ул аларны бала килеш ала иде, һичшиксез, атасын. Аларның барысына да Спутник дигән исем бирә. 1957 елның октябрендә Советлар Союзының Җир тирәли орбитага Спутник җибәрүе турында дөньяның бөтен радиостанцияләре хәбәр таратканнан соң шулай китте аның. Ул вакытта әле ул гаиләсе белән — үсеп килүче өч баласы һәм тыңлаучан, хезмәт яратучы, пакь, киң күңелле, сөйкемле хатыны Фәридә белән туган авылы Өшәрдә яши иде. Фатих өчен бу иң бәхетле еллар иде. Чыннан да, балалар тууу, малайларының армиягә киткәнчегә кадәрге, кызларның кияүгә чыкканчыга кадәрге вакыт ата-ана өчен иң бәхетле еллар булып тоела. Җир иярчене җибәрелү уңаеннан авылдагы күршесе Фатихка бик сөйкемле эт баласы бүләк итте. Алар аңа бергәләшеп Спутник дигән исем бирделәр. Тегесен, үсеп килә торган Спутникны, кыш башында Сарапулдан килгән балыкчылар урлап киттеләр. Фатих озак вакытлар аны оныта алмады. Язын ул тагын эт баласы ал-

ды. Аны да Спутник дип атады. Этләр бик сирәк үләләр, аларны урлыйлар. Менә ул тагын дүрт аяклы йомшак кына җан иясе алды. Аны тагын Спутник дип атады.

Менә бүген шатланып, сикерә-сикерә Фатихны Сарапул автовокзалына озата баручы тугрылыклы дусты — Спутнигы өч ел инде аның карамагында яши.

Билетны карт Каракүл район үзәгенә кадәр алды. «ПАЗ»ик автобусында Каракүл автостанциясенә чагыштырмача бик тиз, тоткарлыксыз-нисез барып җиттеләр. Дөрес, башта шофер мыгырданган булды. Янәсе, этен борынчыксыз алып бара. Барысы да урнашып беткәч, эт хуҗасының аяклары янына тыныч кына килеп ятты. Ялагайланып, автобустагыларның барысына да карап алды. Шофер да тынычланды һәм:

— Овчарканың исеме ничек? — дип сорап куйды.

— Ул овчарка түгел, ә себер лайкасы, исеме — Спутник,— диде карт.

— Кызык,— диде шофер,— димәк, Спутник. Матур исем. Иң мөһиме — заманча. Үз исемен ишеткәч, эт койрыгы белән берничә мәртәбә автобус идәненә суккалап алды һәм хуҗасына сораулы караш ташлады.

Каракүл гаҗәп матур урында урнашкан. Моннан, тау башыннан, башкорт болыннары, нефть вышкалары уч төбендәге кебек күренә. Ә еракта Агыйдел бистәсе утыра. Уңда элеккеге Дербешка пристаненә Кама борылышы, янәшәдә үк елганың текә яр битендә Чеганда тау куышлыгы. Карт үзенең туган авылы Өшәр ягына карап торды, туган җирнең ниндидер бер үзенчәлекләрен күрәсе килде. Ләкин бернәрсә дә күрә алмады. Йөрәге күкрәк читлегеннән чыгардай булып типте, туган җирнең якынаюын күреп күңеле нечкәрде. Алар Спутник белән Кама буена төштеләр. Бәхеткә каршы, бер хатын белән бер ир көймәгә утыралар иде. Карт:

— Эт белән икебезне аръякка чыгарып куймассызмы? — дип сорады.

— Әйдәгез, әйдә, тизрәк утырыгыз,— диде көймә хуҗасы һәм двигателенең каешын тартып җибәрде.

Көн тыныч, җилсез иде. Көймә каршы як ярга бик тиз барып җитте. Алып чыккан өчен акча алмадылар. Фатих бабай Спутнигы белән Агыйделгә таба китте. Бу юлны ул бала чактан ук белә иде инде. Аның авылдашлары белән кышын да, җәен дә бу юллардан Каракүлгә, ә аннан Сарапулга ничәмә тапкырлар үткәне булды. Тиздән юлчыларны башкорт номерлы «бобик» куып җитте. Нефтекамск нефтьчеләре иске Агыйделнең уң як ярына балык тотарга баралар икән.

Бу көн карт һәм аның эте өчен бик уңышлы килеп чыкты. Салкынча булса да, көн кояшлы, коры иде. Транспортын да Ходай бирә тора. Картның кәефе дә беркадәр яхшырды. Кичәге ыңгырашулар, күңел сыкрануы күпмегәдер онытылып торган кебек булды. «Бобик»тагы балыкчыларның:

— Кая юл тотасыз? — дигән сорауларына каршы карт:

— Туган авылым Өшәргә! — дип кырт кисте.— Үләргә кайтам.

Балыкчылар, бер-беренә нидер әйтеп, озак һәм каты итеп көлештеләр.

— Кара син аны, үләргә җыенган. Син әле, бабай, бездән дә уздырачаксың...

— Юк инде,— диде карт, «бобик»тан чыга-чыга. Ул инде бу вакытта иске елганың аргы ягында иде.

Балыкчылар үзләренең балык тота торган аулак урыннарына китеп бардылар. Карт үзенең Спутнигы белән Агыйделнең уң як кушылдыгы ярында калды. Агыйделнең үзенә барып җитү өчен каршы як ярга чыгарга кирәк иде. Тирә-юньдә бернинди җан иясе дә юк. Карт, уйга калып, бер сәгать чамасы утырды. Ул инде көн яктысында теге як ярга эләгә алмаячагына борчыла башлады. Кинәт тынлыкны су өстеннән очып диярлек килүче көймәнең двигатель тавышы бозды. Фатих бабай, үҗәтләнеп, колаклы бүреген салып болгый башлады. Бабай белән этне күрделәр. Көймә зур тизлек белән яр комын ерып килеп туктады.

— Нәрсә, карт? — дип кычкырды юан муенлысы. Көймәдә тагын шундый ук икәү утыра иде. Аяк асларында ятьмәләр.

— Теге якка гына чыгармассызмы икән? — дип сорады Фатих бабай, кыяр-кыймас кына.— Миңа Өшәргә барырга иде.

— Әйдә, утыр, бабай, чыгарырбыз,— диде берсе.

«Дөньяда әйбәт кешеләр бар шул»,— дип уйлап алды карт һәм шул минутта ук эте белән көймәгә кереп утырды.

Күп тә үтмәде, моторлы көймә Сарапул сәяхәтчеләрен соңгы утрауга китереп җиткерде. Моннан ерак та түгел, янәшәдә үк аның җанына иң кадерле булган туган җире. Аның менә туган Агыйделе буенда гөнаһлы дөньяга килүе турында хәтта ышанасы да килми иде. «Һи, минем туган җиремә хәзер бер адым»,— дип уйлады Фатих бабай, Агыйдел яры буена төшә-төшә. Теге як ярда Габдулла хуҗалыгыннан эт өргән, этәчләр кычкырган тавышлар ишетелде. Авылдашы учагыннан чыккан төтен картның борынын кытыклый сыман тоелды. Әмма балачактан йөргән сукмакларга җиткәндә, соңгы каршылыкларны җиңү Спутник белән Фатих бабайга бик үк җиңелдән булмады.

Агыйдел, Агыйдел, аның яраткан Агыйделе! Совет-япон сугышы көннәрендә Маньчжурия сопкаларында ятканда төшләренә кергән, Сарапулда яшәгәндә күңеленнән чыкмаган Агыйделе бүген аны туган җиренә, балалык, яшьлек елларын, гаиләсе белән яшәгән елларын үткәргән җиргә җибәрми. Ул аны теге якка, иң якын кешеләре, туганнары, авылдашлары күмелгән җиргә үткәрми.

...Карт, уйлана-уйлана, бик авырлык белән генә төн уртасында йокыга китте. Кайчандыр зур булып гөрләп торган авылы, туган йорты төшенә керде. Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә вафат булган, дөресрәге, «хәбәрсез югалган» әтисе төшенә керде. Соңгы вакытта ул аның йөзен һич төгәл генә күз алдына китерә алмый иде. Ә бүген ул аның төшенә шулкадәр яшь, шулкадәр матур булып керде ки, нәкъ менә аны фронтка, Актаныш район үзәгенә озаткандагы шикелле. Хатыны Фәридә дә төшенә керде. Кулы белән ымлап гел үзе янына чакырды. Ә ул аңа каршы йөгерде, һич кенә дә араны үтә алмады. Төштә шулай була шул. Нәкъ менә шул мизгелдә, Фәридәсен кочагына алам дип ашкынганда, карт уянып китте. Яраткан хатынын кочагына ала алмаганлыктан, рәнҗеп, Фатих бабай елап җибәрде. Эт тавыш чыгарып иснәде дә идәнгә төште. Карт зажигалкасын кабызып сәгатенә карады, ләкин бернәрсә дә күрә алмады. Капшанып, бушлат кесәсеннән чехолга салынган күзлеген алды. Аны кигәннән соң, янә зажигалкасын кабызды. Сәгать алты иде.

Ул урамга чыкты, әле караңгы иде. Салкынайта төшкән. Көнчыгыштан салкын җил исә. Спутник үзенең эшен тәмамлады да хуҗасының аякларына килеп сыенды. Бераз басып торганнан соң, җир асты «кунакханә»сенә керделәр. Карт, кулларын баш астына куеп, чалкан ятты һәм уйланды: «Агыйделнең теге ягына бүген дә чыга алмас микән?» Күкрәген кыздырып йөрәге әрнеде. Картны билгесезлек борчый иде. Спутник «караватка бүтән менеп маташмады. Ул шыгырдавык ишек янына ятты. Фатих бабай көннең тулысынча яктырганын көтәргә булды.

### *Дүртенче бүлек*

Тракторчылар икесе берьюлы диярлек уяндылар. «Дача» йортларының бердәнбер тәрәзәсеннән октябрьнең эңгер-меңгер яктылыгы төшеп килә иде. Йорт нык суынган.

— Буржуйканы ягып җибәр,— диде Рамил, башын иске одеал астыннан чыгармыйча гына.

— Тор да як,— диде шаяртып Мирсәет.— Кара син аны, патша ята дип белерсең.

— Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала? — диде Рамил көйгә салып һәм, курткасын киеп, өйдән чыгып китте. Бераздан ул бер кочак коры-сары, өянке ботаклары алып керде. Аларны җәен әзерләп куйганнар иде.

Кочагындагы утыннарны идәнгә куйгач, Рамил калтыранып куйды:

— Кеше яшәми торган бу утраудан тиздән Зур җиргә китәрбез, ахры. Шуңа охшаган. Өй янындагы су каткан. Минус бишләр булыр, мөгаен.

— Кызык, безнең бабай анда исәнме икән? Аның белән нәрсә дә булса булыр шикелле,— диде Мирсәет һәм үзләре ясап куйган караваттан сөйләнә-сөйләнә әкрен генә торып утырды.

— Әйдә, тиз генә чәй эчик тә яр буена йөгерик,— диде Рамил һәм буржуйкага тыштан алып кергән утыннарын тыкты. Ут кабызып җибәрде.

Яр буена төшкәннәр иде, катып калдылар. Агыйдел тулып силнең аксыл соры массасы ага. Көчле агым ярга якын урыннарда боргалый, әйләндерә, аннары ярга китереп тери. Зуррак боз кисәкләреннән торган көчлерәкләре аны төрткәләп, түбән таба алып төшеп китә. Яр буенда үсеп утыручы өянкеләр апак бәс белән капланганнар. Алар шулкадәр матур күренәләр ки, без кайчандыр совет кинофильмнарында караган сәүдәгәрләрнең кышкы кәрваннарын хәтерләтәләр.

— Менә сиңа мә! — Рамил башка ни әйтергә белмичә, Мирсәеткә карады.

— Э-һе...— Мирсәет тә шуннан артык әйтер сүз тапмады. Бераз тын торганнан соң өстәп куйды: — Ситуация. Хәзер «Беларусь» көпчәген сүтүнең кирәге калмады инде. Кышкы йокыга талыр алдыннан сил акканда елгага керү үлемгә бару белән бер. Карт балыкчылар, хәер, алар гына түгел, көймәдә йөрүчеләр дә силнең нәрсә икәнен яхшы беләләр: аның тоташ агучы массасы металлдан ясалган көймәләрне дә уенчык кәгазь корабларны бөгәрләгәндәй бөгәрләп ташлый яисә үз арасына кыстырып агызып алып китә. Бу вакытта трактор камераларына утырып елгага керү, гомумән, акылсызлык булыр иде. Хәзер инде бу масса агымының туктаганын гына көтәргә кала. Аны суык туктатканнан соң, боз өстеннән әкрен генә шуышып чыгарга мөмкин булачак.

Әйе, аның чоры шундый иде — бу вакытта Агыйделнең түбәнге өлешендә бөтен хәрәкәт бер атнага туктый иде. Елга тулысынча боз белән каплангач кына, тормыш яңадан башлана. Башта җәяүлеләр саклanып кына боз өстеннән чыгалар, ә аннары инде — атлылар. Бу иксез-чиксез болын тигезлекләрен кар каплагач, монда икенче тормыш — кышкы тормыш башлана. Каракүлгә, Агыйдел бистәсенә һәм башка урыннарга, шулай ук печән кибәннәренә туп-туры юллар салына. Күп очракта бу юлларны, балыклы урыннарны яхшы белүче Сарапул балыкчы-фанатиклары салалар иде. Кышкы яшәү шартлары әле бүген түгел, якынча биш-җиде көннән булачак. Агыйделдә әле хәзер боз белән кар катнашмасы хакимлек итә.

— Әнә алар,— дип шатланып кычкырып җибәрде Рамил.— Аллага шөкер, исән-саулар.

— Уф-ф,— дип җиңел сулап куйды Мирсәет тә.

Механизаторлар фараз кылган землянка янындагы бәс сарган өянкеләр арасыннан таякка таянган, этен иярткән картыбыз елга буена төшеп килә иде. Менә ул елга кырыена килеп җитте. Иелеп учына су алды, битен юды. Кулларын селкештергәннән соң, берсен каш өстенә куеп, Агыйдел аръягына, туган авылы Өшәр ягына карап тора башлады.

Мирсәет, кулларын рупор ясап, Агыйделнең теге ягындагы кешегә кычкырды:

— Исәнме, бабай! Елга тынганын көт. Сине обязательно алып чыгарбыз.

Карт туган ягыннан ишетелгән сүзләрнең мәгънәсен аңлады бугай. Ул, бөкре гәүдәсен түбән игәләп, үзенең рәхмәтен белдерде. Аннары, якташлары ягына карап, нидер кычкырды. Ир-атлар карт әйткән сүзләрнең кайбер өзекләрен генә ишеттеләр. Алар картның кичә әйткәннәренә охшаш иде.

Рамил кыршылып беткән биноклен күзләренә якын китерде. Карт бүген дә елый иде. Ярчыкланып беткән бармаклары белән күз яшьләрен кырынмаган җыерчыклы битенә сылый.

— М-да,— дип уйга калды ул.— Картка нәрсә дә булса булган, әледән-әле үлемне кабатлый. Өшәр авылы турында әйтә. Мөгаен, кеме дә булса үлгәндер аның анда.

Ир-атлар, үзләренең көчсезлекләреннән уңайсызланып, яр кырыена килеп утырдылар. Елганың теге ягында карт та утырды. Агыйдел буйлап, ниндидер ямьсез тавыш чыгарып, елганы тоташ каплап, кыш алды силы ага иде.

## *Бишенче бүлек*

Фатих бабай үзенең үткән тормышын Агыйделнең шушы болганчык агымы, силның бер-берләренең өсләренә менүче ак-соры карлы боз кисәкләре белән чагыштырды. Шушы үлемнәр белән тулы һәм серле егерменче гасырда аның тормышы да болганчык агым булып үтте. Силның аклары күбрәк бугай, ә аның тормышында соры таплар күбрәк урын алып тора.

Сугыш алды елларында энкавыдышникларның Актаныш авылларында «халык дошманнарын» эзләп, хуҗалыктан хуҗалыкка йөрүләре аның әле дә хәтерендә. Кырык беренче елның соңгы бер кояшлы көне гомерендә онытылмаслык булып хәтерендә уелып калды. Ул көнне әтекәен — Салих абзыйны, Өшәр авылының бөтен сәламәт ир-атларын сугышка озаттылар. Булачак фронтовикларның җыелу урыны Актаныш янында, Агыйделнең Әҗәкүл пристанендә иде. Аннан инде аларны башта Агыйдел, аннары Кама, Идел буйлап Казанга алып киттеләр. Салих абзый үзенең туган авылы белән ике мәртәбә саубуллашты дияргә була. Русча белмәүче кичәге колхозчыларны беренче тапкыр җәяүләп күрше Чиялек авылына озаттылар. Бу хәл ерактан караган кешегә бөтен авыл яшәгән урыныннан купкан да каядыр күчеп китәргә җыена сыман күренгәндер. Чиялекне чыккач, Салих абзый ягымлы гына итеп кырынмаган ияге белән Фатихның битләреннән сыдыргалап алды, үзенең тормышында соңгы тапкыр хатыны Фәрхикамалны кысып кочаклады. Аннары туп-туры Актаныш ягына, авылдашларын куып китте.

Икенче тапкыр ул туган авылы белән бер тәүлектән соң саубуллашты. Ул иске генә бер пароходта Агыйдел буйлап үзе өчен иң кадерле булган, әле кайчан гына печән чапкан, биш баласы белән шомырт, гөлҗимеш, салкыннарда балан җыеп йөргән болыннар яныннан үтте. Алар утырган пароходның һәм үтүче башка судноларның сузып-сузып кычкыртуы йөрәкләрне өзә. Бу, күңелеңнән үзеңне ялгыз сизеп, Агыйдел белән бик авыр саубуллашу иде. Югыйсә палубада янәшәдә генә бөтен авылдашлар тын гына басып тора. Гәрчә аларның да йөрәкләрен шундый ук уйлар яндырадыр. Алар да бит төп су юлыннан өч кенә чакрым ераклыктагы Өшәр авылы ягына карап бакканнар.

Өшәр ике-өч көн эчендә бушап калды. Хезмәткә яраклы барлык ир-ат фронтка китте. Биш бала белән калган фронтовик хатыны Фәрхикамал апа кинәттән авырып урынга ятты. Өйдәге бөтен мәшәкать, хуҗалык эшләре унбиш яшьлек өлкән улы Фатих җилкәсенә төште. Көндезен ул колхозда эшләде, кичен өйдәге мал-туарны карады, кышка утын әзерләде.

Өч айдан Фәрхикамал апа беркадәр рәтләнде, әкрен генә өйдә йөри башлады. Алар һәр көнне әтиләреннән хат көттеләр, чөнки киткәннән бирле аңардан әле бер мәртәбә дә хәбәр килгәне юк иде.

Көннәрнең берендә терелеп килүче Фәрхикамалга, гаиләгә язмыш үзенең бөтен ачысын күрсәтте. Хат ташучы алар йортына кара хәбәр китерде. Ул тапшырган кәгазьдә дөньядагы иң кайгылы сүзләр язылган иде: «Кызылармеец Кәримов Салих Ватан өчен барган сугышларда хәбәрсез югалды». Ул көннәрдә мондый кара кәгазьләрне бик күпләр алды. Фәрхикамал, бу кайгыга чыдый алмыйча, тагын урынга егылды.

Фатих болай тыштан караганда нык торды. Ләкин эченнән бик кайгырды. Үзенең, дүрт энекәшенең һәм сеңелесенең әтисез калуына ышанасы килмәде. Авыл капкасын чыккач, беразга атын туктата да, арбага менеп, озак кына Кама, Дербешка пристане ягына карап тора, карашы белән Кама аръягындагы Удмуртия колхозы кырларын әйләнеп чыга. Әйтерсең лә фронт шуннан, горизонттан үтә. Ниндидер могҗиза белән ул анда барып чыгар да әтисен очратыр, үзенең йомшак битләре белән аның кыл сакалын сыйпар кебек иде. Әмма Кама ягыннан ишетелгән пароход гудоклары, күңелне елатып, кайгыга са-

лып торалар. Зур гаиләгә тормыш биргән кешенең менә шулай кинәттән генә юкка чыгуына ышанмый иде ул.

Кырык дүртенче елның көзендә Актаныш аша шул ук маршрут белән үзен Казанга, аннан фронтка озатканда да әтисен башка һичкайчан күрмәячәгенә ул ышана алмады. Үзенең өлкән малаен фронтка озатканда, Фәрхикамал кара янып йөрде. Шулай да ул, Фатихы анда, бәлки, әтисен очратыр әле дигән өмет белән яшәде. Ул да барлык фронтовик хатыннары кебек иренең үлүенә яки хәбәрсез юкка чыгуына ышанмады. Тере кеше ничек инде хәбәрсез югалсын?

— Улыкаем, хет син исән-сау кайт инде,— дип кабатлады ана.

Фатихны нык гаҗәпләндергәне шул булды: аларны Казаннан Көнбатыш фронтка түгел, ә пассажир поезды белән көнчыгыш юнәлешенә, Ерак Көнчыгышка җибәрделәр.

Ул Кытай чигендә хезмәт итте. Көнбатыш фронтка эләкмәве нигәдер һәрвакыт аның күңелен тырнап торды. Ахыр чиктә әтисенең эзенә төшә алмаса да, Россия җиренә кайгы-хәсрәт, җимерүләр, үлем алып килгән фашист илбасарларыннан үч алыр иде. Хезмәт үз көенә үтә торды. Шунысы читен — бик начар ашаталар. Әйтүләренчә, бөтен булган азык-төлекне Көнбатыш фронтка җибәрәләр икән.

Менә шулай хезмәт итә торгач, кырык бишенченең мае да килеп җитте. Шуның белән бергә — Бөек Җиңү. Фатихка, инде сугышлар беткәч, әтисе өйгә кайткандыр кебек тоелды. Ә ул монда Маньчжурия сопкалары арасында эшсез ята.

Ай ярымнан Ерак Көнчыгышка товар, эшелоны-эшелоны белән хәрби техникаларын да алып, сугыш утыннан чыккан фронтовиклар килә башлады. Ил чираттагы яңа сугышка, Япония белән сугышка әзерләнә иде.

Кыска вакытлы бу сугышны Фатих бик җиңел үткәрде. Аңа Сугышчан Кызыл Байрак ордены тапшырдылар. Вакытына карата бу бик зур бүләк иде. Аның әле тагын җиде ел хезмәт итәсе калды. 1926 — 1927 елларда туган егетләр сигезәр ел хезмәт иттеләр.

Туган Өшәр авылына ул илле икенче елны өлкәнәеп, матураеп кайтты. Ике энесе армиядә хезмәт итә иде. Ә бер сеңелесе кияүгә чыккан. Әнкәсе иң кече кызы — төпчеге Земфира белән яши иде. Сугыш чорындагы һәм сугыштан соңгы колхоз тормышын күргән әнкәйләре өлкән улының исән-сау авылга әйләнеп кайтуына башта ышана алмый торды. Фатих шомырт кара күзле Фәридә исемле чибәргә өйләнде. Ул иреннән дүрт яшькә кечерәк. Армиягә киткәнче Фатих аны күргәне дә булмады, белми дә иде. Ул Ерак Көнчыгыш чикләрен япон самурайларыннан саклаган арада, Фәридә менә дигән чибәр кыз булып үсеп җиткән. Шуның өстенә әле ул бик яхшы хуҗабикә, ә балаларына менә дигән әни булды. Әүвәл, никах укып, тыйнак кына туй ясап алдылар. Мулла булмаганлыктан, никах ритуалын Фәрхикамал үзе башкарды. Ул күп кенә аятьләрне яттан белә иде. Дин мәсьәләләрендә бик гыйлем булган әнисе Бибиәсма кызын да өйрәткән. Фәрхикамал Коръәнне гарәпчә бик иркен укый иде.

Фатих үзенең булачак хатынын беренче күрүдә үк яратты. Ә бу ярату көннән-көн ныгыды. Фатих саклады бу мәхәббәтне. Фәридә дә аңа шулай ук җавап бирде. Бер-бер артлы балалары туа башлады. Башта Рәзилә туды, аннары уллары Зөфәр белән Рәшит.

Фатих үзе колхоз мастерскоенда механик булып эшләде. Бу еллар аның өчен иң бәхетле еллар иде. Ни өчендер андый еллар сиздермичә тиз үтәләр шул.

## *Алтынчы бүлек*

Уйланып утыра торгач, Фатих бабай аръяктагы механизаторларның әбәт ашарга кереп китүләрен күрми дә калды. Ни өчендер Спутнигы да үз янында тыныч кына ята бирә. Фатих аякларының туңа башлавын сизде. Ул утырган җиреннән торды. Хуҗага ияреп аның дүрт аяклы дусты да землянкага таба китте. Агыйдел өстендә карлы бозларның шыбырдавы һаман ишетелеп тора иде әле. Фатих бабай балыкчылар әзерләп куйган утыннарны землянкага ташыды. Буржуйкага охшаган мичне ягып җибәрде. Аның өстендә су белән тулы колаксыз алюмин кәстрүл тора иде. Балыкчылар, сунарчылар кебек үк, язылмаган законны саклыйлар: үзләре киткәндә яшәү өчен кирәк-яракларны калдыралар. Мичтәге утыннар әйбәт кенә янып китте. Мичнең ачык ишегеннән чыккан ялкын телләре караңгы җир асты патшалыгын тонык кына булса да яктыртып торды. Кәстрүлдәге су бик тиз кайнап чыкты. Фатих бабай капчыгыннан Сарапулда алган чәен, эмальле кружкасын, шикәрен чыгарды.Дустына тагын ипи белән колбаса кисәген бирде. Алар икәүләшеп мич җылысында ашап алдылар. Карт, землянкадан чыгып, тагын яр буена төшеп китте. Агыйделдә кар катнаш бозлар шаулый иде. Тирә-юньдә беркем дә юк.

Тракторчылар төшке аштан соң картны борчымаска булдылар. Шуңа күрә Агыйдел буена бармадылар, иске елга ярына таба киттеләр. Бу ерганакта сил бөтенләй юк диярлек иде. Ә булганнары су өстендә тыныч кына әйләнеп тора. Теге як ярда халыкларның зур күченүе көннәрендә ташланган ике иске өй тора. Аннан арырак Габдулла Хәйбуллинның яңа йорты күренә. Ә янәшәсендә иске өенең каралып беткән түбәсе тырпаеп тора. Ярда сумалага буялган зур корсаклы өч көймә аунап ята. Кайчандыр гаять зур авыл булган урында бәскә төренгән алабута плантациясе генә. Арырак, унда, удмуртларның Кама аръягындагы кырлары күренә. Каршыда, ике чакрымнар читтәрәк илленче еллар ахырында, алтмышынчы

еллар башында Өшәр колхозчылары утырткан наратлык карачкыл булып күренеп тора. Сул яктарак калкулыкта Буазкүл, аннан арырак Бүләк авылы күренә. Габдулла хуҗалыгы тирәсендә берәү дә юк. Мөгаен, сыерларын, атын, башка мал-туарын кертеп япкандыр. Хәтта аның усал эте дә аваз салмый иде.

— Без Зур җиргә картка караганда иртәрәк чыгарбыз, ахрысы,— диде Мирсәет, тынлыкны бозып.— Монда Агыйделдәгегә караганда боз ике көнгә иртәрәк күренәчәк.

— Моның белән нәрсә әйтмәкче буласың? — Рамил Мирсәеткә ачулы караш ташлады.— Картны үз карамагына калдырабызмыни?!

— Мин боз турында, ә син карт турында... — Мирсәет тә үпкә белдереп куйды.— Мин бит аны ташлап китәбез дип әйтмим. Бәлки, без башта Габдулла янына бара алырбыз, ашарга-эчәргә нәрсә булса да алырбыз.

Чыннан да, механизаторларның бәрәңгедән кала башка ризыклары юк иде инде. Сил башланганнан бирле балык та тотып булмый. Аннан соң аны күрәсе дә килми иде инде.

Иске елга буенда киңәш-табыш иткәннән соң, Рамил белән Мирсәет буржуйкага ягарга дип, өйләренә кайтып киттеләр.

...Фатих бабай хәрәкәтсез генә Агыйдел ярында утырды һәм кышка әзерләнүче салкын суның көчле агымы белән тау-тау силларны агызып китүен күзәтеп торды. Югарыда эт ырылдап, сикергәләп куйды. Тычкан тотмакчы иде, ахрысы. Ләкин аның бу сунарчылыгыннан берни дә килеп чыкмады.

Карт һаман туган җирләрендә уздырган еллары турында уйлый иде.

Камада гидроэлектростанция белән бергә Түбән Кама плотинасы төзеләчәге турында мондагы кешеләр беренче тапкыр 1965 елның язында «Социалистик Татарстан» газетасыннан укып белделәр. Аннан соң бу турыда Татарстан радиосы сөйли башлады. Электр станциясе бик күп энергия бирәчәк диделәр. Ә аның Чаллыда төзеләчәген берәү дә белмәде. Түбән Кама шәһәре турында да ишеткән юк иде. Түбән Кама ГЭСы Каманың иң түбәнге өлешендә төзелергә тиеш бит инде. Бөтен трагедиянең дә нә шул «түбән» дигән сүз кысасында булуы берәүнең дә башына килмәде. Актанышлылар Каманың урта өлешендә диярлек яшәделәр. Кама белән Агыйдел арасындагы өчпочмакта.

Алтмыш алты-алтмыш җиденче елларда инде яңа ГЭСның гаять зур сусаклагычы Камадагы Воткин ГЭСына һәм Бирск шәһәренә кадәр һәм Агыйделгә таба әллә кайларга барып җитәчәк, кеше кулы белән эшләнгән диңгез меңләгән гектар сөрү җирләрен, Кама һәм Агыйдел буендагы атаклы болыннарны басачак икән, дип сөйли башладылар. Актаныш районындагы зур-зур авыллар: Өшәр, Урыс һәм Татар Әҗбие, Агыйдел белән Кама кушылган урындагы үзенең егәрлекле затоны һәм зур бистәсе булган Дербешка пристане һәм тарихи Көләгеш ярындагы кечкенә Урдалы авылы да күчереләсе икән бит.

Шундый сүзләр йөри башлагач, баерак һәм тәвәккәлрәк кешеләр, әкренләп хуҗалыкларын сатып, Удмуртиянең Кама буендагы борынгы Сарапул шәһәренә күчеп китә башладылар. Күрше республиканың моннан йөз чакрымнар ераклыкта урнашкан бу шәһәре Актаныш районы кешеләрен элек-электән үзенә тартып тора иде. Мондагы кешеләр көнбатыш юнәлешендә Минзәлә төрмәсеннән кала берни дә белмиләр иде. Җитмешенче еллар ахырына кадәр Минзәләгә, аннан ары Чыллыга кадәр бернинди юл да юк иде. Түбән Каманы һәм аның комбинатын, аннан соң Чаллы промышленность үзәген төзегәнгә кадәр бу урыннар Алланың ташландык җире иде. Шуңа күрәдер, җирле байпартократлар власте тарафыннан җәберләнгән күп кенә кешеләр чагыштырмача демократик булган якларга — Удмуртиягә һәм Пермь өлкәсенә күчеп китәләр иде. Ә менә Сарапулны үзләренең икенче Ватаны дип саныйлар иде. Күпчелегенең бу матур сәүдәгәрләр шәһәрендә туганнары яши. Эшче кулларның да кадерен беләләр иде бу шәһәрдә. Сугыш елларында бирегә Мәскәүдән һәм Питердан бик зур оборона заводлары күчерелде. Алар сугыштан соң да шунда калдылар, югары үсеш алган социализм чорында да, торгынлык елларында да заманча хәрби техника җитештерделәр.

Җәен, Сабан туе көннәрендә Өшәргә, Татар Әҗбиенә, Чиялеккә, Урдалыга күп кенә элеккеге авыл кешеләре кайта, бәйрәмнәр бик күңелле үтә торган иде. Шәһәрдә яшәүчеләр киткәннән соң, авыллар бушап, тынычланып кала. Печән чабу башлана. Аның бер көне кыш буе мал-туарны туендырырга җитә, икенче төрле әйтсәк, Актаныш районының әкияттәгедәй гүзәл почмагында яшәүче барлык кешеләрне азык-төлекле итә.

КамАЗ автогиганты белән Яңа шәһәрне төзи башлагач, зур су һәм авылларны күчерү турында сөйләшүләр бераз тынып торды. Зәй ГРЭСы энергоблокларын җибәргәч, Түбән Кама химия комбинатының һәм КамАЗның җылылык энергетикасы комплексларын төзегәч, Камада гидроэлектростанциясе салып, энергия арттыруның кирәге калмый икән дип уйлады халык. Түбән Кама ГЭСы төзелеше дәвам иткәнен, бары тик КамАЗ объектлары төзелешен тизләтергә кирәккәнгә финанслауны гына бераз киметкәннәрен гади халык каян белсен ди. Нәкъ менә шул сәбәпле генә Түбән Кама ГЭСын файдалануга тапшыруны төгәл бер бишьеллыкка — совет кешеләре кырык ел буе шул норма белән яшәргә өйрәнгән чорга кичектерелде.

Өшәр авылы кешеләре элеккечә җир сөрделәр, чәчтеләр, югары уңыш үстерделәр. Печән җитәрлек иде, шуңа күрә күпләп мал-туар тоттылар. Гомумән, авыл кешеләре тулы тормышта яшәделәр, балалар

үстерделәр. Турысын гына әйткәндә, торгынлык дигән Брежнев еллары хәзерге демократик дип аталган еллар белән чагыштырганда халык күңелендә ниндидер татлы төш кенә булып калды. Кайгының ни икәнен белмичә унбиш ел яшәделәр.

Колхоз механигы Фатих Кәримов та үзенең тормышына шатланып бетә алмады. Еллар ераккарак алып киткән саен, ул кайгыртучан Фәридәсен тагын да яратарак төште, мәхәббәте артуын тойды. Җитмешенче еллар башына унҗиде яшьлек өлкән кызлары Рәзилә ифрат чибәр булып буйга җитте, бик акыллы һәм тотнаклы булып унбиш яшьлек Зөфәре, унөч яшьлек төпчеге Рәшит үсеп киләләр. Хет мең тапкыр әйт, барыбыр дөрес булыр — бәхетле еллар сизелмичә бик тиз үтеп китә. Бары тик еллар үткәннән соң гына уйлыйсың: бу тормышта булдымы, әллә төш идеме? Фатих Кәримов гаиләсе белән дә, хәер, аларныкы белән генә түгел, кайчандыр чәчәк атып утырган зур-зур авыллар: Өшәр, Чиялек, Урыс һәм Татар Әҗбие, Урдалы, Дербешка елгачыларының шәһәр кадәр бистәсе кешеләре белән дә шулай булды.

Авыл кешеләренә бәхетсезлек күктән төшкән кебек булды. Әйтерсең лә бер зур самолет-бомбардировщик алар өстенә үлем чәчеп китте. Ә гамәлдә исә бик гади генә иде. Чаллыда КамАЗның беренче чиратын файдалануга тапшыргач һәм Яңа шәһәрнең байтак өлешен төзегәч, СССР хөкүмәте Түбән Кама ГЭСы төзелешен тизләтергә карар бирде. Әзерлек эшләре өчен, шул исәптән су астында калачак авылларны күчерү өчен дә бик күп акча җибәрде.

Көннәрнең берендә колхозчыларның «бәлки, су басмас әле, изге туган җирдә яши бирербез» дигән хыяллары минуты белән юкка чыкты. Райком «Волга»сында Өшәргә КПССның Актаныш райкомы беренче секретаре Әхнәф Хәбибуллин җитәкчелегендә бик мөһим делегация килде. Аның составында беренченең хатыны, район Советы башкарма комитеты рәисе урынбасары Рәүфовна (районда аны шулай дип кенә атыйлар иде), ТАССР Министрлар Советының су басу зонасы идарә начальнигы һәм төзелә торган Түбән Кама ГЭСы вәкиле дә бар иде. Делегация колхоз клубы янына Өшәр халкын җыйды. Менә шушында инде район хуҗасы, зур күзләрен үгезнеке шикелле акайтып, бу авылның күчәчәге, моның өчен һәр хуҗалыкка бик күп акча биреләчәге турында әйтте. Урын сайлау һәркемнең үз иркендә икән, ләкин райком, автомобиль спидометры белән исәпләгәндә, моннан ун чакрымнар ераклыкта урнашкан Ямалы авылы янәшәсендәге калкулыкны тәкъдим итә.

Әллә инде шушындый хәбәрне җиткерү секретарь өчен бик авыр булды, әллә физиономиясе шундый идеме, ялкынлы нотыгыннан соң аның юан муенын, битен, күзләрен, чиертсәң бәреп чыгардай булып, кан басты. Әллә йөз-кыяфәте шундый булганга, район авылларында аны Үгез дип йөртәләр иде. Актаныш халкы бик телчән, кушаматларга, кеше исемнәрен кыскартып әйтүгә бик оста. Аңа бик дөрес бирелгән Үгез кушаматы бөтен гомеренә ябышты. Актаныш җирендә берничә ел секретарьлык иткәндә, бәлки, аны үзе белмәгәндер дә, ләкин шул кушаматы белән ул Казанга, чиктән тыш куәтле оешмага — КПСС өлкә комитетына китеп барды. Ул Татарстан Республикасының югары дәүләт постында эшләгәндә, журналистлар да үзара аны Үгез дип йөрделәр. Чыннан да, еллар үтү белән, ул тагын да тазара төште, бит тиресе шоп-шома булды, шулай итеп, ул испанлылар корридага чыгара торган үгезгә охшап калды. Ә хатынын аның гел шулай Рәүфовна дип атап йөрттеләр. Аны кушамат дип уйладылар булса кирәк. Аның исемен бу якларда берәү дә хәтерендә калдыра алмады.

Җыелыш бу якларда соңга калып килә торган язның кояшлы көнендә булган иде. Колхозчылар барыбер чәчәсен чәчтеләр. Милли бәйрәмебез — Сабантуйларын да уздырдылар. Халык теләр-теләмәс кенә күңел ачты, әйтерсең ул, үзен гаепле сизеп, ниндидер хезмәт йөкләмәсе үти. Ир-ат гомердә булмаганча эчте.

Хезмәткә яраклы халык иске елганың теге ягына печән чабарга киткәч, Өшәр техника белән тулды: чехларның кызыл экскаваторы, артына чүмечен, алдына кырдыргычын таккан «Беларусь», ике «КамАЗ» үзбушаткычы. Бу армаданы «ПАЗ» автобусы озата килде. Бөтен техника авыл читендә туктап калды, ә «ПАЗ» колхоз идарәсе белән авыл советы янына кадәр үтте. Автобустан өстенә төзүчеләрнең яшел формасын кигән илле яшьләр тирәсендәге бер ир чыкты. Блокнотына карап алганнан соң:

— Миңа авыл советы рәисе Ильяс Насыйров кирәк иде,— диде.

Контор бинасыннан чыккан кешеләр, очраклы рәвештә шушы тирәдә буталучылар автобуста килүчеләрне кызыксынып күзәтә башладылар.

— Авыл советы рәисе Ильяс Насыйровны кайда күреп була дип әйтүем,— дип кабатлады әлеге аксыл чәчле ир-ат. Ул, әлбәттә, татар кешесе түгел иде.

Бермәл тын гына торганнан соң, кызыксынып җыелып торучылар арасыннан берсенең тавышы ишетелде:

— Әнә монда таба килә...

Җыелып торучылар янына илле яшьләр тирәсендәге кеше килеп басты. Бу Бөек Ватан сугышы ветераны, әллә никадәр орденнар, медальләр алган, авыл советы председателе постына сайланган бик мөхтәрәм кеше Ильяс Насыйров иде.

— Нәмә булды? — дип сорады ул сагаеп кына һәм автобуска карап алды.

Теге аксыл чәчле ир-ат, бригадирмы, мастермы, шайтан белсен, менә шул килүчеләрнең җитәкчесе булса кирәк, авыл советы рәисе белән русча исәнләште дә мәсьәләне аңлатты:

— Сезнең авылны күчерү өчен Чаллыдан килдек. Беренчедән, яшәп тору өчен сез безне кая урнаштырырсыз икән?

— Клубка,— диде Насыйров, озак уйлап тормыйча.— Гомуми торак, кунакханә ишеләрнең бездә гомердә дә булганы юк.

Ильяс Насыйров урысча менә дигән итеп сөйләшә иде. Дүрт ел фронт тормышы юкка гына узмаган. Тегеләрнең башлыклары тагын алгарак чыгып:

— Башта зиратны күчерәчәкбез. Кайсысыннан башлыйк? Искесеннәнме, әллә яңасыннанмы?..— дип сорады.

Авыл советы рәисе агарынды, баскан җирендә авып китәрдәй булды. Авылларны су астында калдырганда иң алдан зиратларны, үле маллар күмелгән урыннарны күчергәннәрен ул яхшы белә иде, ләкин моңа әле тиз генә тотынмаслар, һич югында зур авылның юридик һәм фактик хуҗасы булганда бу эшне эшләмәсләр дип ышанып тора иде. Ильяс Насыйров, авылдашларының ачулануыннан, Алла каргавыннан куркып, ничәмә тапкырлар җаваплылыкны үз өстеннән алып ташлыйсы килде. Аны бу урысның, механикалаштырылган колонна җитәкчесенең, Өшәрдәге хәлләрне яхшы белүе гаҗәпләндерде. Хәер, гаҗәпләнәсе дә түгел, аның кулында Актаныш районының су астында кала торган авылларын күчерү турындагы технологик картаның күчермәсе бар ич.

— Так, кайсы зираттан башлыйк? — дип кабатлады соравын механизаторлар башлыгы.

Председатель, каты йокыдан кинәт уянып киткәндәй, сискәнеп куйды, ә аннары әрнүле рәвештә:

— Хәзер җирләнә торганыннан,— диде.

— Дөрес! — дип нокта куйды бу мәсьәләгә механизаторлар башлыгы.— Значится, бүгеннән яңа зиратка күмү тыела. Ямалы авылы зиратына күмәчәксез. Ә хәзергесен Бүләк авылы кырыена күчерәбез. Теләүчеләргә, якын туганнарының каберен белүчеләргә мәетне казып алып, яңа урында җирләргә ярдәм итәчәкбез. Ә инде хуҗасызлары, дөресрәге, онытылган каберләр барысы бергә, кем әйтмешли, колхозның туганнар зиратына күмеләчәк.

Авыл халкы, басып, дәшми генә тыңлап торды. Ишеткәннәрдән халык әллә инде шок хәлендә калды, әллә инде әле һаман аңнарына барып җитми иде, аңа каршы берсе дә чыгыш та ясамады, сүз дә әйтмәде.

— Йә, гражданин начальник, әйдә күрсәт кунакханәңне, клубны диюем.

— Киттек,— диде Ильяс Насыйров. Бу хәлдән аның тамагына төер утырган иде. Ул киттек дигән сүзен дә көчкәкөчкә генә әйтә алды һәм ашыкмыйча гына клубка таба юнәлде. Аның артыннан Өшәр авылын актарырга килүче иярде. «ПАЗ»ик автобусы да урыныннан кузгалды.

Авыл советы янындагы халык ничек тораташ кебек басып торган булса, шул килеш калды да.

Авылга килеп чыккан «коммунизм төзүче» Ильяс Насыйров белән тигезләнгәч, механизаторлар начальнигы ягына карамыйча гына сүз уңаеннан сорап куйды:

— Ни исемле соң?

— Минме? — дип сорады механизатор-актаручы. Аның авызыннан аракы исе килеп тора иде. Юлдашының җавабын көтеп тормыйча, үзе әйтте: — Лотяну. Иван Лотяну.

— Алай булгач, молдовандыр инде,— дип сүзгә кушылды председатель.

— Паспорт буенча урыс. Минем әти молдован булган, тумышы белән Бендердан.

— Мин Бендерны гитлерчы илбасарлардан азат итештем,— диде Ильяс Насыйров.— Ул тирәләрдә сугышлар галәмәт каты булды. Шунысын да әйтим әле, ул җирләрдән чигенгәндә гитлерчылар нәрсә бар, шуның бөтенесен җимерделәр, ә менә зиратка тимәделәр.

— Мин сугышта булмадым,— дип кырт кисте Иван.— Казахстан лагерьларында срок уздырдым. Экибастузны ишеткәнең бармы? Менә шунда. Гомумән, Бендерда минем беркайчан да булганым юк. Чын урыс җирендә, Орел янында туганмын, шунда үскәнмен. Тургенев урыннары турында ишеткәнең бармы?

— Бар,— диде Ильяс Насыйров.— Ул җирләрне дә гитлерчылардан азат иттем. Орел дугасы турында ишеткәнең бармы? Анда да ни гитлерчылар, ни совет сугышчылары кеше каберләренә тимәделәр. Шуның өстенә әле без, совет сугышчылары, вермахт сугышчылары каберләренә дә тимәдек.

Иван Лотяну дәшмәде. Бераз барганнан соң, Ильяс Насыйров, «син»гә күчеп, дәвам итте:

— Болай килеп чыга инде: мин синең кечкенә Ватаныңны чит ил басып алучыларыннан азат иттем, ә син минем туган оямны туздырырга килгәнсең.

— Әй, бугор! — Иван-актаручы кинәттән генә туктады. Битенә кызыллык йөгерде.— Әйдә пропагандасыз һәм сентиментальлеккә бирелмичә генә. Минем бригадага зиратны күчерү бурычы йөкләнде һәм менә мин ул эшне үтим дә. Төкерәм мин синең уфылдауларыңа, зарлануларыңа. Үземнең эшләү чорында, беләсеңме, мин Советлар Союзында күпме зират күчердем?!

Бригадир-актаручы хаклы иде. Ул күп еллардан бирле инде кабер күчерүчеләрнең, дөресрәге, кабер актаручыларның махсус бригадасына җитәкчелек итә. Бөек комсомол төзелешләрендә йөреп, гидроэ-

лектростанцияләрнең су басу, төзелә торган промышленность предприятиеләре зоналарындагы никадәр каберләрне күчергәннәр алар. Ул каберләр күчерү проблемаларына карата халыкара таләпләрне яхшы өйрәнгән. Аларга төзелеш объектларындагы югары квалификацияле монтажчыларга түләгәннән шактый артык түлиләр иде. Хәер, бик үк мактаулы булмаган бу эшкә гади кешеләрдән бик сирәкләре генә бара иде. Иван Лотяну үз эшен шәп белә, аны төгәл итеп вакытында башкара. Ул бу эштән үзен азат итүләреннән курка иде. Яхшы хезмәт хакыннан тыш Иванның өстәмә кереме дә барлыгын проектантлар һәм төзүчеләр арасында кем дә булса белә идеме икән: ул карга борыны белән мәетләрнең казналарында калган алтын һәм алтынга манылган коронкаларын суырып ала. Кайбер каберләрдә брошка, алка, йөзек кебек бизәнү әйберләре дә очраштыргалый. Кайчакларда Лотяну православие руханиларының зур тәресенә тап булгалады.

Шәп кенә итеп аракы эчеп алганнан соң, ачылып китеп, ул үзенең ышанычлыларына татарларның ярлы яшәүләре турында зарланды:

— Бөтен бер зиратны актарып чыгасың, ник бер алтын коронка, ник бер алтын балдак табылсын. Тәре турында монда уйларга да юк инде. Басурман басурман инде ул.

### *Җиденче бүлек*

Икенче көнне иртән үк Өшәргә «бобик»ка утырып райбашкарма комитеты председателе урынбасары Актаныш районының бөтен авылларын бетерү, юкка чыгару өчен җаваплы кешесе Рәүфовна — партия райкомының чиктән тыш көчле беренче секретареның хатыны килде. Ул халыкны авыл советы бинасы янына җыярга кушты. Халык бик тиз җыелды. Ул, Владимир Ильич Ленин революцион Петроградта Фин вокзалында броневикка менеп баскан сымак, авыл советы болдырына менеп нотык тотты:

— Тәк, кадерле өшәрлеләр! Авылны күрше Ямалыга күчерүне бик тиз башкарып чыгарга кирәк. Бу максатка бирелгән акчалар районга килде. Кемгә нәрсә кирәк — булышырбыз...

— Ну... Кемнең дә булса Ямалыга күчәсе килми икән, аны нишләтерсез? — диде алдагы рәттәгеләрнең берсе.— Әгәр сер түгел икән, кая, мәсәлән?

Рәүфовна, күзләрен кыса төшеп, сорау бирүче ир-атка карады.

— Мисал өчен, күрше Удмуртиягә, мәсәлән,— диде Фатих Кәримов, сорау бирүченең сүзләрен куәтләп.— Сарапул шәһәренә...

Авыл советы каршындагы мәйданда авыр тынлык урнашты. Рәүфовна да бер сүз әйтми торды. Ул килеп туган мондый ситуациядә ничек җавап бирергә кирәклеге турында уйлый иде бугай. Берничә минут шулай торганнан соң, Актаныш авылларындагы кешеләрнең язмышын хәл итүче Рәүфовна сорап куйды:

— Йә, андыйлар күпме? Кулларыгызны күтәрүегезне сорыйм.

Халык өстендә күтәрелгән куллар санап бетергесез иде. Авылдашларның күбесенең туган Актаныш районында каласы килми иде. Өшәр авылы кешеләренең үз районнарында гына түгел, хәтта туган Татарстанда да каласылары килмәде. Көчле империя үзәгеннән — СССРмы ул, Мәскәүме, РСФСРмы — үз халкын яклап кала алмаганга күрә, кешеләр үз хакимнәренә нәфрәт белән карадылар. Өшәр авылының гади кешеләре үз хакимнәрен аларның туган җирләрен юк итү, кабиләдәшләренә карата геноцид оештыру, ерткычларча каберлекләрне туздыру буенча җинаятьчел сүз куешуда гаепләделәр. Шуңа күрә дә авыл кешеләре артык купшы киенгән Рәүфовнаны яратмадылар.

Утызынчы еллар башында нәкъ менә шундый алласыз бәндәләр бүрәнәләп-бүрәнәләп мәчетне сүттеләр. Башта тантаналы төстә мәчетнең горур булып һавага ашып торган манарасын кистеләр. Ул авыл урамына уфылдап ауды. Гүя ул бу хәлнең бәхетсезлек, ачлык, бөлү булып Өшәр авылына кире кайтасын искәртә иде.

Безнең якларда бик аз кеше генә белгәндер, Өшәрдә ул турыда гомумән башларына да кертмәгәннәрдер: Актаныш районының Яңа Кормаш авылында укытканда, минем туган авылым Түбән Карач мәчете манарасын кисүдә нәкъ менә Хәбибуллинның әтисе катнашкан. Ул вакытта аны укытучы итеп шунда җибәргәннәр. Минем авылдашларым моны авылымны юкка чыгарып бетергәнче хәтерләрендә сакладылар. Балалар укытырга дип, Югары Уръядыдан безнең авылга җибәрелгән укытучы хатынны да онытмыйлар. Авыл тормышында бу кирәкмәгән элемент дип, ул Хәбибуллин белән бергә манараны аударган. Бу юлларның авторы сугыштан соң шушы мәчеттә укыды. Анда башлангыч мәктәп ясаганнар иде...

Актаныш райбашкарма комитеты рәисе урынбасары җыен шундый борылыш алыр дип һич тә көтмәгән иде. Нигездә, бөтен авыл Татарстанда калудан баш тартты. Күрше Ямалы авылы янындагы калкулыкка күчү өчен бары берничә кул гына күтәрелде. Алар олы яшьтәге картлар, карчыклар иде. Аларның читтә таянып беркеме дә юк. Нишләсеннәр, әйткәнгә буйсынмый хәлләре юк. Ямалыга күчү өчен кул күтәрүчеләр арасында берничә авыл куштаны, җирле начальство тирәсендә йөреп, гомуми байлыктан үзләренә өлеш чыгаручылар да бар иде.

Бу хәлләрдән каушап калган Рәүфовна сүзен дәвам итте:

— Көчләп бирәүне дә тотмыйбыз. Теге вакытлар узды. Актаныш районыннан читкә китүчеләр тиешле компенсация алырлар, кем әйтмешли, һәркемнең үз ирке. Акчаны өлешләп шушында, авылга китерәчәкбез. Ямалыга күчәргә теләүчеләр анда барып авыл советында җир участокларын билгеләтергә тиешләр.

Рәүфовна янында Иван Лотяну да басып тора иде. Башкарма комитет рәисе урынбасары, үзенең ялкынлы нотыгын төгәлләп, болдырдан төште дә райкомзем хезмәткәрләре белән бергә, «бобиг»ына утырып, зиратка урын эзләргә дип, Бүләк авылына китте. «Бобик» артыннан Иван Лотяну автобусы да кузгалды. Яңа зиратта эшләү өчен чех экскаваторын да шунда җибәрделәр. Ә җыендагы халык дәррәү кубып хәзерге көндә мәетләр кабул итә торган зиратка, якыннарының каберләрен эзләргә китеп барды.

Хәзерге һәм иске зиратларны күчерү турындагы хәбәр тирә-юньгә генә түгел, хәтта бик еракларга таралды. Зиратта халык байтак иде. Өшәрдән дә, якын-тирә авыллардан да килгәннәр. Бу аңлашыла да, чөнки кайберләре нindидер сәбәп белән башка авылга күчеп киткән, кызларның кайберләре чит авыл егетләренә кияүгә чыкканнар. Кичкә таба хәзер Сарапулда яшәүче элеккеге авылдашлар кайттылар. Барысы да якыннары күмелгән урыннарны эзләделәр. Шушы кайгылы сәбәп аркасында озак вакытлар күрешмәгән туганнар, якыннар очрашып сөйләштеләр. Шушы кайгылы очрашу Өшәр авылы кешеләренә зиратның ташландык хәлдә икәнен дә күрсәтте. Татарлар чыннан да Ислам кануннарын бик үк дөрес аңламауданмы, якыннарының, туганнарының каберләрен карап, тәртиптә тотмыйлар шул. Бүген ул турыда уйларга соң иде инде. Туганнарының каберләрен табарга кирәк. Бу эш бик үк җиңел булмады, чөнки күп кенә каберләр өстендә ташлар да, башка билгеләр дә юк иде.

Кичен Өшәр авылы клубы-кунакханәсенә кайтканда, механизаторлар яңа җирдә туганнар каберлеге өчен зур чокыр казулары, билгелеләре өчен аерым-аерым урыннар әзерләүләре турында сөйләделәр.

Өч көннән соң экскаватор Өшәргә әйләнеп кайтты һәм зират кырыенда туктады. Авыл халкы җир казучы техникага эшләргә ирек бирмәде. Күбесе якыннарының каберләрен көрәкләр белән казырга керештеләр. Бик газаплы эш иде бу. Күптән түгел күмелгәннәрне елый-елый кабердән чыгаралар да тактадан махсус әзерләнгән әрҗәләргә, тартмаларга салалар. Унбиш-егерме ел элек җирләнгәннәрне, дөресрәге, аларның сөякләрен капчыкларга тутыралар. Зиратта берничә көн дәвамында ыңгырашкан-елашкан тавышлар гына ишетелеп торды. Туганнарының мәетләрен яңа урынга илтеп, яңа кабергә күмделәр. Гыйбадәт кылдырыр өчен үзлегеннән өйрәнгән муллага чират тордылар.

Зират бушап калды. Анда күңелне борчый торган тынлык урнашты. Бу мәйдан әле яңа гына зур сугыш үткәнне хәтерләтә иде, андагы күренеш нәкъ бомба төшеп шартлаганнан соң хасил булган чокырлар, окоплар кебек иде. Зираттагы гаять зур тупылларда үзәк өзеп каргалар каркылдый. Тагын да авыррагы — билгеле булмаган авылдашларның каберләрен ачып, сөякләрен «КамАЗ» үзбушаткычы кузовына төяү калган иде. Иван Лотяну үз эшен менә дигән итеп белә. Ул рулетка-үлчәгеч белән каберләрнең арасын үлчи, аннары каберне каян казырга кирәклеген күрсәтеп металл таяк кадый:

— Шушыннан казы!

Чехларның шәп сыйфатлы бульдозерлары, двигатель әйләнешен бер арттырып, бер киметеп, әллә нинди улаган тавышлар чыгарып, үзенең чүмеч тырнакларын вакыт үтү белән шактый тыгызланырга өлгергән кабер җиренә батыра башлады. Чүмече белән бер-ике тапкыр туфрак алуга, җир өстендә кеше сөякләре күренде. Иван Лотянуның каберчеләр бригадасы әгъзалары аларны, чиләктән зуррак бер савытка җыеп, бераз арырак туктаган «КамАЗ» үзбушаткычына илтә тордылар. Кабер актаручыларның берсе, машина әрҗәсенә басып, савытны кабул итә һәм тимер кузовка шалтыратып бушата. Өшәр авылының өлкән кешеләре бу вакханалиягә карый алмадылар. Шуңа күрә зиратта күренмәделәр дә. Җир казучы техника янында берничә малай гына йөри иде, Иван Лотяну аларны чебен куган кебек кенә куып җибәрде. Бүләк авылында кеше сөякләре салына торган туганнар каберлеге янында картлар гыйбадәт кылалар, намаз укыйлар, туздырылган каберләр өчен, үлгән кешеләрнең җаннарын кузгаткан өчен Аллаһы Тәгаләдән гафу үтенәләр, чын күңелләреннән җитәкчеләргә, аларның хатыннарына акыл бирүне сорыйлар. Бүләк авылы янындагы зиратта картлар гыйбадәт кылалар икән дигән сүзләр килеп ирешкәч кенә, өшәрлеләр бераз тынычландылар.

Бер атна дигәндә бу зират белән эшне төгәлләделәр. Өшәр авылы читендә ергаланган, яраланган җир генә ыңгырашты, зур-зур тупыллар, каеннар, тамырлары белән йолкынып, шул мәсхәрәләнгән җир өстенә ташландылар.

Бу зиратта эшне тәмамлау уңаеннан Иван автобустан бер ящик аракы сөйрәп чыгарды, ашамлыклар китереп куйды һәм үзенең «социалистик төзелеш» алдынгыларын сыйлый башлады. Шәп кенә салып алганнан соң, җирдәге ак бер нәрсәне аягы белән тибеп җибәрде. Ул кемнеңдер баш сөяге булып чыкты. Аннары Иван вакыт үтү белән саргая башлаган бу баш сөяген кулына алды, үлән белән сөрткәләде. Бераз аракы салып чайкады. Аны түгеп, янә шунда аракы салды. Иптәшләре кулындагы кырлы стаканнар белән чәкештерде дә эчеп җибәрде һәм коточкыч бу савытны чокырга томырды.

— Үлгәннәрдән түгел, исәннәрдән куркырга кирәк,— диде бригадир тантаналы кыяфәттә.— Табут казып чыгаручылар яшәсен!

Берничә минуттан соң өстәп куйды:

— Нинди табут казып чыгаручылар инде без бүген. Мөселманнарны табутсыз күмәләр ич. Без бүген кабер казучылар гына.

Үзенең тост-нотыгын Иван Лотяну ниндидер бер ризасызлык белән тәмамлады:

— Алай да татарлар начар яшиләр. Бөтен зиратны актарып чыктык. Нибары ике алтын коронка.

Өшәрдә һәм Бүләк авылында зират актарган көннәрдә җитәкчеләр кешеләрнең каберләрен, бәндәләрнең ояларын, аларның тарихын туздырган өчен Алладан шәфкать-мәрхәмәт тә сорамадылар. Аларның үзләренең «Без үзебезнең элекке һәм хәзерге халыкларыбыз сөякләрендә яңа дөнья төзиячәкбез» дигән принциптагы үз диннәре бар иде. Аларның хәзер диннәре башка, яңача. Бервакыт алар динне коммунистик рухтагы иблискә сатканнар иде, аннары аны икенче дин, шул ук халык исәбенә баю дине хакына саттылар. Хәзер алар алтын бозау дине буенча гыйбадәт кылалар.

### *Сигезенче бүлек*

Маньчжуриядә япон самурайлары белән сугышларда катнашкан колхоз механигы Фатих Кәримов зиратны туздыру кебек вакханалияләрдән читтә торды. Авылдашларының мәетләрен казып ала башлагач, аның йөрәге әрнеде. Күңелендәге иске яралары ачылды. Әле дә булса исән-сау яшәүче, тыныч холыклы, шәфкатьле әнкәе Фәрхикамал ир һәм кыз туганнары, хәбәрсез югалган әтиләре сөякләрен башкалар белән бергә күчерә алмауларына рәнҗеделәр. Әтиләренең кайда ятканын гаиләдәгеләр белми. Гомумән, кешечә җирләндеме икән әле ул? Россия җирләрен гитлерчы илбасарлардан азат итү өчен барган канлы сугышның дәвамы бу гаиләне рәхимсез рәвештә сөякле куллары белән эләктереп алды. Әтиләре үз авыллары зиратына җирләнгән булса, алар да аны, башкалар кебек үк, Бүләк авылы читендәге зиратка күчереп күмәрләр иде.

Фатихның әнисе зират күчерү вакыйгасын аеруча авыр кичерде. Өйнең бер почмагыннан икенче почмагына йөрде, ятты да тагын торды, авыр сулады. Менә ничәмә мәртәбәләр инде ире белән сарык ите сатарга дип, Дербешкага баргач төшкән бердәнбер карточкага карады. Юк, ул еламады. Яше юк иде. «Хәбәрсез югалды» дигән кара тамгалы кәгазьне алгач, сугыш бетеп Җиңү көненнән соң авылдашлары кайсы исән-сау, кайсы яртылаш исән килеш кайта башлагач, ачлык елларында берүзе биш бала тәрбияләп үстергәндә, аның күз яшьләре беткән иде инде.

Сугыштан соңгы беренче елларда ук ябылган, ташландык хәлендәге зиратны актаруга керешкәнче, экскаваторчы яңа урындагы туганнар каберлеге өстенә туфрак сипкәләде. Иске зиратны куаклыклар, кеше биеклегендәге алабута һәм киндераш баскан. Ничәмә дистә еллар инде монда кеше аягы басмаган, зиратлар актаручы Иван Лотянуга монда рулетка-үлчәгеч белән үлчәп торуның мәгънәсе юк иде. Ул экскаваторчыга барысын бергә казырга кушты. Механизатор ярсып-ярсып эшләде, җир өстендә сөякләр күренгәндә генә туктап алгалады. Бу юлы, кызыксынып, иске зиратка Фатих Кәримов та килде. Биредә ул үзе шикелле үк кызыксынып йөрүче берничә авылдашын очратты. Бу зиратта аның әтисе ягыннан әбисе белән бабасы күмелгән иде. Бәлки, борынгы бабалары да мондадыр. Ул аларның кая күмелгәнен белми. Ләкин зур кызыксыну белән экскаваторның эшләгәнен, ярым исерек Иван Лотянуның ары-бире йөргәнен карап торды. Вакыты-вакыты белән бу коточкыч машинаның чүмече каберләрдән кочагы-кочагы белән ак сөякләр казып чыгарды. Аларны туфрактан аралабрак җир өстенә китереп салды. Төрле җирдә аунап ятучы ак сөякләр күзгә урман аланындагы гөмбәләрне хәтерләтә иде.

Җир астыннан чыгарыла торган сөякләр хәзергеләрнекенә караганда шактый эрерәк икән, дигән фикергә килде Фатих. Мөгаен, ул чор кешеләре хәзерге совет кешеләре токымыннан эрерәк булган. Өенә кайткач, ул бу фикере белән әнкәсе Фәрхикамал белән дә уртаклашты. Әнисе:

— Әйе, улым. Элекке заманда кешеләр эрерәк сөякле иде,— дип раслады.

Кабер актаручылар иске зиратта да эшне тәмамладылар. Туганнар каберлеген генә төгәллисе калды. Көн уртасында Бүләк авылы читендәге яңа зиратка бик күп халык җыелды. Ун чакрым ераклыкта булуга карамастан, Өшәрдән һәм башка күрше авыллардан олысы-кечесе килгән иде. Мөселман гадәтләрен ахыргача онытып бетермәгән картлар, үлгән туганнарына, якыннарына багышлап, җыелышып намаз укыдылар. Гаҗәпкә каршы, Лотяну аек иде. Намаз укып бетергәннән соң, ул туганнар каберенең гадәттән тыш зур чокырын күмәргә экскаваторчыга әмер бирде. Эшне «Беларусь» бульдозеры төгәлләде. Эшлисе эшләр эшләнеп беткәч, Иван Лотяну үзенең гадәти булмаган чыгышы белән гаҗәпкә калдырды. Ул җыелган халык алдына чыкты да, калтыравыклы тавышы белән:

— Иптәш мөселманнар, гафу итегез безне. Бу таркатуда безнең гаеп юк,— диде.

Барча халык тирән сулап куйды. Мөселман татарлары арасында да, кабер казучылар арасында да район, республика оешмаларыннан һәм учреждениеләреннән, авыл советы рәисе фронтовик Ильяс Насыйровны санамаганда, беркем дә юк иде. Очына чыккан район чиновниклары «Үлеләргә ничек тә ярдәм итә алмыйсың икән, тереләрне сакларга кирәк» дигән канунны онытканнар иде бугай.

Кабер эшләре осталары берничә көнгә Өшәрдән юкка чыгып тордылар. Эшләрен тиешенчә башкарганлык хисләре белән алар берничә көнгә ялга, гаиләләре янына кайтып киттеләр. Бер атнадан ки-

ре килделәр һәм үле маллар күмү урынын күчерүгә керештеләр. Анда күп еллар буена тирә-юнь колхозларның төрле авырулардан, бигрәк тә себер түләмәсеннән үлгән малларны күмделәр. Кабер актаручылар Өшәргә кире килү белән, берничә чиновник һәм ике милиционер озатуында ике «бобик» белән райбашкарма комитеты председателе урынбасары Рәүфовна килеп төште. Авылдан күчүчеләр өчен Рәүфовна акча алып килгән икән дигән хәбәр таралды. Авыл халкы, чакырып торуны көтмичә, тагын авыл советы каршындагы мәйданга җыелды. Купшы киенгән Рәүфовна тагын «казенный йорт»ның болдырына менеп басты һәм, алпавыт үзенең крепостнойларына караган кебек, җыелган кешеләр өстеннән күз йөртеп чыкты. Начальницаның як-ягына кобура таккан ике милиция баскан иде. Рәүфовнаның артыннан түбәнрәк чиндагы чиновниклар карап торалар. Бу күренеш үзенә күрә көлкеле дә иде: бер карасаң, халык өстеннән суд барган шикелле, икенче караганда, Хәбибуллинның үзен хөкем итәләр кебек, як-ягында җинаятьчене саклагандай ике милиционер басып тора.

— Тәк,— дип мөрәҗәгать итте Рәүфовна халыкка,— кем дә кем даими яшәү өчен күрше Ямалыга күчә, колхозчылар арасыннан чыгып сул якка басыгыз.

Өлгергән вакытында арыш басуы җил исүдән ничек дулкынланса, җыелган халык та шулай чайкалып куйды. Галәмәт күп халык арасыннан ике дистәгә якын колхозчы чыкты. Калганнары дәшмичә генә баскан урыннарында тик тордылар.

— Аңлашылды,— дип раслады Рәүфовна.— Йә, кайсыларыгыз Сарапулга күчәргә ниятләде? Андыйлар уң якка күчсеннәр.

Кешеләрнең төп массасы көчле диңгез дулкыны кебек уң якка күчте.

Күрше республикага күчәргә теләүчеләр күпчелек иде.

— Кы-зы-ык,— диде Рәүфовна, үткәргән чараларына йомгак ясап, һәм дәвам итте: — Кем Ямалыга күчәргә карар кылды, шуларны авыл советы рәисе бүлмәсенә керергә чакырам. Күчү өчен компенсация алырсыз.

— Ә без, Сарапулныкылар кайчан алачакбыз? — дип кычкырдылар сул яктагылар арасыннан.— Безгә тоже салкыннарга хәтле күчәргә кирәк бит...

— Сез бераз сабыр итәрсез,— диде Рәүфовна, зәһәрлеген яшерә алмыйча.— Сезгә тотнаклыкка вакыт бирелә. Бәлкем, туган җирегезне ташлап китүдән баш тартырсыз.

— Без китмәгән булыр идек, сез безне куасыз,— дип кычкырдылар уң якта торучылар.— Бу безнең җир, бабаларыбыз җире... Сез безне мәсхәрәлисез.

Танкист үзенең бронялы машинасына кереп киткән сымак, Рәүфовна да авыл советы ишеге уемына кереп күздән югалды.

— Тынычлануыгызны сорыйбыз,— диде милиционерларның берсе.— Тыныч кына өйләрегезгә таралышыгыз. Сезнең чират та җитәр.

Акчаларны биргәннән соң, Рәүфовна тиз генә милиционерлары һәм чиновниклары белән «бобик»ларга утырып авылдан чыгып китте.

Фатих Кәримов өенә кичке якта гына кайтты. Алар хатыны һәм инде шактый картайган әнисе белән бергә яшиләр иде. Олы кызлары Рәзилә һәм өлкән уллары Зөфәр шушы ук авылда үз гаиләләре белән яшиләр һәм оныклар үстерәләр иде. Кече уллары Рәшит Совет Армиясендә иде.

Фатихның хуҗалыгы нык иде әле. Өенең өч тәрәзәсе үзәк урамга карап тора. Берара ул ишегалды ягыннан янкорма да төзеп куйды. Анда алгы бүлмә, аш бүлмәсе ясады, эченә җылыту казаны урнаштырып, пөхтә генә мич утыртып куйды. Зал буйлап зур диаметрлы торбалар уздырды. Мичне алар тәүлеккә ике тапкыр ягалар иде: иртән һәм кич. Бу бурап эшләнгән зур йортны коры һәм җылы итеп тоту өчен җитә иде.

Ә менә хәзер власть тотучыларга нык үпкәләп, ул да, күпчелек авылдашлары кебек, күчәргә ниятләде. Ике дистә елдан соң аңа өен, бүрәнәсен бүрәнәгә сүтеп, Сарапулга илтергә кирәк иде. Нәрсә эшләргә соң? Күчерү өчен бит әле башта аның җир участогын алырга кирәк. Фатих берничә мәртәбә Сарапулга барып килде. Үзенең авылдагы хуҗалыгын күчереп утыртырлык җир участогы булган искереп беткән йортларны карап йөрде. Старцево тавындагы Раскольников белән Коры үзәнлек урамнары кисешкән җирдәге борын-борыннан һичкем ала алмаслык крепость дип саналган Сарапул төрмәсе белән янәшә урынны ошатты.

Тузган йортлы бу участок өчен әллә ни күп сорамадылар. Ләкин тиз генә каян аласың әле аның акчасын. Күченү буенча тиеш булган компенсация түләүләрен халыкка «игелек күрсәтүче» Рәүфовна һаман тоткарлап тора иде әле. Өенә кайтып, ул бөтен мал-туарын: сыерын, ун айлык үгез бозавын, бөтен сарыкларын, казларын, хәтта тавыкларына кадәр суйды. Нык хуҗалыклы дип саналган Фатихның ишегалдында хайваннардан бары бер Спутнигы, өендә Вася атлы мәчесе генә калды. Дистәләгән еллар буена чын хезмәтчәннәр яшәгән, хайваннарны, кош-кортларны чын күңелдән сөйгән йорт өчен бу коточкыч көннәр иде. Ишегалдында кинәттән генә сыер, үгез бозау мөгрәүдән, сарыклар бәэлдәүдән, тавыклар кытаклаудан, казлар каңгылдаудан туктасыннар әле?! Бу коточкыч бушлык ишегалдында, лапаста гына түгел, иң борчыганы — эчпошыргыч бу бушлык өйдәгеләрне чарлады, йөрәкләрен яндырды. Дөньяда күп нәрсәне күргән, күп еллар дәвамында коммунизм төзелешенең бөтен авырлыкларын үз

җилкәсендә татыган Фәрхикамал карчык бигрәк тә хәсрәтләнде. Фәридә, тормыштагы бу трагедияне эченә йотып, кайгысын иренә дә, бианасына да күрсәтмәскә тырышты. Фәрхикамал әби аңа үз анасы кебек кадерле иде. Авыр, билгеле. Менә шушындый тыныч вакытта, тормышлар җайланып киткән чорда туган ояңны ташлап китәргә мәҗбүр итсеннәр әле?! Фәридә өлкән кызы белән улы гаиләләре өчен дә эчтән генә бик кайгырып йөрде. Ул аларны вакыты-вакыты белән шәһәргә күчмәскә дә күндереп карады. Янәсе, шушы кечкенә Ватаныбызда калырга да башка кайберәүләр кебек Ямалыга күчәргә кирәк.

— Минем нервыга тимә, Муля! — Ачуланганда Фаина Раневскаяның экраннан ишеткән сүзләрен кабатлый иде Фатих.— Минем туган авылымның, яраткан болыннарымның, гомерем буе эшләгән кырларымның, әтием туып-үскән оҗмахтай урыннарның сасы сазлыкка әйләнүен күрәсем килми. Мин аңа түзә алмаячакмын.

Фатих бөтен итне дә Сарапул базарында сатып бетерде. Тузган йорт өчен алдан бераз акча биреп куйды. Шуннан соң шәһәргә үзенең «копейка»сын — «Жигули»ның беренче моделен алып килде. Аңа аны моннан дүрт ел элек колхозның алдынгы механигы булганы өчен сатканнар иде. Сарапулда күптәннән яшәүче авылдашыннан бераз бурычка алып торды һәм төрмә янындагы Старцево тавындагы утар өчен исәп-хисапны тулысынча өзде. Хәзер инде авылдагы өйне генә шәһәргә күчерәсе калды. Ләкин тагын акча каян алырга?! Рәүфовна компенсация акчасын бирүне һаман сузды.

Агыйдел буеның сумала шикелле өч мең гектардагы кара туфраклы җирләре кышка сөрелмичә, икенче төрле әйткәндә, ташландык хәлдә калды. Мең баш терлекне башка колхозларга тараттылар, кайберләрен суйдылар. Ашлыкның бер өлешен заготзерногa тапшырдылар, бер өлешен тараттылар, урлап бетерделәр. Җәен әзерләнгән печәнне кибәнләп Актаныш районының башка хуҗалыкларына бүлеп бирделәр. Менә шулай итеп, элеккеге нык колхозны туздырдылар да бетерделәр.

Фронтта ир-атларның үлү кайгыларын кичергән, сугыштан соңгы еллардагы ачлыкларны күргән халык Түбән Кама ГЭСының суы килүе уңаеннан мәсхәрәләүләргә, төрлечә кысуларга түзә алмады, күпләп-күпләп туган җирләрен ташлап, күрше республикага күчә башлады. Өшәр авылы кешеләре белән бергә Татар Әҗбие дигән авыл, һәрвакыт тормыш кайнап торган Дербешка пристане һәм затоны, Урыс Әҗбие, Чиялек һәм Урдалы авылы кешеләре дә көчләп күчерү трагедиясен үз башларыннан кичерделәр.

Меңләгән гектар уңдырышлы җирләр, менә дигән болыннар, ташланып, Түбән Кама ГЭСы суы килеп үзләрен сазлыкка әйләндергәнне көтеп калдылар.

Сүз дә юк, күчерелергә тиешле авылларның күпчелек кешеләре Чаллыга, Түбән Камага китә алалар иде. Юк, аларның туган Татарстан җирләрендә каласылары килмәде. Туган җирләрдән куылу үпкәсе көчлерәк иде.

Күрше Ямалы авылына китәргә ниятләгәннәрнең китәсе китеп бетте: берәүләре өйләрен күчерделәр, икенчеләре яңа йорт салып керделәр. Андыйлар өчен Актаныш райбашкарма комитеты председателе урынбасары иң беренче ярдәмче булды. Хәер, ул шулай булырга тиеш тә иде инде.

Өшәр авылында, нигездә, күрше Удмуртия Республикасына, Сарапулга күчәргә ниятләгән кешеләр калды. Фатих Кәримов та кышны үзенең гаиләсе белән туган йортында үткәрергә булды.

Көтмәгәндә тагын күк күкрәп алды. Авылда үзенең Рәүфовнасы һәм берничә чиновник озатуында, шулай ук «техпомощь» автомобилен ияртеп, райкомның беренче секретаре Әхнәф Хәбибуллин килеп төште. Халыкка авыл советы янына җыелырга кушылды.

Хәбибуллин күп сөйләп маташмады, бары шуны гына әйтте:

— Кадерле иптәшләр! (Искә алыгыз, кадерле, имеш.) Бүгенге көннән башлап үз язмышыгыз үзегезнең кулыгызда.

Болдырга авыл советы рәисе Ильяс Насыйров күтәрелде. Ул бары берничә сүз әйтергә генә өлгерде:

— Туганнарым, авылдашларым! Бу безнең ахыргы очрашу. Сау булыгыз! Бәхил булыгыз!

Йөрәген тотып, ул ава башлады. Аны тотып алырга өлгерделәр һәм җиргә яткырдылар. Мәсхәрәләүләргә, кысуларга фронтовикның йөрәге түзмәде. Кайсыдыр авыл советы рәисенә ясалма сулыш алдырды, кемдер тел астына таблетка салды. Аңына килеп, бераз рәткә керә башлагач, аны район «бобиг»ында өенә илтеп куйдылар.

— Акча! Акча! — дип кычкырдылар элеккеге колхозчылар.

— Алырсыз! — диде беренче секретарь һәм, сүзләрен раслагандай, үгезнекедәй башын селкеп куйды. Шул ук минутта үзенең Рәүфовнасын райком «Волга»сына утыртып китеп тә барды.

«Техпомощь» автомобиле электрподстанциясе янына килеп туктады. Аннан электриклар чыктылар да авылга ток бирүне туктаттылар. Аннары электромонтерлар планлы эшкә — өйләр янындагы чыбыкларны кисәргә керештеләр. Алар шашып-шашып каргаборын белән электр чыбыкларын кистеләр һәм, ниндидер бер тизлек белән чолгап, аларны озата килүче үзбушаткыч машинаның әрҗәсенә ыргыта бардылар. Караңгы төшкәнче Өшәр авылын тулысынча электр утыннан мәхрүм иттеләр. Бары тик терлекчелек биналары калдыкларында, элеккеге клубта һәм кибеттә генә чыбыклар эленеп калды. Кич булды. Авылга караңгылык, мәңгелек караңгылык, урта гасыр караңгылыгы килде.

### *Тугызынчы бүлек*

Тактадан эшләнгән «дача» йортындагы зәмһәрир суыктан механизаторлар бик иртә, икесе берьюлы диярлек уяндылар. Рамил трусиктан гына буржуйка янына килеп шырпы сызды. Буржуйка өстендәге кәстрүлдә су каткан иде.

— Ох-хо-хо! — диде калтырана-калтырана Рамил.— Йоклаганда күшегеп, катып үлүебез шушында була язган ич.

Мирсәет тә торды. Кичтән керткән утыннары белән алар икәүләшеп буржуйканы бик тиз кабызып җибәрделәр. Мичтән чыккан ялкын телләре «робинзоннар»ның торагын яктыртты. Кәстрүлдәге боз да бик тиз эреде һәм кайнап чыкты. Аларның әле пакетлы чәйләре калган иде. Агач караватларына утырган килеш, бокалларына өрә-өрә, кайнар чәй эчә башладылар. Өй дә беркадәр җылынды. Бердәнбер тәрәзәнең пыяласы пар белән капланды. Кайнар чәй эчкәннән соң, аларга хәтта эссе булып китте. Тышта таң беленә башлаган иде. Рамил белән Мирсәет өсләренә киделәр дә өйләреннән чыгып киттеләр. Төньяктан салкын җил исә иде. Урамда суык. Беренче булып Мирсәет сүз башлады:

— Кызык, безнең бабай тегендә нишли икән? Әйдә Агыйделгә таба...

Механизаторлар елга буена килеп җиткәндә, тышта тәмам яктырган иде инде. Тирә-юньдә авыр тәэсир калдыра торган тынлык. Агыйдел кышкы ялга туктаган. Бер ярыннан икенче ярына хәтле аны боз каплаган. Ул тигез түгел иде. Елгада боз, кар кисәкләреннән торган сил ничек аккан булса, су шулай каткан. Еракта, елганың түбәнге агымында катмаган урыннар да күренгәли. Аннан сыек кына ак пар күтәрелә. Беренче кар яумаган иде әле. Аның каравы Агыйделнең ике як ярындагы агачлар әкияттәге кебек ап-ак бәс белән сарылганнар. Беренче карашка алар ниндидер ак челтәр ябынган сымак күренделәр.

Механизаторлар игътибар белән каршы як ярны күзәттеләр. Карт та, аның эте дә күренми. Агыйдел аша чыгу мөмкин түгел иде әле. Боз бик юка һәм уалучан. Җәяүләп чыгу өчен дә кимендә ике көн көтәргә кирәк. Рамил белән Мирсәет яр буйлап бер сәгать чамасы йөрделәр. Карт та, эт тә күренмәде.

— Бабай, бәлкем, авыргандыр? — Рамил Мирсәеткә карап куйды.

— Шулай булуы да бик мөмкин,— диде Мирсәет.— Может алар кирегә, Агыйдел шәһәренә таба киткәннәрдер?

— Авырса, эш шәптән түгел, әлбәттә,— диде уйга калып Рамил.— Алай дисәң, ни өчен эте күренми?

Алар фараз кылганча, землянка булган урында җан әсәре барлыгы сизелми иде. «Җир асты патшалыгы» торбасыннан төтен чыкканы да күренми.

Механизаторлар үзләренең өйләре кырыеннан каршы якка, иске елга ярына таба киттеләр. Агыйдел ярына алар соңрак килергә булдылар. Иске елганың теге як ярында эте белән Габдулла басып тора иде. Елганың икенче ягында чит кешеләрне күреп, аның эте зәһәрләнеп өрә башлады. Бу урында ермак бик киң түгел иде. Аннан соң аның бозы да, Агыйделнекеннән аермалы буларак, тип-тигез булып каткан, әйтерсең боз сараеның үрнәк мәйданчыгы иде. Ләкин ымсындырып торучы бу шугалак өстеннән барырга иртәрәк әле. Көтмәгәндә боз астына төшеп китүең мөмкин. Иң киме бер тәүлек булса да көтәргә кирәк, анда да әле бүгенгедәй суык торса.

— Ни хәлләр? — дип кычкырды теге як ярдан Габдулла.— Ачка үлмәдегезме әле?..

— Без ничава,— дип җавап бирде Мирсәет.— Иртәгәләргә кунакка көт.

Габдулла белән механизаторлар әйбәт кенә сөйләшеп аңлаштылар. Бөтен сүзләре ишетелде, аңлашылды. Сүзгә тагын Рамил кушылды:

— Без ничава, вәт бабаебыз чаво-то югалды.

— Нинди бабай тагын? — дип сорады Габдулла теге яктан.

Механизаторлар, бер-берләрен бүлә-бүлә, Агыйделнең теге ягындагы карт һәм аның эте турында сөйләделәр. Аның «өшәр», «ләргә», «үләргә» дигән сүзләрен әйттеләр.

— Кем икән ул? — диде Габдулла уйга калып.— Безнең якта бер кеше дә үлмәде...

Боз белән капланган иске елга аша шулай бераз сөйләшкәч, Рамил белән Мирсәет үзләренең өйләренә, Габдулла, этен ияртеп, үз хуҗалыгына кайтып китте.

Өй тагын нык суынган иде. Ир-атлар утын ташыдылар да тагын буржуйканы ягып җибәрделәр. Әрчемичә генә бәрәңге пешерделәр. Ипи тәмен инде алар оныттылар. Бәрәңгене ашап бетергәч, яттылар да йокыга да киттеләр.

Рамил белән Мирсәет тиздән тордылар да Агыйдел буена киттеләр. Көн кичке якка авышты. Елганың ике ягында да җан ияләре юк иде. Мирсәет кулларын, рупор ясап, авызына якын китерде һәм бар көченә кычкырып җибәрде:

— Бабай, исәнме син?

Берничә секундтан Мирсәетнең сүзләре кайтаваз булып бу якта яңгырады: «Бай-бай, сәнме, сәнме...» Теге як ярдан җавап бирүче булмады. Арлы-бирле йөргәннән соң, механизаторлар үзләренең такта йортларына кайттылар.

Ә бу вакытта Фатих чыннан да авырган иде. Ул, үзенең кайсы җире авыртканын да белмичә, йокымсырап ята иде. Башы да авыртмаган шикелле, йөрәк-моторы да артыгын типми, эчендә дә берни борчымый сымак. Ләкин аның ашыйсы да, эчәсе дә килми. Землянка караңгылыгында ул вакыт исәбен дә югалтты. Бары бер тапкыр, сихәтсезлек башланган бер вакытта гына коры утыннар ташып куйган иде. Буржуйканы ягып, Спутнигын икмәк һәм колбаса кисәге белән сыйлады. Үзе эчмәде дә, ашамады да. Җир астында чагыштырмача җылы иде. Ул солдат бушлатына төренде дә, колаклы бүреген батырып киеп, печән өстенә менеп ятты һәм үткән тормышы турында уйлый башлады. Вакыты-вакыты белән рәнҗүдән, аңлашылмый торган сагыштан ул елап алды. Чынлыкта исә аның күзләре коры иде, картның җаны сыкранды. Еш кына ул, онытылып, яшәештән юкка китеп баргалады. Спутнигының шыңшуыннан аңына килгәләде. Җанвар хуҗасының хәлен аңлый иде. Карт аңына килгәч, эт тә шыңшуыннан туктый.

## *Унынчы бүлек*

Электр чыбыкларын кисеп алганнан соң, Өшәр авылы кешеләре моннан ике дистә еллар элек җыеп куелган иске керосин лампаларын эзләргә керештеләр. Шәме булганнар шуны кабыздылар, кайбер йортларның тәрәзәләрендә саргылт ут яктысы күренде, ә күпчелек тәрәзәләр утсыз иде. Иртән авылга тагын бер кайгылы хәбәр таралды. Төнлә авыл советы рәисе Ильяс Насыйров үлгән. Элеккеге фронтовикның йөрәге түзмәгән. Ул бик тәртипле, ихтирамлы кеше иде авылда. Һәр кеше өчен борчыла, кайгыра иде.

Ильяс Насыйров өе янына бөтен авыл халкы җыелды. Өй эчендә бары картлар гына иде. Алар мәрхүмнең, алыштыргысыз авыл советы җитәкчесенең, гәүдәсен юдылар, Коръәннән аятьләр укыдылар. Аның үзен дә әле шушы көннәрдә генә туганнарын, якыннарын илткән Бүләк авылы зиратына илтергә әзерләделәр. Авыл советы рәисен соңгы юлга Өшәрнең бар кешесе озатты. Бүләк авылы читенә урнашкан яңа зиратка кадәр ун чакрым араны җәяүләп үттеләр. Ильяс Насыйровны җирләү сәяси акциягә әйләнде. Татарларда, гадәттә, мондый авыр көннәрдә ызгыш-талашка юл куелмый, мәетне җирләгән көнне дошманлык күрсәтүләр Алла алдында зур гөнаһ эшләү дип санала. Бу көнне рәиснең авылдашлары «тормозны ычкындырдылар». Күмү идарә ителми торган митингка әйләнде. «Председатель үлемендә хакимият гаепле, бөтенебезне дә шул язмыш көтә, Агыйдел белән Кама кушылган җирдә Актаныш җирләрен су бастыру бабаларыбыз һәм үз халкыбыз алдында гаять зур җинаять»,— дигән сүзләр җыелган халык авызыннан әледән-әле ишетелә торды. Ильяс Насыйровны соңгы юлга озата килүчеләр барысы бер булып райкомның беренче секретаре килүен таләп итә башладылар. Аларның таләбен ничек итеп тиз арада беренче секретарьга җиткергәннәрдер, билгесез, якынча бер сәгать дигәндә, ул «Волга»сына утырып килеп тә җитте. Үгез кебек адымнар белән Ильяс Насыйров кабере өстендәге туфрак өеме янына килеп басты һәм кепкасын салды.

— Гафу ит, Ильяс,— диде ул, аннары җыелган халыкка таба борылды.

Күмәргә килгән кешеләр, бер сүз дә дәшмичә, беренче секретарьга карап тордылар. Бу мизгелдә шундый тынлык иде — чебен очса, аның тавышы да ишетелер иде. Әхнәф Хәбибуллин да берсүзсез җыелган кешеләргә карап торды. Беркадәр вакыттан эчке яну белән әйтеп куйды:

— Э-эх, миннән торамыни инде бу эш...

Шулай диде дә озак кына тын торды. Башкалар да бер сүз дәшмәделәр. Беренче секретарь сүзсез генә «Волга»сы янына килде һәм, машинасына утырып, олы юлга таба китеп барды. Күмәргә килүчеләр дә өйләренә, Өшәр авылына таба юнәлделәр.

Икенче көнне төш вакытларында ике коралллы милиционер озатуында авылга инкассатор «буханка»сы — «УАЗ» автомобиле — фургон килде. Күченү буенча компенсация акчасы китергәннәр дигән хәбәр авылга бик тиз таралып өлгерде. Янәсе, акча барысына да җитәчәк икән. Авылдашларның кичә зираттагы митинг активлыгы үзенең максатына ирешә. Райкомның беренче секретаре район чиновникларының койрыкларын боргалаган, булган вакыйгалар турында Казанга хәбәр иткән. Шулай итеп, акча да бик тиз табылган.

Эңгер-меңгер була башлаганда, «буханка» милиционерлар белән бергә Актанышка китеп барды. Тиздән урамда салып алган кешеләр дә күренә башлады. Алган акчаларга шатланыргамы, шатланмаскамы икәнлеген халык белми иде әле. Ә бит акча бирү үзләренең туган җирләре өчен тулысынча исәп-хисап ясау, аларның күченү тормышындагы соңгы нокта иде. Нәтиҗәдә болай килеп чыкты: юк кына акчага алар үзләренең кече Ватаннарын саттылар.

Юк! Акчаны барысы да алмаганнар икән. Акча алудан бердәнбер йорт хуҗасы — кырык яшьләрендәге Габдулла Гыйбадулла улы Хәйбуллин баш тарткан икән. Ул авылдашларына да, район чиновникларына да кистереп әйткән:

— Үз Ватаным белән сату итмим. Бернинди акча алмаячакмын. Соңгы көнгә кадәр эти йортында калам. Пусть батырсыннар. Үземнең өй белән су астына китәм.

Күршеләре, туганнары ничек кенә үгетләп карамасыннар, ул үз сүзендә торды — акча алмады. Туганнары үгетләгән саен, ул усаллана гына төште, кулларын күтәреп акырды:

— Сатлык җаннар. Илегезне саттыгыз...

...Элеккеге колхозның элеккеге колхозчысы Фатих Кәримов, компенсация акчаларын алгач, бераз тынычлана төште һәм, монда кышлау турындагы уйларыннан кире кайтып, әнкәсе белән хатынын Сарапулда сатып алган тузган йортка күчереп торырга ниятләде. Мәчесе Вася, эте Спутнигы белән нәрсә эшләргә? Мәҗбүри рәвештә илне саткан өчен акча алганнан соң, өлкән балалары Рәзилә белән Зөфәр үз гаиләләренең язмышларын үзләре хәл иттеләр. Кызы ире белән Сарапулда ике бүлмәле кооператив фатир сатып алырга булдылар. Ә улы Кама буендагы шәһәрдән беткән булса да бер йорт сатып алырга дигән карарга килде. Гаиләдәгеләрнең барысы да ахыр чиктә күченү белән килештеләр. Бары әнкәсе Фәрхикамал гына улыннан үтенгән шикелле:

— Үлгәч, мине безнең күчкән зиратка, туганнар, авылдашлар арасына алып кайтып җирләвеңне сораймын. Зинһар өчен. Туган илебездә әтиең дә күмелә алмады. Хет мине күмсәң иде туган җиребездә... Бу минем азаккы үтенечем,— дип үтенде.

— Ярар, үлү турында сөйләмик әле, әнкәй,— диде Фатих.— Яңа урында яңа тормыш турында уйларга кирәк.

Салкыннар башлангач, Агыйдел һәм аның тармаклары аша юл салынгач, әнисен, хатынын, шулай ук Спутник белән Васьканы юл уңаена үтеп баручы машинага утыртып Сарапулга озатты. Машинага кирәк булган бөтен әйберләрне төяде. Китәр алдыннан озак кына Васьканы эзләделәр. Эшнең нидәлеген сизеп, өйдән качкан, хәерсез. Үзенең туган җирен ташлыйсы килми икән. Фәридә аны бер өй аша күршеләреннән тапты. Тегеләрнең карават асларына кергән дә бер почмакка поскан. Вась-васькага да, пес-пескә дә җавап бирмичә тик ята, ди.

— Ярар, торсын бездә язга чаклы. Без калабыз бит әле. Яз көне алып китәрсез,— диде күршесе Фәридәгә.

— Юк, әнкәй сорый бит,— дип, Фәридә карават астына керде. Аннан мәчене көчкә тартып чыгарып, өйгә алып кайтты һәм бианасына бирде. Фәрхикамал карчык бу вакытта, пальтога һәм мамык шәлгә төренеп, баскан киез итекләрен киеп, автомобиль кабинасында утыра иде инде. Спутник машина әрҗәсе кырыйларына алгы аякларын куеп ишегалдын күзәтә иде. Фатих ишекләргә асылмалы зур йозаклар элде, аннан соң машина кузовы янына килеп, хатынын биленнән ике кулы белән тотып күтәрде дә машинага утыртты, аның артыннан үзе менде. Кәримовларны озатырга күршеләре, гаиләләре белән өлкән балалары килде. Машина Агыйдел шәһәрчеге ягына таба юл алды. Күршеләре озак басып тордылар һәм ерагая баручы машинадагыларга, саубуллашып, кул болгадылар. Авылны чыгып иске елганы үткәч, Фатих хатынын кочагына алды һәм бар тавышка «Хуш, авылым» җырын җырлап җибәрде:

Туган җирем,
сөйгән авылым
Бигрәк якын күңелгә.
Кай илләрдә яшәсәм дә,
Оныта алмам гомергә...

Фәридә, иренең күкрәгенә капланып, сулкылдап-сулкылдап елый башлады. Фатих кулы белән аның җилкәсенә каккалады:

— Елама, карчык, үләргә китмибез әле...

Ул, ярсып-ярсып, җырлавын дәвам итте. Каршыдан исүче салкын җил аның моңлы көен, бу моңлы көйнең сүзләрен, йөрәк әрнүен кайчандыр туган булган, хәзер инде чит булган авылга таба алып китте.

Хуш, авылым, сау бул,
Сәламнәр көт
Таң җилләре искәндә,
Мин җырлармын
сине сагынып,
Өзелеп искә төшкәндә.

Автомобиль, тизлеген арттырып, калын боз белән томаланган Агыйдел өстеннән бара иде. Тау өстенә менгәннән соң, Фатих җырның ахырын җырлап бетерде:

Матур була, ямьле була
Яз көннәрең, җәйләрең...
Исән булсам,
бер кайтырмын,
Язлар кебек әйләнеп.

Кама буендагы Сарапул шәһәренә ихтыярсыздан күчүче гаиләне утыртып, автомобиль көнчыгышка таба бара да бара иде. Болар әле Советлар Союзы дип аталган нык империянең үз эчендәге беренче ка-

чаклары иде. Урта Азиядән һәм Кавказдан качучылар соңрак, унбиш-егерме елдан соң күренә башлаячаклар.

Гаилә әгъзаларын Сарапулдагы тузган йортка урнаштырганнан соң, Фатих озак та тормады, туган авылына кайтты һәм өен, каралты-кураларын сүтәргә кереште. Беренче эш итеп ул өйнең бөтен бүрәнәләренә, почмакларга балта белән рим цифрлары сугып чыкты. Ишек һәм тәрәзә яңакларына да тамгалар салды. Шуннан соң гына шифер түбәне сүтә башлады. Күп еллар буе ятып, шифер уалучанга әйләнгән. Кадак суыргычны куеп бераз басуга, ул урыны-урыны белән кителеп төшкәләде. Фатих аның шулай буласын белгән иде инде. Эшкә яраклырак дигәннәрен ул аерым өйде. Сарапулда алар белән сарай түбәсен ябарга ниятләде. Бер атна эчендә булдыра алганнарын — өй түбәсен, өйалдын, веранданы берүзе сүтте. Ишегалдындагы бөтен кирәк-яракларны алып җыеп куйды. Өйнең генә бүрәнәсен бүрәнәгә аласы калды. Бу эшне башкару өчен, ул киявен, улын һәм ике күршесен чакырды. Ике көннән соң өй урынында зур кара чокыр гына күренеп калды. Тагын һәйкәл кебек зур гына ак мич утыра иде. Читтәрәк Сарапулга озату өчен бүрәнә, такта һәм борыслар өеме ята иде.

Бөтен эшләрне дә түгәрәкләгәннән соң, Фатих төзелә торган Агыйдел шәһәренә китте. Икенче көнне зур гына чана таккан егәрлекле «К-700» тракторында әйләнеп кайтты. Сүтелгән хуҗалыгын шуңа төяп, элеккеге колхозның элеккеге механигы шул ук көнне, тракторга утырып, Сарапулга китеп барды. Чыгып китәр алдыннан кирәк булмаган бөтен искене, черегән такталарны, борысларны лапас урынына җыеп яндырды. Зур учак барлыкка килде. Шулай иттереп, Фатих узган тормыш белән хәзергесе арасындагы күперне яндырды.

### *Унберенче бүлек*

Яз җиткәч, Фатих Сарапулдагы тузган йорт белән янәшә авылдан алып килгән йорты астына фундамент ясады. Сүс сатып алды. Ярдәмгә авылдашларын чакырып, өйне дә бик тиз күтәреп куйды. Калганнары инде үз вакыты белән башкарылачак иде. Түбәне ул яңа шифер белән япты. Мич аша үткәреп, су белән җылыту системасын эшләде. Яңа йорттагы бөтен нәрсә иске тормышны хәтерләтеп тора башлады. Вакыты белән Фатихка хәтта үзенең туган авылыннан күчмәгән дә сымак тоелды. Туган оядан куган өчен мәсхәрәләнү һәм үпкәләү бераз басыла төшкән иде инде. Чыннан да, кешегә тынычланыр өчен күп кирәкмени соң?! Яңа җирдә туган йортны салып куюга бигрәк тә Фатихның әнисе шатланды. Ул әледәнәле фронттан ире турында «кара кәгазь» алганнан бирле кабатлый торган сүзләрен тагын әйтеп куйды:

— Э-эх! Әтиегез исән булса, сөенер дә иде инде.

Алай да аларны бернәрсә борчыды: төзелеш барган мәшәкатьле көннәрдә Васька белән Спутник югалды. Мөгаен, матур, ягымлы Спутникны кем дә булса урлагандыр һәм кулга ияләштергәндер. Бәлкем, ашаганнардыр да, тиресеннән бүрек теккәннәрдер. Ә Васьканың Агыйдел тирәсенә, туган авылга китеп баруы ихтимал. Күп сулы Кама һәм Агыйдел елгалары аша юл эзли-эзли каядыр Каракүл районында җан бирүе дә бик мөмкин.

Ышанычлы дустын югалтуга бик нык кайгырганнан соң, Фатих тагын бер эт баласы алып кайтты. Аны да Спутник дип атады.

Күчү өчен бирелгән акча яңа урында йорт салу өчен артыгы белән җитте. Калган акчага Фатих белән Фәридә туган авылларыннан тана сатып алдылар һәм, шулай итеп, савым сыерлы булырга ниятләделәр. Бер елдан соң инде аларның шәһәрдә үз сыерлары булды. Фатих шәһәрнең су бирү станциясенә дежур слесарь булып урнашты. Эшкә ике тәүлеккә бер барасы иде. Су станциясе хуҗалыгының Кама буенда иң биектә урнашуы гына күңелен борчыды. Эшкә бару уңаенда һәрвакыт Каманың түбәнге агымына таба, туган якларына таба моңаеп карады, күңеленнән туган җирен барлады. Борок бистәсеннән һәм яшелләнеп торучы нарат урманыннан ары ул, әлбәттә, берни дә күрә алмады. Ләкин уй-хыяллары белән Фатих Агыйдел буйларында булган кебек иде. Бара-тора аның бу гамәле гадәткә әйләнде. Үзенең туган ягына карап алмый торып, ул эшкә керешмәде.

Өй хуҗасы хатынын эшкә урнаштырмады. Ул, артык сөйләшергә урын калдырмыйча, кырт иттереп әйтте:

— Эчке эшләр министры булырсың. Сиңа үзеңнең хуҗалыгыңда да эш җитәрлек: сыерны карарга, артык сөтне күршеләргә, танышларга сатарга кирәк. Өшәрнең колхоз фермасында эшләвең дә җиткән.

Ике көнгә бер тапкыр эшкә бару ишегалдында шөгыльләнергә, кышын «Эчке эшләр министры»ның ярдәмчесе булырга, җәен үзләрен туендырып торучы сыерга печән әзерләргә мөмкинлек бирде. Кечкенә шәһәрдә аларның тормышы әкренләп җайга салынды. Якшәмбе көннәрендә ул үзәк базарга авылдашлары белән очрашырга бара башлады. Бу үзенә күрә яшерен йола иде. Иртән үк ит павильоны янына Өшәр авылының элеккеге кешеләре җыелалар, яңалыклар сөйләшәләр, фикер уртаклашалар: кем үлгән, кем өйләнгән, кемнең оныклары туган... Якташлык рухы бик көчле иде күчеп килгән кешеләрдә. Якшәмбе көннәрендә базарда очрашулар алар өчен күңелне бушату иде.

Фатих туган ягына булган сагышын өйдәгеләргә күрсәтмәскә тырышты. Хатынының еш кына тәрәзә каршына басып туган якка карап торуын күреп, Фатих аның да авылны, туганнарын сагынуын аңлый иде. Мондый вакытларда Фатих Каманың Сарапул төрмәсе янындагы иң биек ярына барып утыра һәм әледән-әле Агыйдел ягына караштыргалап авыр хисләр кичерә, үткәннәрне искә ала. Аста, текә яр астында Кама үзенең кургаш төсле суларын түбән таба алып төшә. Йөрәкне әрнетеп, тынлыкны үтеп баручы пароходларның гудоклары гына бозгалый иде. Елга буйлап түбәнгә төшүче теплоходларның кычкыртуы күңелне бигрәк тә борчый иде. Фатихка алар гел үзләренең авылларына баралар сымак тоелды. Менә син шуларның берсенең палубасына утырасың да икенче көнне үк туган җирләрдә буласың. Ул бу минутларда утырган җиреннән торып китәргә көч таба алмый иде. Бары тик һәр теплоход, үзйөрешле баржа белән туган җиренә шартлы рәвештә сәламнәр җибәреп торды.

Язын армиядән кече уллары Рәшит кайтты. Ул буйга үскән, ныгыган. Фатих белән Фәридәнең шатлануларының чиге булмады — хуҗалык эшләрендә ярдәмче, өметләре, карт көннәрендә таянычлары булган малайлары бит ул. Оныгының кайтуына Фәрхикамал карчык та балаларча шатлану белән шатланды. Аны ул алсу битләреннән, аркасыннан сыйпады һәм берничә тапкыр:

— Койган да куйган бабасы Салих инде. Бу кадәр охшаса да охшар икән...— диде.

Чыннан да, Рәшит гәүдәсе белән дә, йөзе белән дә, үз-үзен тотышы һәм холкы белән дә Бөек Ватан сугышында хәбәрсез югалган Салих бабасына бик охшаган иде.

Сарапулның үзәк базарында җыелган якшәмбе көннәрнең берсендә Актаныш авылларында Сабантуйлары уздыру вакыты билгеле булды. Җыенда мондый карар кабул иттеләр: авылга барырга һәм Сабантуйны элек уздыра торган җирдә үткәрергә. Шәһәрдән яше-карты, кайсылары үз машиналарында, кайсылары тиз йөрешле метеорларда, кайберләре, гаиләләре белән җыелышып, автобус яллап, Өшәр авылына юнәлделәр.

Июньнең кояшлы көнендә Өшәр авылы кырыена йөзләгән «Москвич»лар, «Жигули»лар, «Волга»лар һәм автобуслар тезелде. Галәмәт зур авылның элеккеге кешеләре күркәм бәйрәмгә, балачакның хыялый бәйрәме — Сабантуйга җыелдылар. Дөресен генә әйткәндә, бу сагынып сөйләшүләр һәм искә алулар бәйрәме иде. Иске елга буендагы төрле-төрле чәчәкләр, үләннәр белән капланган тигез урынны авыл кырые дип шартлы рәвештә генә әйтергә мөмкин иде. Кайчандыр озын урамнар хасил иткән йортлар урынында хәзер кыргый киндераш, алабута һәм кычыткан гына котырынып үсеп утыра. Шушы яшеллек океаны уртасында Габдулла Хәйбуллин өе һәм бик күптәннән салынган ике тузган йорт кына күренеп тора иде.

Уйлабрак эш итүче кешеләр башкалардан бер-ике көн алданрак килеп Сабантуйга әзерлек хәстәрен күргәннәр: капчык белән сугышу өчен ике баганага бүрәнә беркеткәннәр, авыш бүрәнә куйганнар. Тамашачылар өчен эскәмияләр ясау турында да онытмаганнар. Сабан туе көнендә тирә-юньгә үзебезнең моңнар яңгырап торды. Халык агылды да агылды. Бу шимбә көнне өшәрлеләр бәйрәменә элеккеге Татар Әҗбие кешеләре дә килде. Сабантуй төсмерләре Сабантуй төсмерләре булып калды инде ул. Бөтен хикмәт дусларның, туганнарның очрашуында иде. Күздән яшьләр агызган бу бәйрәм чыннан да авыр тойгылар калдырган бәйрәм булды. Кая карама, шунда кочаклашып елашулар... Аларга мәйдан уртасыннан килгән гармун тавышы килеп кушыла. Җырлашып очрашулардан, баш әйләндергеч биюләрдән соң, кичкә таба йөзләгән еллар торган йортлары, йорт корылмалары участоклары, ничәмә буын кешеләре туган, ничәмә якыннары үлгән нигезләренә таралыштылар. Алабута, кыргый киндераш һәм кычыткан арасында табын оештырдылар, якыннарын искә алдылар. Күбесе үзләренә күңел истәлеге, киләчәк буынга истәлек, талисман итеп капчыкка туган туфракларын салдылар.

Үзенең туган оясын, туган җирләрен ташламаган Габдулла Хәйбуллин көннең герое булды. Ул, үз чиратында, бөтенесен чәйгә чакырды. Шәһәргә кире киткәндә, кешеләр Габдулла Хәйбуллинга авыл өйләренең учагын саклаучы булып калуын, борынгы бабалары җиренә бирелгәнлеген ахыргача лаеклы дәвам итүен теләделәр.

Икенче көнне үзләре шикелле үк күченгән кешеләр белән уртак теләктәшлек белдереп, Өшәр авылы кешеләре, иске елга ярында палаткаларын калдырып, әле күптән түгел генә зур авыл булган урынга — Татар Әҗбиенә Сабан туена барып килделәр.

Өченче көнне бәйрәмгә килүчеләр Бүләк авылы янындагы туганнар зиратында булдылар, күмелгән, күчереп күмелгән туганнарының, якыннарының каберләре янында уйга батып басып тордылар, аннан соң Сарапул шәһәренә кайтып киттеләр. Туган илне, туган җирне шулай бик тиз ташлап китәргә ризалашкан өчен, алар хакимият органнарына, үз-үзләренә үпкәләделәр.

Бәйрәмнәр үтте. Габдулла үзенең карт әнисе белән тагын икәүдән-икәү генә иске Агыйделнең сахрадай ярында калдылар.

Туган җирләрдән әйләнеп кайтканнан соң, Фатих кече улына өйләнү мәсьәләсен кузгатты. Рәшит нишләптер аны-моны әйтмәде. Ләкин, күп тә үтмәде, балалы маржага өйләнәчәген белдерде. Фатих белән Фәридә бу хәбәрне бик авыр кичерделәр. Ә Фәрхикамал карчык бу яңалыкны ничек аңларга да белмәде. Рәшит көннәрнең берендә туйсыз-нисез, бернинди тантанасыз үзенең кадерлесе янына китте һәм

башкача өйгә әйләнеп кайтмады. Ярты елдан соң Рәшитнең ул хатынның баласын уллыкка алуы билгеле булды. Шулай итеп, көтмәгәндә Кәримовлар тагын бер кешегә артты.

Бу вакыйгалардан соң ике-өч ай да узмады, кинәт кенә Фатихның әнисе, Фәридәнең яраткан бианасы Фәрхикамал карчык дөнья куйды. Һәрвакыт тын гына йөрүче Фәридә озак елады. Ул бианасы өчен үләргә әзер иде. Каенанасы үлгәч, ул үзен ялгыз итеп сизде, әченнән генә ансыз Сарапул шәһәрендәге бу йортта бәхетле тормыш булмаячагы турында уйланды.

Фәрхикамал карчыкның үтенече буенча Фатих белән Фәридә аның мәетен, туган җиренә, Бүләк авылы янындагы яңа зиратка алып барып, туганнары, авылдашлары янәшәсенә җирләделәр. Алар элеккеге Өшәр авылында үзләренең хуҗалыклары урынында да булдылар. Төнне Габдуллаларда уздырдылар, иртән Сарапулга кайтып киттеләр.

Бу дөньяда тормыш шулай корылган күрәсең инде, кайгы ул бервакытта да үзе генә килми. Ике айлар үткәч, Сарапулга Кәримовлар исеменә туган якларыннан кайгылы хәбәр язылган телеграмма килде: Өшәр авылыннан ерак түгел, балык тотканда, олы уллары Зөфәр Агыйделдә батып үлгән.

Әтисе үрнәгендә ул да Сарапулда кечкенә генә бакчасы булган иске йорт сатып алган иде. Ләкин аның шәһәрдә даими эшкә урнашасы килмәде. Туган җирләрендә балык тоту белән шөгыльләнде. Ул, балык тоту кирәк-яракларын алып, Агыйделгә китә иде дә атналар буе йә балыкчылар землянкасында, йә Габдуллаларда, яисә җәен яр кырыенда палаткада яши иде. Балыгын сата, азык-төлеккә, аракыга алыштыра. Шуның белән канәгатьләнеп яши иде. Колхозның элеккеге механизаторын әрәмтамаклыкта, заводта яки шәһәр төзелешендә эшлисе килмәүдә гаепләп булмый иде. Фатихның олы улы кендеге белән туган җиренә береккән иде, шуңа күрәдер дә ул күп вакыт авыл кырыйларына, Агыйдел кушылдыкларына, Агыйделнең үзе янына китеп югала, анда таңны каршы ала, елга тамагында теплоходларның гудок тавышларын тыңлый.

Зөфәрнең гәүдәсен бер атнадан соң яр буендагы шул ук балыкчылар күреп алалар һәм Ямалы авыл советына хәбәр итәләр. Мәетне Сарапулга алып кайтып тормадылар. Фатих белән Фәридә, Зөфәрнең хатыны балалары белән, туган җирләренә барып, Фәрхикамал карчык янәшәсенә җирләделәр.

Ярты елдан соң һич көтмәгәндә, Кәримовларның кызы Рәзилә йөрәк авыруыннан дөнья куйды. Аның үле гәүдәсен шулай ук Сарапулдан туган якларына алып киттеләр, әбисе һәм Зөфәр янәшәсендә күмделәр.

Фәридә зиратта сулкылдап-сулкылдап озак елады һәм:

— Бөтенесен кире ташып бетердек инде. Хәзер минем чиратым җиткәндер,— дип кабатлады.

— Юкны сөйләмә әле,— дип, Фатих ягымлы итеп тормыш иптәшен тынычландырырга тырышты.— Киресенчә, безгә озак яшәргә кирәк. Үлгән балалар өчен дә...

— Мин синнән бары бернәрсәне генә сорыйм,— диде Фәридә елау катыш. Ул һаман тынычлана алмый иде әле.— Зинһар, мине балаларым янәшәсенә җирлә.

— Кемне алдан күмәселәре әле берәүгә дә билгеле түгел.— Фатих ачуланмый гына әйтеп куйды.— Әйдә, бу турыда онытыйк...

Ике баласын җирләгәннән соң, Фәридә өчен тормышның яме китте. Аның зиһене чуалды, онытучан булды, нервыларының ярсуы нәтиҗәсендә зиһене томаланды. Кече уллары Рәшитнең ара-тирә килеп китүе дә Фәридәнең, аның гына түгел, Фатихның да күңелен тынычландыра алмады. Гадәттә, ул ял көннәрендә улы Иван белән килә иде. Гәрчә Ваня сөйкемле малай булса да, картларның күңеле аңарга ятмады. Чит кан. Ә Рәшитнең үз балалары ни өчендер юк иде әле. Аннан соң бердәнбер уллары Рәшитнең салгаларга яратуы, хуҗалык эшләренә күңеле ятмавы да Кәримовларны бик борчый иде. Ишегалды корылмаларын ясаганда, атасына бер кадак кагарга да булышмады. Ә үзе өч литрлы банкада сөт һәм сыер мае алып китүдән бер дә баш тартмый иде.

Фатих белән Фәридә бер үк вакытта пенсия ала башладылар. Уйладылар-уйладылар да сыерларын сатарга булдылар. Азык әзерләүләре, яшь вакыттагы шикелле иртәнге дүрттә-биштә торып ашату-эчертү, лапастан тирес чыгарулары авыр була башлады. Алай исәпләп карадылар, болай исәпләп карадылар да пенсия бик иркенләп яшәрлек булмаса да, нормаль яшәп тору өчен җитәр әле дигән фикергә килделәр.

Шулай ирле-хатынлы Кәримовларның көндәлек күңелсез тормышлары дәвам итте. Ял көннәрендә Сарапулның үзәк базарында якташлар белән очрашулар гына тормышка бераз ямь өсти иде. Шундый көйгә салынган тормыш та Фатих өчен көтмәгәндә кинәттән өзелде — аның мәхәббәте, тормыш дусты, балаларының әнисе үлде. Югыйсә соңгы елларда нинди дә булса каты авыру белән дә авырмады. Үләргә ике атна кала ул тугрылыклы тормыш иптәшенә кинәттән генә әйтеп куйды:

— Ахры, мин дә озакламый китәрмен инде. Әгәр дә соңрак әйтә алмасам, бәхил бул инде, Фатихкаем, рәнҗеп калма. Мин синең белән бик рәхәт яшәдем... Аллакаем сиңа тазалыклар бирсен. Минем васыятемне оныта күрмә...

Сөекле хатынының бу сүзләрен ачуланып кабул итте һәм катырак итеп әйтеп ташлады:

— Җитәр инде сиңа юк-бар нәрсә турында сөйләргә...

Беренче тапкыр хатынының үле гәүдәсен күрү белән, үзенең ачуланып әйткән сүзләре исенә төште һәм шул сүзләре өчен үз-үзенә үпкәләүдән күз яшьләре атылып чыкты. Ул сүзләрне үзе үлгәнче хәтерендә тотты, үз-үзен тиргәде, шул минутларны күз алдына китереп, еш кына елады. Шулай инде, тормышта булганны сакламыйбыз — югалткач елыйбыз.

Фатих Фәридәнең авыл зиратында әйткәннәрен дә исенә төшерде: «Бөтенесен кире ташып бетердек инде». Улы Рәшит, кызы Рәзилә белән Фатих тугрылыклы хатынын, кайгыртучан ананы, тагын туган якка, әнисе, балалары, туганнары янына илтте. Сарапулда буш өйдә яшәү Фатих өчен бөтен мәгънәсен югалтты. Пенсиясен алганнан соң, ул даими рәвештә ай саен туган ягына кайтып йөри башлады. Озаклап икешәр-өчәр көн Бүләк авылы янындагы зиратта йөрде, үзенең якыннарының кабер ташларын куллары белән сыйпады. Хатыны кабере өстендәге ташны бите белән сыйпады, үбеп-үбеп алды. Истәлеккә дип, шәһәргә алып кайту өчен кечкенә капчыкка туфрак тутырып алды.

Сарапулда аның бердәнбер шатлыгы — тугрылыклы эте, Спутнигы, һәм ял көннәрендә үзәк базарда якташлары белән очрашуы гына калды. Ялгызлыкка, туган җирләрне, балаларны, сөекле хатынын сагынудан күңеле түзә алмагач, иртәгә иртүк туган якларга юлга чыгарга дигән карарга килде. «Может соңгы баруым булыр,— дип уйлады карт.— Кем белгән, авырып китәрмен дә, аннары кышын бара алмам. Үзебезнекеләр белән киләсе язга кадәр саубуллашырмын...»

### *Уникенче бүлек*

Механизаторлар Рамил Әхмәтов белән Мирсәет Шакиров бу иртәдә дә такта йорттагы чыдап булмаслык суыктан уянып киттеләр. Өйнең бердәнбер тәрәзәсенә Кыш бабай әллә нинди челтәрләр ясап бетергән. Мичне ягып, чәй эчкәннән соң, алар, гадәт буенча, тагын Агыйделгә киттеләр. Суык үзен шактый сиздерә иде, мөгаен, унбиш градуслар булгандыр. Ә кар һаман юк иде әле. Агыйдел көчәйгәннән-көчәя баручы салкыннан йокымсырый. Ике як ярында да беркем юк. Мирсәет ике бармагын авызына куеп бик көчле итеп сызгырды. Землянка урнашкан дип уйланылган яктан бәс сарган өянкеләр арасыннан картның эте килеп чыкты. Ул боз кырыена килде һәм, койрыгын арт аяклары арасына кыстырып, башын югары күтәрде, ямансу, җан әрнеткеч тавыш белән улый башлады. Мирсәет тагын бер мәртәбә сызгырды. Эт элеккесеннән дә катырак улады. Берничә минут боз кырыенда басып торганнан соң, өянкенең бозланган куаклары арасына кереп китте.

— Чыннан да, карт белән нәрсәдер булган,— диде Рамил.— Авырган, күрәсең.

— Может ул, ни... үлгәндер,— дип сүзгә кушылды Мирсәет. Рамил, шундый сүзләре өчен ачуланып, дустына карады.

— Син бигрәк инде, шулхәтле соң...

— Да-а, катлаулы мәсьәлә булды әле бу.— Мирсәет колак артын кашып алды.— Без бүген теге як ярга чыга алмыйбыз бит әле. Әгәр дә суык тагын бер тәүлек шул көе торса, иртәгә әкрен генә шуышып чыгарга мөмкин булачак.

Эт башкача күренмәде. Мирсәет белән Рамил куышларына таба борылдылар. Өйләре яныннан кулларына берәр колга алдылар, Габдулла ягына чыгу нияте белән, иске елгага таба юнәлделәр. Иске елга яры да буш иде. Тирә-юньдә Габдулла үзе дә күренмәде. Ир-атлар, аякларын иске елганың шома бозыннан аермыйча, сантиметр артыннан сантиметр калдырып, алга шуыштылар. Алар бер-береннән ун метрлар чамасы ара калдырып бардылар. Канатта йөрүчеләр упкын өстеннән барган шикелле алар кулларына колгалар тотканнар иде. Каршы як ярга чыга алуларына үзләренең дә исләре китте. Гөнаһлы җиргә аяк басу белән, дулкынланудан аларның битләреннән тир акты. Аларның икесе дә яңа гына пешерелгән кысла шикелле кып-кызыл иделәр. Кешесез утраудагы әсирлектән котылуларына күпмедер ышанмый тордылар. Бераз тынычлангач, механизаторлар Габдулла йортына таба юнәлделәр. Йорт хуҗасының эте килгән кешеләргә ярсып, алай гына да түгел, шашып өрде, өсләренә ташланмакчы булды. Әгәр юан чылбырга бәйләнмәгән булса, чит кешеләрне өзгәләп ташларга әзер иде ул.

Эт өрүенә, җилкәсенә иске тунын салып, Габдулла үзе чыкты. Этен кисәтеп, такмаклый башлады:

— И-и Аллам, сез исәнме? Әйдәгез, өйгә керегез.

Механизаторларны өйдә Габдулланың әнисе Гөлчирә әби бик якты чырай белән каршылады. Туксан өч яшьтә булуына карамастан, ул әле бик җитез һәм сүзчән иде. Карчык элеккечә, сугыш алды елларындагы кебек, самовар куярга ашыкты. Габдулла өендә, авылдашлары күчеп киткәннән бирле, электр уты янмый иде.

Утраудагы суфи тормышыннан соң өйнең җылылыгы һәм уңайлыгы Рамил белән Мирсәеткә оҗмах булып тоелды. Кунаклар көткән дип белерсең, Гөлчирә әби казанда өй токмачы белән әллә никадәр аш пешергән. Габдулла үзе савытлар шкафыннан шушындый хәлләр өчен әзерләп куелган аракысын чыгарды.

— Ну, нәрсә? Өйгә кайтасызмы? — дип сорады Габдулла механизаторлардан.— Елгада боз ныгыганчы мин тракторыгызны карый торырмын.

— Ничек кайтып китәсең,— диде Рамил,— теге як ярдагы бабайның хәлен беләсе бар әле. Ачыкларга кирәк, аңа нәрсә булды икән.

— Бер уңайдан аның кем булуын да ачыклыйсы бар,— дип сүзгә кушылды Мирсәет.

— Да-а, кызык кына ситуация икән әле монда. Кем булуы мөмкин икән? — дип дәвам итте Габдулла.— Белеп кара син аны. Бәлкем, ул безнең як кешеседер. Әгәр шулай икән, кем ул, кем карты, кемгә, кая бара? Безнең авылда бит меңләгән йорт иде.

Ирләр сөйләшкән вакытта Гөлчирә әби, танырга тырышыпмы, юлаучыларның әле берсенә, әле икенчесенә карый иде. Аннары сүз уңаенда гына карт турында әйтеп куйды:

— Эх, мескенкәем...

Кичкә таба Габдулла мунча ягып җибәрде. Аны томалаганнан соң, күпме көннәр газап чиккән ир-атлар оҗмах почмагына килеп эләккәндәй булдылар. Рамил белән Мирсәеткә болар әле төш кенә сымак тоела иде. Хуш исләр бөркеп торган каен себеркесе белән бер-берен дөмбәсли-дөмбәсли озак чабындылар. Уннарча еллар буена суфичылык тормышы алып баручы Габдулла өчен дә ирләр белән аралашу үзе бер шатлык булды. Шундый рух күтәргеч мунчадан соң алар җырлап торган самовар янында сөтле чәй эчтеләр һәм, уртак танышларын искә алып, озак сөйләшеп утырдылар.

Рамил белән Мирсәет Габдуллаларда кунарга булдылар. Иртә белән кайнар сөтле мәтрүшкә чәе эчкәннән һәм табадан гына төшкән коймак ашаганнан соң, механизаторлар Габдулла җитәкчелегендә Агыйделнең аръягына чыгарга, билгесез бабай белән нинди хәлләр булуын ачыкларга карар кылдылар.

Иске елга өстеннән өчесе өч җирдән чыктылар. Анда боз шактый ныгыган иде инде. Кичкәндә хәтта бер тапкыр чыртлап та карамады. Печән чабучылар йорты янына килеп, ир-атлар «Беларусь»ның арткы көпчәкләрен салдырдылар. Камераларын алып, аларга һава тутырдылар. Шулай итеп, ике резин көймә барлыкка килде. Габдулла өйнең тышкы такта ишеген элмәкләреннән алырга кушты. Барлык шушы милекләре белән алар Агыйделгә юнәлделәр. Өянке куаклары арасыннан тагын эт йөгереп чыкты һәм боз кырыена килеп улый башлады. Камераларның һәркайсына һәм ишек полотносына өчәр метр бау бәйләделәр. Шушы әйберләрен сөйрәп, алар аерым-аерым калкулыклардан торган кытыршы боз өстеннән сакланып кына атлый башладылар. Гаҗәпкә каршы, боз нык иде. Утыз, әллә инде кырык минуттан алар Агыйделнең уң як ярына аяк бастылар. Эт кешеләргә ташланмады, киресенчә, ул, койрыгын болгый-болгый, әле кунаклар янына йөгереп килде, әле тирәк куаклыклары арасына кереп югалды. Ул кайсы юнәлештә барырга кирәклеген күрсәтә иде бугай.

Берничә минуттан соң Габдулла, Мирсәет һәм Рамил землянканы таптылар. Аның ишеге бераз ачылган иде. Ишекнең эчке ягы эт тырнаклары белән тырналып беткән. Болай булгач, эт землянкадан көч-хәл белән генә чыга алган. Габдулла ишек уемын, кеше сыярлык итеп, бераз киңәйтә төште һәм җир астына кереп китте. Аның артыннан Рамил белән Мирсәет тә керделәр. Землянка эче караңгы, берни күренми иде. Габдулла шырпы сызды. Шулчак алар караватны хәтерләткән җир түмгәк өстендә кеше ятканын күрделәр. Ә өстәл итеп кулланыла торган җир түмгәк өстендә илленче еллар үрнәгендәге гаилә альбомы ята. Шунда ук Фатихның, аның әнисенең, әтисенең, хатынының, улларының, кызларының һәм башка туган-тумачаларының фотокарточкалары чәчелгән иде. Карт, бүреген күзләренә төшереп, иске солдат бушлатына төренгән хәлдә, аякларына искереп беткән кирза итекләр кигән килеш, бөкрәеп ята иде. Габдулла картның беләзеген тотты. Аның куллары салкын гына түгел, хәтта каткан иде. Карт үлгән. Габдулла картның бүреген салдырды һәм шундук артка чигенде.

— Ох, егетләр,— диде ул курку катыш.— Бу Фатих абзый ич, Фәрхикамал әби улы, Фәридә апаның ире. Алар бездән ерак түгел генә торалар иде. Авылларны күчергән елларда алар Сарапулга киттеләр.

Габдулла авылдашының йөзен игътибар белән күзәтә башлады. Аның иреннәрен кан чыгарырлык итеп тугрылыклы дусты — эте ялаган. Хуҗасының үле йөзен күреп, эт койрыгын аяклары арасына кысты һәм йөрәк өзгеч итеп улый башлады. Габдулла тагын бер тапкыр Фатих абзыйның үлгән хатынының, кызларының, улының, әнисенең һәм әтисенең җир өстәл өстендә аунап ятучы фотокарточкаларына күз ташлады. Янәшәдә генә бер кечкенә календарь ята. Анда аның туган ягына юл тоткан көннәре сызгаланган иде. Соңгы ике көне сызылмаган, димәк, карт булдыра алмаган, үлем хәлендә булган. Фатих карт үзе туган, үзе үскән җирләргә бары берничә йөз метрлар гына барып җитә алмыйча үлгән. Ләгънәт төшкән сезон арасы, нәфрәт тудыргыч сил үзенең туган җиренә барып җитәргә мөмкинлек бирмәгән аңа.

Габдулла идәннән урталай бөкләнгән кәгазь табып алды, ишек янына килде, күзлеген киеп, «Хуш, авылым» җырының сүзләрен укыды. Мәрхүм аны кайчандыр төгәл һәм матур итеп күчереп язган булган, күрәсең. Беренче ике куплетны ул эченнән генә, ашыкмыйча сүзен сүзгә укыды. Соңгы юлларны кычкырып укыды:

Матур була, ямьле була
Яз көннәрең, җәйләрең...
Исән булсам, бер кайтырмын,
Язлар кебек әйләнеп.

Габдулла сытылып чыккан күз яшьләрен сөртеп алды һәм тамак төбенә утырган төер аша әйтте:

— Кайтты, в общем. Түлке көз ахырында, кыш башында...

Картны саклык белән генә землянкадан алып чыктылар һәм елга буена алып төштеләр. Мәрхүмнең гәүдәсен ишек полотносына салдылар. Габдулла аңа бау бәйләде. Мирсәет куаклар арасыннан таяк табып алды. Ашыкмыйча гына, калкулыклы, тигезсез урыннарда ишек полотносын күтәргәли-күтәргәли Фатих бабайның гәүдәсен Агыйделнең каршы як ярына шудырып алып киттеләр. Көтелмәгән хәл килеп чыкмагае дип, як-ягына трактор камералары бәйләделәр. Бигрәк тә эт мәшәкать тудырды. Ул бозда һәрдаим тайды, үзәкне өзеп, әледән-әле улады. Ул, бер мәлгә туктап, хуҗасы белән шуып баручы ишеккә карап торды, шыңшыды, аннары сөртенә-тая ирләр артыннан йөгерде. Агыйделнең яңа каткан калкулыклы тигезсез бозы өстеннән шулай бару күпмегә сузылгандыр, шайтан белсен. Ирләргә аның чиге юк сымак тоелды.

Ярга җитү белән, аларның өчесе дә җиргә аудылар. Хәл ала алмыйча озак яттылар. Читтән карасаң, яр битендә дүрт мәет ята дип уйларга мөмкин иде. Бары эт кенә үзенең хуҗасы янында утырды һәм бертуктаусыз улады.

Рамил белән Мирсәет камераларны трактор янына илттеләр һәм шунда ук киредән яр буена төшеп киттеләр. Хәзер алар өчәүләп, Фатих бабайның гәүдәсе һәм аның юлга алынган әйберләре салынган ишек полотносын күтәреп, Габдуллалар йортына юнәлделәр. Янәшәдә, үзен гаепле санагандай, читкә карабрак картның эте барды. Ир-атлар Габдулла өе янына кичке якта гына, суфи хуҗалыгына караңгылык төшә башлагач кына килеп җиттеләр.

— Фатих абый урамда кунсын,— диде Габдулла.— Ул барыбер каткан инде. Хәзер аңа бернәрсә дә булмый. Монда кунарбыз да иртәгә минем атта мәетне Такталачык авылы участок хастаханәсенә илтербез. Кем белә нәрсә булганын. Пусть тикшерсеннәр...

Мәетне брезент белән капладылар. Этне абзарга куып керттеләр һәм ашаттылар. Баштарак ул, койрыгын аяк араларына кыстырып, ашамаган булды. Ачлык ачлык инде. Озак читкә карап тора алмады, ипи турап салынган калган ашка ташланды. Шуннан соң бераз тынычланды.

Каты суыклар башлануга карамастан, җиргә кар төшкәне юк иде әле. Шуңа күрә Габдулла иртүк торып атын арбага җикте. Мәетне арбага салып, алар Такталачык авылына чыгып киттеләр. Ирләр арба кырыеннан бардылар. Габдулла, алдын-артын уйлап, этне ябып куйды. Әмма ул, хуҗасын алып киткәннәрен сизеп, озак улады.

Буазкүл авылында Габдулла беренче очраган ир-атка булган хәл турында сөйләде һәм Сарапулга Фатих Кәримовның улы Рәшиткә, оныкларына телеграмма сугуын үтенде.

Участок хастаханәсендә бик әдәпле, ачык йөзле хирург мәетне алырга ике тәүлектән соң килергә кушты.

— Ул бит каткан, үлем сәбәбен билгеләү өчен аның эрүе кирәк,— дип нәтиҗә ясады хирург.

Икенче көнне Габдулла Бүләк авылы янындагы зиратта хатыны белән янәшә Фатих Кәримов өчен кабер казыды, мондагы мулла белән дога укырга килеште, кәфенлекләр сатып алды.

Өченче көнне Габдулла, элеккеге авылдашларыннан өч кешене алып, бер якташ-эшмәкәрнең «Газел»ендә участок хастаханәсенә китте. Такталачык табиблары мондый нәтиҗә ясаганнар: миокард инфаркты. Алар кулларын гына җәйделәр, янәсе, картлык, берни дә эшләп булмый. Якташын, аның бөтен туганнарын ерактагы авыл зиратында күмеп бетерү авырлыгын, туган җирен юксынуын яхшы белгән Габдулла үзенең ныклы диагнозын куйды: Кәримов Фатих Салих улы сагынудан, юксынудан үлде.

Табиблар мәетне юарга һәм хастаханәдә күмүгә әзерлек хәстәрен күрергә рөхсәт иттеләр.

Фатихны шул ук көнне әнисе белән балаларыннан ерак та түгел, сөекле хатыны белән янәшә җирләделәр.

## Калаларда таш казарма...

### *Мин китәм калаларга*

Таң алдыннан авыл урамын яңгыратып, тальянның үзәк өзгеч моңына кушылып җырлаган калын тавышлы билгесез ир-атның җыры, гомерем буе мине эзәрлекләгәндәй, колагымда яңгырый:

Мин китәм калаларга,
Калаларда таш казарма
Бәхетсез балаларга...

Ярты гасыр гомер узса да, бу җырның авторын әлегәчә белә алмадым. Әмма аның сүзләре дә, көе дә хәтеремә нык уелган. Эчем пошкан чакларда борын астыннан гына җыр сузам:

Калаларда таш казарма
Бәхетсез балаларга...

...1947 елның җәй уртасы. Эссе. Төнгә тәрәзәләрне ачып калдырабыз. Мин — ул чакта 10 яшьлек малай — татлы йокымнан шушы җырны һәм тальян моңын ишетеп уяндым. Күңелемне сүз белән генә аңлатып булмый торган әллә нинди сагыш биләп алды. Әрнеп-әрнеп елый башлавымны сизми дә калдым. Ул арада тальян һәм җыр моңы авыл очына китеп, кара төн куенына кереп югалды...

Ачлыгы белән җанга үткән кырык җиденче елда гаиләбез тулы иде әле. Әткәй дә безнең белән, әбиебез дә исән.

Таң алдыннан ишеткәннәремне йокыдан торуга инәкәйгә сөйләп бирдем.

— Төшеңә кергәндер, улым,— диде ул.— Бәлки, берәрсен йә армиягә, йә ФЗӨгә, йә булмаса төрмәгә озатканнардыр.

Бераз уйланып торгач:

— Хәер, төрмәгә түгелдер. Таш казармага җырлап китмиләр,— дип өстәде.— Кеше лапасыннан бәрән урлаган кебек тавыш-тынсыз алып китәләр анда.

Мин, ул әйткәннәргә ачыклык кертергә теләп:

— Нәрсә соң ул таш казарма? — дип сорыйм.

— Әтиеңнән сора, ул сугышта булган кеше, таш казарманың ни икәнен яхшы беләдер.

Бик сорар идем дә бит, әткәй өйдә юк, таң белән колхоз эшенә киткән. Башка кайгы төште бит: ничек итеп кенә таш казарманың нәрсә икәнлеген белергә?Аптырап басып торуымны күреп, инәкәй йомшара төште һәм кыска гына итеп аңлатып бирде:

— Таш казарма — кызыл кирпечтән салынган ике катлы йорт була ул. Әгәр дә әнәле тимерчыбык белән уратылып, тәрәзәләренә тимер рәшәткәләр куелса — төрмә, аларсыз гына булса — солдатлар яши торган казарма инде.

Бераз аңладым шикелле. Шул вакыттан бирле төрмә дигән сүз ишетсәм, күз алдыма тимер рәшәткәле, тимерчыбык белән уратып алынган кызыл йорт килеп баса. Мин үземне хәрби хезмәткә — рәшәткәсез кызыл йортка китәргә әзерли башладым.

Безнең Түбән Карач авылы Актаныштан Минзәләгә баручы ике юл чатына урнашкан иде. Ике атнага бер тапкыр авылыбыз аша Актаныш КПЗсыннан Минзәлә төрмәсенә баручы 10—15 кешелек колонна үтә. Куллары артка куелган арестантлар Минзәләгә һәрчак җәяү баралар. Аларны колонна башында һәм ахырында җигелгән атларга утырган надзиратель-сакчылар озата. Урамның каршы ягында — нәкъ безнең өй турысында авыл коесы бар. Колонна һәрчак шул кое янында туктап тора: атлар һәм арестантлар су эчә. Коеның тешләрне камаштыра торган салкын суын алар әкренләп кенә эчәләр. Арестант чиләктән су йота, ә күзләре белән тирә-якны өйрәнә. Ул күзләрдәге сагыш, хәсрәт... Аларның өс-башлары да бик хәерче: тузып-тетелеп беткән иске сырмалар, аякларында — чабата. Әбекәебез аларны үзенчә «ристан», «ристаннар», ә надзирательләрен «җандармнар» дип атый.

Бөтен авыл капка ярыкларыннан, тәрәзә пәрдәләре артыннан ристаннарны һәм жандармнарны күзәтә. Тик берәү дә аларга якын килергә кыймый. Авыл халкы үзебезне дә алып китмәгәйләре дип курка. Бары малай-шалай гына бер куркусыз ристаннар янына килә. Күрәсең, ул чакта кызыксыну хисе курку хисеннән өстенрәк булган!

Авыл аша арестантлар үткәндә, башларны гел бер уй бораулый: «Әгәр дә...»

Чынлап, әгәр дә без — авылның бөтен малайлары, жандармнарга каршы чыгып, аларның зур наганнарын кулга төшерсәк, мескен ристаннарны иреккә җибәрер идек тә алар безнең Шәбез елгасы аша урманга качарлар иде... Юк, урманга качарга ярамый. Сугыштан соң урманны бүреләр басты. Алар, бу як халкының котын алып, кайвакыт төннәр буе бертуктаусыз улыйлар. Күпме сарык, бозау, сыер һәм атларның башларына җиттеләр... Ристаннарны да «әһ» дигәнче ашап куюлары бар. Соңрак, ул илленче елларда, бүре-бәдбәхетләрне Казаннан «яраплан»га утырып килгән аучылар кырып бетерделәр.

Мескен ристаннар күршедәге зур авыл — Татар Суксуына китсәләр, әйбәтрәк булачак. Чөнки авыл башыннан ике чакрымлап озынлыкта сусыз елга сузылган, аннан Көләгеш күленә качарга, Көләгештән Камага китәргә бик уңай.

Табигатьнең иң хәтәр эше булган Суксу башындагы яр-упкын әле дә хәтеремдә. Шул яр төбеннән тишек сырмалы, мунчалага әйләнгән чабаталы ристаннарның ничек итеп жандармнардан качуларын еш күз алдына китерә идем.

Балачакның күп хатирәләре шул яр белән бәйле. Авылда электр юк заман. Болай да дефицит керосинны янга калдырабыз дип, йокларга иртә ятабыз. Барыбыз да сәкегә тезелгәч, инәкәебез Мөнирә белән Фәрхикамал әби берәр нәрсә сөйлиләр, соңыннан, бергәләп, Коръән сүрәләре кабатлыйбыз.

Әбекәй сөйләгән бер хикәя бүген дә хәтеремдә.

...Кышның күз ачкысыз буранлы төнендә бер карчыкны олы улы тирес ташый торган чанага утыртып яр буена алып килә дә төпкә тәгәрәтә. Упкын төбеннән әнисе кычкыра икән моңа:

— Чанаңны ал, улым. Кирәге чыгар. Улларың үскәч, алар да сине монда алып килерләр бит...

Шушы сүзләрне ишеткәч, улы, упкын төбенә төшеп, әнисен кире алып менә.

Кеше тормышы төрле сурәтләүләргә, ассоциацияләргә бай. Кышның буранлы ямьсез төнендә упкын төбендә карда аунаган шушы карчык, аның янындагы чана һәм өстә — яр читендә басып торган ир-ат гомерем буе күз алдыннан китмәде...

Авыл коесы янындагы мескен ристаннарны коткарсак, алар ярга таба йөгерерләр дә, Көләгеш күле аша Камага качарлар иде. Ә Камадан соң Россия — очы да, кырые да күренмәгән ил башлана дип уйлый идем мин, беркатлы авыл малае. Бу илдә беркемнең дә беркая да кача алмаганлыгын мин каян белим соң? Әйе, иге-чиге булмаган, җир шарының алтыдан бер өлешен биләп торган ил. Әмма опричниклардан качып котылу мөмкин түгел. Качса да, бик сирәкләр генә котылгандыр...

Кое янында туктап хәл җыйган бәхетсез җаннар, Югары һәм Түбән Уръяды, аннан соң Калморза, Бикбаул, Мәлкән авылларын үтеп, Минзәләгә китәләр. Туган авылым аша үтүче бу юлны Актаныш ягы халкы «төрмә юлы» дип йөртте. Хәзер күпләр моны хәтерләми, яшьләр исә бөтенләй белми.

Арестантларны озатканда, мин аларның ничек итеп рәшәткәле тәрәзәләрдән генә торган, тимерчыбык белән уратып алынган ике катлы кызыл кирпеч йортка килеп җитүләрен күз алдына китерә идем. Шул чакларда тальянга кушылып моңланган билгесез ирнең җыры колагымда һаман яңгырый:

Калаларда таш казарма
Бәхетсез балаларга...

Бер елдан артыграк вакыт үтүгә, кырык сигезнең сентябрендә, минем этигә — колхоз рәисенә дә чират җитте. Мин дөньяга килгән 1937 елгы репрессияләрдән соң бөек халык атасы мыеклы Сталин икенче тапкыр илне чистарта башлый. Ул чакта әсирлектә булган фронтовикларга һәм ач колхозчыларга бер уч кына булса да икмәк биргән рәисләрне утырттылар.

Кырык җиденче елның җәйге иртәсендә инәкәемнең «төрмәгә җырлап китмиләр» дигән сүзләрен еш искә төшерәм. Ә без этиебезне төрмәгә җырлап озаттык. Безгә кушылып, минем кулларымдагы тальян да бу ачы хәсрәттән сыкрады... Әткәйне дә шул Минзәлә төрмәсенә озаттык. Бу көнне инәкәй белән минем күзләрдән, хәсрәт дәрьясы булып, кайнар яшь акты. Тәрәзәләре тимер рәшәткә белән капланган, тирә-ягы энәле тимерчыбык белән уратылган ике катлы, кызыл кирпечтән эшләнгән Минзәлә төрмәсе күз алдымнан китмәде.

Соңрак, Колымадан әткәйнең беренче хаты килгәч, мин ерак Охота диңгезе буендагы мәңгелек бозлавык илендә урнашкан төрмәне дә нәкъ шулай — Минзәлә төрмәсе кебек итеп күз алдына китерә идем.

Колыма төрмәсен беркайчан да күрергә насыйп булмады, шөкер. Мондый җирләрдән Ходай үзе саклады.

Илле икенче елда без — инәкәй, энекәшләр, кечкенә сеңлем һәм мин — авылдан кысрыклаудан, хәерчелек һәм түлисе салымнан качып, Сарапул шәһәренә күченеп килдек. Тәүге тапкыр төрмәне дә Сарапулда күрдем. Иң гаҗәбе, мин ничек күзалласам — төрмә нәкъ шундый булып чыкты. Ул хәзер дә Кама ярында тора. Ике катлы. Кызыл кирпечтән. Тәрәзәләре рәшәткәле. Төрмәнең биек стеналары энәле тимерчыбык белән уратылган. Чын төрмәне күрүгә, торараштай катып калдым. Кырык җиденченең иртәсендә туган авылымны уяткан тальян моңын һәм ир-атның сагышлы җырын ишеткәндәй булдым:

Калаларда таш казарма
Бәхетсез балаларга...

Тормыш көтелмәгән хәлләрдән тора. Илле икенче елда инәкәйнең бертуган энесе — армиядән яңа кайткан Габделхәй абыйга ике катлы фин йортыннан бер бүлмә бирделәр. Йорт немец колониясендә булып, анда репрессиягә эләккән Идел буе немецлары яши иде. Сарапулда ике немец колониясе бар. Берсе — Сарапул елгасы белән Кама кушылган урында, шпал заводы янәшәсендә урнашкан. Шпал заводындагы бөтен авыр эш мескен немецлар җилкәсенә төште. Миңа — татар малаена да берничә ай монда эшләргә туры килде.

Тирә-юньгә яңа кискән агач һәм сумала исе таралган. Ул истән башлар әйләнә, зиһен томалана. Еракта калган яшьлегем исе ул. Кайвакыт хәзер дә тоям ул исне.

Икенче немец колониясе Ленин урамындагы тимер юл станциясе янында урнашкан. Без шунда илле сигезенче санлы йортка күченеп килдек. «Безнең» немецлар Габделхәй абый белән бергә агач эшкәртү предприятиесендә — урман комбинатында эшләделәр.

Кызык яшәдек. Немецлар русча такы-токы гына беләләр. Габделхәй абзыйдан кала, безнең гаиләдәгеләр дә ни немецча, ни русча сөйләшә белми. Фатирыбыз ике бүлмәле булып, аның берсендә улы белән фрау Марта яши. Искиткеч чиста күңелле, игелекле күршеләр. Аларның этиләре дә, безнең эти кебек үк, Сталин лагерында. Сталинга хөрмәт күрсәтмәгән өчен утыра. Без бик дус яшәдек. Тел белмәү аралашуга киртә булмады. Монда күчеп килгәч, безне иң шаккатырганы — электр лампочкалары булды. Гомере буе караңгы авылда яшәгән кешеләр өчен Ильич утлары цивилизациянең иң зур казанышы булып тоелды.

Барлык немецлар да гражданлык тавышыннан мәхрүм ителгән. Алар паспорт ала алмыйлар һәм төрле сайлауларда катнашмыйлар. Һәр немец айга бер тапкыр КГБның шәһәр идарәсендәге махсус комендатурага күренергә бара.

Безнең күршеләребезгә ара-тирә Казахстаннан хатлар килә. Конвертына махсус мөһер сугылган бу хатлар КГБ тикшерүе узалар иде. Марта түти сер итеп кенә көнчыгыш далаларда да немецлар яшәве хакында сөйләде. Шунда аларның туганнары да бар икән. КГБның махсус комендатурасы капитаны Деев Александр Александровичның безнең колониядәгеләрне тикшереп йөрүен яхшы хәтерлим.

Февраль аеның суык бер кичендә Деев безнең фатирга килеп керде. Кыска туннан, билен күн каеш белән буган. Тун эченнән шул чорның власть символы — күн курткасы күренә. Сул ягына күн планшет аскан. Ишек тавышына коты алынып, Марта түти килеп чыкты.

— Т-ә-ә-к,— дип сузды капитан, планшеттан кара китабын чыгарып,— Марта Вайхель. Билгеләп куям! Синең олы улың Борисны күрмим?

— Урамда йөри,— дип алдашты Марта түти. Борисны бүген төнгә кайтып җитәр дип көтә ул.

— Ярар. Иртәгә нәкъ шушы вакытта как штык өйдә булсын.

Борис икенче көнне дә кайтмады. Без аның соңгы тиеннәренә кадәр җыеп, Казахстандагы туганнарын күрергә китүен белә идек. 10 көн эчендә әйләнеп кайтырмын да, Деев сизмичә дә калыр дип уйлаган иде дә бит, әмма никтер һаман да юк.

Икенче көнне шул ук вакытта Деев безнең фатирга атылып килеп керде. Аның беренче сүзе шушы булды:

— Борис Вайхель кая? — Капитан Марта түтине үтәли тишәрдәй итеп карый, күз кырые белән генә безне дә тикшерә. Без, кечкенә энеләрем Фәнүс һәм Марсель белән, вакыйгалар барышын үзебезнең бүлмә ишеген ярым ачып күзәтәбез.

Марта түти, идәнгә карап, кирәкле рус сүзләрен көчкә җыеп, пышылдый:

— Өч көн элек кайтырга тиеш иде. Казахстанга сеңлем янына бер атнага китте. Менә... юк бит, тоткарланды бит. Кайту белән сезгә барыр...

Марта түтинең йөзе күренми. Бары тик күз яшьләре генә түбәдән тамган язгы тамчылар шикелле тып та тып идәнгә тамалар.

Борис бер атнадан гына кайтып җитте. Ач, өс-башы пычрак, үзе ябыгып беткән. Поездлар тоткарланып йөргәннәр. Паровозлары туңып, бозланып каткан. Коммунизмның шул этәргеч көченә утырып, Борис ике атна буе Сарапулга кайткан.

Ул кич кайтып керде. Капитан Деев, таң белән килеп, Борисны комендатурага алып китте. Өч көн узгач, 16 яшьлек Борис Вайхельның комендант режимын бозган өчен өч айга хөкем ителүен белдек.

Борис Старцево тавындагы төрмәдә утырды. Әтисе исә Колыма лагерында (әтисен 1956 елда гына, Сталин теге дөньяга киткәч кенә, азат иттеләр).

Марта түти кайгыдан саргайды. Бориска төрмәгә передача илтергә дә рөхсәт бирмәделәр. Шулай бервакыт бер бөтен ипи, бер кило «Дунькины радости» конфеты алып, дустым Борис Вайхельга тапшыру нияте белән төрмәгә киттем. Мине чал мыеклы старшина куып кайтарды. Әйбер тапшыру өчен КГБ (немецлар өчен генә) комендатурасы биргән махсус рөхсәт кәгазе кирәк икән.

Төрмәдән бераз ераклашкач, борылып артка карадым. Һәм... теге җырны яңадан ишеткәндәй булдым:

Калаларда таш казарма
Бәхетсез балаларга...

Төрмәдән туры КГБның комендатурасына киттем. Капитан Деевны коридорда ук күреп, аның артыннан кабинетына кердем.

Минем соравымны ишетүгә, Сталин опричнигы зәһәрләнде, яшелле-күкле тавыш белән акырды:

— Сиңа ни җитми, татарчонок? Ярамый! Аңлыйсыңмы, ярамый! Марш моннан! Каян килгән немчураны яклаучы...

Борис нәкъ өч ай дигән көнне өйгә кайтты. Лесокомбинатның такта яру цехына эшкә урнашты. Соңрак анда мебель ясау цехы төзеп куйдылар, лаклау өчен өр-яңа станоклар, заманча техника урнаштырдылар. Борис шунда столяр өйрәнчеге булып эшли башлады. Дүрт класс кына белемле булуына карамастан, Борис алтын куллы егет булып чыкты.

Бер-бер артлы ел артыннан ел үтте. Төрлебез төрле якка таралыштык, яңа фатирлар алдык. Немец дуслар белән очрашулар да сирәкләнгәннән сирәкләнде. Бервакыт Борис гаиләсе белән Көнбатыш Германиягә китеп, Штутгартта калган һәм столяр булып эшли икән, дигән хәбәр җиткерделәр. Аның столярлык эшенә һәвәслеген, алтын кулларын һәм немецларга гына хас төгәллеген ватандашлары бик тиз күреп алганнар һәм хезмәтенә тиешле бәя биргәннәр. Борис җитмешенче елларда ук автомобиль сатып алган, сиксәненче еллар уртасында кечерәк кенә мебель фабрикасы ачып җибәргән. Бер сүз белән әйткәндә, Борис Вайхель капиталистка әйләнгән.

Без яшьлек дустым Борис белән туксанынчы елларда Сарапулда очраштык. Ике Германия берләшкән чак. «Черек» Германиянең капиталисты, дустым, бер телем икмәкне урталай бүлеп ашаган күршем белән елашып күрештек. Рәхәтләнеп сөйләштек, истәлекләр белән уртаклаштык. Борис үзенә кунакка — Штутгартка чакырды. Бер читтә аның өр-яңа «Мерседес»ы ялт-йолт итеп тора. Аның арткы тәрәзәсенә нидер язылган:

— Тәрҗемә ит әле,— дим Бориска.

Бу болай килеп чыкты: «Германия — немецлар өчен генә!» Юк, минем яшьлек дустым нацист түгел. Мин моны ышанып әйтәм, чөнки ул Сарапулда үткән балачагы һәм яшьлек еллары турында сагынып сөйләде. Россияне яратуын әйтте. Автомобиль тәрәзәсендәге язу — Борисның үзен дә сыендырган ата-бабалары җиренә рәхмәте.

Советлар Союзы дип аталган империя бетүгә, Сарапулда немецлар бик аз калды. Туганнары һәм якыннарының каберләрен калдырып, чит җирләргә китәргә теләмәүчеләр иде алар.

Борис белән очрашудан бер генә үкенеч калды: без бергәләп Ленин урамындагы финский йортыбыз каршында фоторәсемгә төшмәдек. Ашыгу күп нәрсәне онытты ра шул.

Алай да 2000 елның сентябрендә Сарапулга баргач, җанга газиз 58 нче йорт каршына басып фоторәсемгә төштем. Ул хәзер бөтенләй башка. Стеналарын тыштан сылап, акшарлаганнар. Йорт үзе нык әле. Газы, суы, бәдрәфе һәм канализациясе дә булмаган бу йортта хәзер дә кешеләр яши. Алар яңа фатир бирүләрен көтәләр...

Сталин чорына кире кайтыйк әле. Мартның салкын, җил-давыллы бер көнендә халыкларның атасы, юлбашчы Иосиф Виссарионович Сталинның вафат булуын хәбәр иттеләр. Шәһәр кара кайгыга чумды. Юлбашчыны җирләү сәгате аеруча тетрәндергеч булды. Ленин урамындагы бар транспорт, бар халык туктап калды. Бичара кешеләр үксеп-үксеп елыйлар. Ул да булмады, завод-фабрика, автомобиль, паровоз гудоклары бар дөньяны яңгыратып гүләргә тотынды. Җан өзгеч мизгел!

Өйгә кайтып керсәм, Марта түти белән инәкәем кухняда елашып, шешенеп беткәннәр. Инәкәй мине күрүгә, кулы белән күз яшьләрен сөртеп алды.

— Улыкаем! Сталин үлде бит. Ничекләр яшәрбез аннан башка!

Мин, 16 яшьлек яшүсмер, түзеп тора алмадым, елап җибәрдем. Чынлап та, Сталинсыз ничек яшәргә соң?

Шушы вакыйга исемә төшә дә, гаҗәпләнүемнән һушларым китә: миллионнарча кешеләрне ничек итеп шушы кадәр үк ышандыра алдылар икән? Бичара фрау Мартаның да, инәкәйнең дә газиз ирләре Сталин төрмәсендә тилмерә, ә алар аны кызганып күз яше түгәләр.

Апрель азакларында безнең тимер юл станциясе аша көнчыгыштан көнбатышка таба Сталин тоткыннарын төягән беренче эшелоннар китте. 1945 елда Җиңү хәбәрен алган халык ничек сөенсә, бу эшелоннарны күреп шулай шатланды. Һәр гаилә кемне дә булса каршы алырга әзерләнде. Ярты ил халкы Сталин төрмәсендә иде бит.

Халык хөрриятка хозурланырга да өлгермәде, күңелгә шик-шөбһә килеп тулды: күзгә күренеп илдә җинаятьчелек тамыр җәйде.

Шул ук илле өченче елның беренче маенда Колымадан әтиебез кайтып төште. Кирәк бит — нәкъ шул вакытта унбер яшьлек энекәшем Фәнүс тимер юл станциясендә булган. Станциядә тиктомалдан гына йөрми иде ул. Безнең станция аша ireккә чыккан тоткыннарның беренче эшелоны үткән көнне үк, паровоз туктап торган арада, тоткыннар бөтен кибет, ларек, буфетларны тар-мар китереп, җимереп бетергәннәр. Сталин үлгән бит, рәхәтләнеп типтер, янәсе!

Тоткыннар үз вагоннарына кочак-кочак урланган мал ташыйлар, алардан төшеп калганны малайшалай, шул исәптән безнең Фәнүс тә эләктерә икән.

Шулай итеп, әткәй Фәнүсне вагон ишек төбендә үк күреп алган.

— Улым, син нишлисең монда? — дип сораган әткәй аптырап.

Аерылуга дүрт ел ярым вакыт үтүгә карамастан, әткәй белән Фәнүс бер-берсен бик тиз танып алганнар. Энем әткәйне немец колониясендәге финский йортка алып кайтты. Шулай итеп, әткәйне Минзәлә төрмәсенә мин гармун тартып, җырлап озаткан идем. Энем исә аны әтиебез өчен бөтенләй чит булган, безне үзенә сыендырган Урал төбәгендә поезддан каршы алды. Дүрт ел фронтта, дүрт ел ярым төрмәдә утырып кайткан әтиебезгә нибары 39 яшь иде. Өстендә сырган озын фуфайка, аягында кирза итекләр. Төсе уңып беткән киҗе-мамык костюмында тоткын номеры булган кара урын. Кулына фанер чемодан тоткан. Бик озак кына аның фуфайкасын матрас урынына йөрттек. Чемодан да эшкә ярады — әни аңа салып, сатарга дип, авылдан йомырка ташыды.

Иреккә чыккач, әтиебез бик уйчанланды. Туган якны сагына иде ул. Эчкәли дә башлады. Эчсә, һаман бер җырны җырлый:

Калаларда таш казарма
Бәхетсез балаларга...

Җырлап туктар иде дә, озаклап елар иде. Әмма беркайчан да төрмәдә күргәннәре турында сөйләмәде. Ел ярымнан гүр иясе булды. Сеңлебез Галиягә бер яшь тә тулмаган иде әле.

Шул чакта ник әтиемнең башыннан узганнары турында төпченмәдем икән? Нишләп мин аның серен ачтырып, шәхси трагедиясен һәм гаиләбез трагедиясен беләлмадым? Шуның өчен гомерем буе үкенәм.

Колыма һәм башка лагерьлар турында бик күп документаль әсәрләр укыганым бар. «Сталин төрмәсе» дигән мәхшәрдән исән калучыларны шактый күп очраттым. Тоткыннар белән дә, аларны саклаучылар белән дә сөйләшкәнем бар. Хәер, сакчылар тоткыннардан барыбер әллә ни аерылып тормыйлар иде. Сакчыларның шулпасы куерак булгандыр да, картлык көннәрендә пенсияләре хәллерәктер. Ә тоткыннарның утырган чоры, алар кулы белән әллә ниләр эшләнсә дә, хезмәт стажына кертелмәде.

Күп кенә танышларыма һәм туганнарыма шул елларда югалган дөреслекне табып, исемнәрен акларга ярдәм иттем. Беләсезме мин нәрсәгә шаккатам? КГБ архивларында күпләрнең документлары саклана. Минем соравым буенча кайберәүләрнең үлем турындагы таныклыкларын да җибәрделәр. СССР гербы төшерелгән документта «Ни сәбәпле вафат булган» дип язылган графа бар. Шунда матур каллиграфик хәрефләр белән коточкыч җөмлә язылган: «Атып үтерелгән».

Россия Юстициясе министрлыгының полковнигы (ул элек Колымада эшләгән) белән булган бер очрашу истә калган. Аның сүзләренә караганда, Колыма лагерьлары бүген дә яхшы сакланган. Алар буш кына, Аллага шөкер.

Дистә еллар үтеп, олыгая төшкәч, әтиемнең арестант тормышы башланган Минзәлә төрмәсенең нинди икәнлеген дә белмәвемә пошына башладым. Әтием генә түгел, күп кенә авылдашларым да утырган анда. Бәлки, мин Минзәлә төрмәсен рәшәткә белән капланган тәрәзәле, чәнечкеле тимерчыбык белән әйләндереп алынган шыксыз урын итеп күз алдына китереп бик нык ялгышамдыр?

Ике меңенче елның декабрендә без, туганнан-туган абыем Рифкать белән, «Волга» машинасына утырып, Чаллыдан Минзәләгә юл алдык.

Минзәлә заманча шәһәрләрдән нык калыша. Екатерина патшабикә Минзәләдә булып киткәннән соң, монда тормыш туктап калган диярсең. Монда Екатерина белән, ул хакимлек иткән чор белән чиксез горурланалар. Шәһәр халкы Минзәлә елгасы аша Екатерина патшабикә килүгә салынган тимер күпер белән мактана. Бу күпер аша кайчан транспорт йөргәнен дә хәтерләүче кеше юк инде хәзер. Районның ярты мәйданын су басу сәбәпле, күпер челтәрле утрау булып су уртасында калган. Ул — бүген кеше кулының табигатьне үзгәртерлек һәлакәтле көч икәнлеген күрсәтүче бер һәйкәл.

Шыксыз урамнар аша бераз адашып йөргәч, төрмә каршына килеп туктадык. Ул «фәләненче санлы учреждение» дип йөртелә икән. Машинадан чыгуга ук, кәефем төште. Бернинди дә ике катлы бина күренеп тормый. Биек кирпеч койма. Акшарланган. Өстән әллә ничә кат энәле тимерчыбык белән әйләндерелгән. Зур тимер капкалар. Койма артында озын ак бина. Түбәсе энәле тимерчыбык белән чорналып беткән. Нәкъ шушы коточкыч җиргә әтиемне, туганнарымны, якташларымны китереп атканнар да төрлечә җәзалаганнар.

Ирексездән тальянга кушылып җырлаган ир-ат хәтеремә килеп төште:

> Калаларда таш казарма
> Бәхетсез балаларга...

«Кодак» фотоаппаратын портфелемнән чыгардым. Шоферым Рамилгә абыем белән икебезне төрмә капкасы янында, ике катлы казарма фонында карточкага төшерергә куштым. Рамил төймәгә басып, ике кадр ясарга өлгердеме, юкмы, безне чуар киемле сигез әзмәвер уратып алды. Барысы да коралланган. Берсе гөбердәп торган тавыш белән команда бирде:

— Карточкага төшүне туктатыгыз! Фотоаппаратны миңа бирегез!

Шоферымның кулыннан «Кодак»ны яшен тизлегендә тартып алдым да тун кесәмә яшердем. Командир, атылып килеп, кулларымны артка каерды. Мин аның симерүдән кызарган чыраена карап кычкырам:

— Кулыңны ал миннән! Минем рөхсәт кәгазем бар!

Кулларымны ычкындырдылар.

— Режимдагы объект, фотога төшерергә ярамый. Кем белә, бәлки, сез теракт әзерләп йөрисездер.

Язучы, корреспондент таныклыкларын, махсус алынган справкамны күрсәтәм.

— Егетләр! Мин бернинди дә теракт әзерләмим. Моннан күп еллар элек бу төрмәдә әтием утырды. Туганнар, якташлар да булды монда. Истәлек өчен фоторәсемгә төшмәкче идем. Бу төрмә җанымдагы иң тирән, иң моңсу хатирә бит...

— Барыбер төшерергә ярамый.— Өлкәнрәк яшьтәге бер «чуар әзмәвер» һаман үзенекен талкый.— Пленкагызны яктыртыгыз.

Мин карышуымны дәвам итәм:

— Юк! Сез минем хокукларымны бозасыз!

— Алайса киттек начальникка. Анда аңлашырбыз.

— Киттек,— дим кызып.

Сигез әзмәвер белән бергә төрмәнең, ягъни «фәләненче санлы учреждение»нең капкасына таба юнәләбез. Мине алга үткәрәләр. Рәшәткәле капка әллә нинди тавышлар белән ыңгырашып үзеннән-үзе ачылып китте. Без эчкә үттек, капка ябылды. Аннан тагын ике капка аша үттек. Минем белән янәшә барган әзмәвер, өченче капка ябылгач, уңга, диде. Җидесе шунда басып калды. Шатлыктан йөзләре балкый. Ник дисәң, төрмә янында «эре кош»ны тотып, шуны начальникка алып баралар бит!

Озын тар коридор. Түшәмнәре тәбәнәк. Ике яклап кечкенә тәрәзәле каморкалар тезелеп киткән. Бу коридордан шулкадәр озак бардык, миңа кечкенә генә тар җирдән шуышкан шикелле тоела башлады. Кечкенә тәрәзәле кабинетка килеп җиткәч, туктадык. Ишектәге язуны да рәтләп укый алмадым: әллә төрмә начальнигының режим буенча урынбасары, әллә ярдәмчесе. Кабинетта илленче еллардан ук калган хәерчелек хөкем сөрә. Мебель дип әйтерлеге дә калмаган язу өстәле һәм дүрт урындык — бар җиһаз шушы.

Озата килгән әзмәвер, үземне генә калдырып, чыгып китте. Шул арада башымда мең уй кайнады.

Беренчедән, урамда бернинди дә телевизион камералар күренмәде. Ничек итеп төрмә сакчылары безне күреп алдылар икән?

Ул да булмады, икенче уй хәтер йомгагын сүтә башлады.

Бәлки, 1948 елда этием нәкъ шушы камерада утыргандыр. Кем белә, бәлки, нәкъ шушы урында «колхоз ашлыгын кая куйдың?» дип җәзалаганнардыр?

Күрше Татар Суксуы авылында яшәгән туганыбыз Мәрхәбә апа искә төште. 1948 елның җәендә ул һәм тагын берничә колхозчы хатын-кыз уракларын иңнәренә салып басудан кайталар икән. Барысы да арыган, ачыккан. Авыл янындагы зират буенда уракчыларны райком вәкилләре каршы ала һәм тенти башлыйлар. Һәр хатынның ыштаны эченнән махсус тегелгән чүпрәк капчыклар табып 2,5–3әр кило бодай алалар. Мескенкәйләрнең өйләрендә балалары ачтан шешенеп ята бит...

Кирәкле кәгазьләрне тиз тутыралар. Хатыннарга «халык дошманнары, дәүләт милкен таратучылар» дигән хурлыклы исем тагып, башта Актаныш КПЗсына, соңыннан шушы Минзәлә төрмәсенә озаталар.

Кайсына биш, кайсына алты ел бирәләр. Белсеннәр, янәсе, колхоз басуындагы уңышка кул сузарга бераүнең дә хокукы юк! Чөнки ул синең басу түгел, син җирдә бары тик эшләргә генә тиеш...

Ул заманда авылыбыз аша атна саен ач, хәлсез, мескен хатын-кызларны, төркем-төркем итеп, Минзәлә төрмәсенә алып китәләр иде. Өйләрендә нәни балалары ятим кала. Күпләренең ирләре Бөек Ватан сугышында яу кырларында башларын салганнар. Без гитлерчы башкисәрләрнең Совет җирендәге кыланмышлары турында китаплар укырга, кинолар карарга яратабыз. Әмма бүгенге көнгә кадәр үзебезнең илдә Сталин иярченнәренең кыланмышларына дөрес бәя бирә белмибез әле.

Утырып чыккач, Мәрхәбә апа Минзәлә төрмәсендә ничек итеп сорау алганнарын искә төшерә иде. «Урлаган ипиегезне кая яшердегез?» — дип, теңкәләренә тияләр икән. «Иң куркыныч җәза — резина капчык иде. Кешене шул капчыкка кертеп, капчыкны бәйләп куялар. Һава тутыралар да палачлар капчыкка таяк белән суга башлыйлар. Аңны югалтып егыла идек, колактан, авыз-борыннан ургылып кан ага башлый»,— дип сөйли иде Мәрхәбә апа. Күзләре дымланса да, ул еламый, чөнки барлык яшьләрен Минзәлә төрмәсендә калдырган...

Күңелсез уйларымны бүлеп, кабинет хуҗасы килеп керде һәм төрмә начальнигының мине чакыруын әйтте.

Начальник кабинеты янәшә диярлек. Зур түгел. Кечкенә тәрәзәсе рәшәткәле. Башымнан яшен тизлегендә бер фикер үтә: төрмә начальнигы — Җәза министрлыгының хәрби кешесе — гражданский киемдәге ир-ат та гомерен шушы казармада үткәрә. Теге сигез әзмәвер дә шул ук язмышка дучар ителгән. Бу минутта алар түземсезлек белән начальникларының миңа карата карарын көтәләр.

Өстәлдә нинди дер крепостьның ясалган макеты. Бер почмакта икона эленгән. Төрмә җитәкчеләренең үз кабинетларын тоткыннарның кул эшләре белән бизәргә яратуы хакында белә идем. Озак еллар утырганнарда әллә нинди талантлар барлыкка килә. Стенаның бер ягында Татарстан Президенты М.Шәймиев, икенче ягында Россия Президенты В.Путинның портретлары эленгән.

Төрмә начальнигы итагатьле, әдәпле булып чыкты. Башта документларымны күрсәтүне сорады. Укыгач, кире бирде. Минзәләгә ни өчен килүем белән кызыксынды. Ни өчен режимдагы объектны фоторәсемгә төшерүем турында сорады.

Мин дә, сабыр гына итеп, Минзәлә төрмәсен шартлатып, «браток»ларны ireккә чыгарырга җыенмавым хакында әйттем. Гомумән, «браток»ларым юк минем. Моннан еракта яшәүче ике ир туганым гына бар. Минзәлә төрмәсенең үзем өчен истәлекле урын булуы, монда этием һәм башка туганнарым, якташларым утыруы турында сөйләдем.

Кыскасы, төрмә начальнигы белән бик матур итеп сөйләшеп утырдык. Ул көтмәгәндә болай диде:

— Әйе, монда күпләр утырган шул. Тик беләсе иде: ни өчен утыртканнар?

Начальник Минзәлә тарихы белән дә таныштырды. Бу урында элек болгарлар яшәгән. Иван Грозный Казан ханлыгын яулап алгач, 1584 елда Минзәлә шәһәренә нигез салына. Төрмәнең дә «данлы» тарихы бар икән. Ул Россия империясе баскыннарына каршы чыккан болгар токымын — татарларны утырту өчен төзел-

гән. Екатерина II — Әби патша идарә иткән чорда төрмәне «Минзәлә острогы» дип йөртә башлыйлар. Өстәлдәге макет шул чордагы төрмәнеке икән. Ул рәсемнәрдән күчереп эшләнгән.

Төрмә начальнигы миңа шул макет фотографиясен бүләк итте. Мин аңа чиксез рәхмәтләремне әйттем. Чыннан да, бик рәхмәтле мин аңа. Начальник төрмә капкасы янында төшкән фотоны беркайчан да бастырмаска кушты.

«Уйлап карармын» дип вәгъдә бирдем. Әмма ныклап уйлагач, рәсемне әлеге китапта дөньяга чыгарырга булдым. Чөнки төрмә Африкада да төрмә булып кала...

Соңыннан начальник капка янына кадәр озата килде һәм мине чыгарып җибәрергә кушты. Сигез әзмәвер яныннан үткәндә честь бирдем. Соңгы капкадан чыгуга, артыма борылып, кул болгадым һәм кычкырып җырлап җибәрдем:

Калаларда таш казарма
Бәхетсез балаларга...

## *Зәңгәр таудан яулык болгармын*

Мөнирә, аның унбер яшьлек улы Мәгъсүм һәм «уф алла» арбасындагы җиде айлык кызы Мостафидә район милициясе бинасы янына килеп җиткәндә, Актаныш тавы артыннан, ялтырап торган бакыр тәлинкәне хәтерләтеп, кояш күтәрелеп килә иде. Район үзәгенең йокыдан арынырга өлгермәгән халкы, мал-туарларын көтүгә куып, Агыйдел тугаеннан кайтып киләләр иде инде. Урамда сентябрь хакимлек итә. Кышның якынлашып килүе сизелә. Шулай да кояшның куе кызыллыгы әйбәт көн вәгъдә итә иде. Әбиләр чуагының соңгы көннәре.

Кырыгынчы-илленче елларда Актаныш халкы район милициясе бүлеген «төрмә» дип атый иде. Мөгаен, менә ни өчендер: кечкенә генә гаепләре булса да, авыллардагы ир-ат халкын КПЗга — район бүлегенең хөкем алдыннан ябып куюу урынына җыялар, аннары җәяүләп тирә-юньдә даны таралган Минзәлә төрмәсенә озаталар. Ә Куян, Илчебай, Уразай, Такталачык, Чалманарат, Шәбез, Калмаш, Түбән - Карач, Уръяды, Күҗәкә, Пучы авыллары аша Минзәләгә бара торган юлны «төрмә юлы» дип атыйлар иде.

...«Актаныш төрмәсе» тау итәгенә җайсыз гына кереп сыенган. Вакыт үтү белән җилдән-яңгырдан каралган дүрт метр чамасындагы биек коймасы тутыгып беткән чәнечкеле тимерчыбык белән уратып алынган. Тирә-юнендә бернинди җан әсәре юк. Мөнирә милиция бүлегенең тышкы ишеге тоткасын тартты. Ишек эчтән бикле иде. Ул кыяр-кыймас кына ишек шакыды. Озак та үтмәде, ишек шыгырдап ачылды. Болдырга йокымсыраган күзләрен куллары белән уа-уа, куе зәңгәр төстәге униформа кигән, галифе чалбарының балакларын инде шактый таушалырга өлгергән кирза итекләренә тыккан старшина чыкты. Мәгъсүм әнкәсенең нәрсә сораганын ишетмәде, әмма старшинаның карлыккан тавыш белән әйткәне аның колагына ачыктан-ачык килеп керде:

— Ярты сәгать элек тауга менеп киттеләр. Актанышбаш авылы аша баралар. Бәлки, куып та җитәрсез әле...

Әнкәсе җиде айлык Мостафидәсе мышнап яткан «уф алла» арбасы янына килде. Кызы белән янәшә арестант әтиләренә дигән азык-төлек һәм... Мәгъсүмнең тальян гармуны ята иде. Мөнирә ирен бередә күрергә өлгерә алмау гарьлегеннән, күз яшьләрен тыя алмыйча, елап җибәрде. Мондагы арестантлар төркемен Минзәлә төрмәсенә аның борын төбеннән үк диярлек алып киттеләр бит. Югыйсә өлгергән дә булырлар иде, гөнаһ шомлыгына каршы, төнлә Чалманарат авылында тоткарландылар. Туган авылы Түбән Карачтан чыкканда, төн уртасына хәтле шактый вакыт бар иде әле. Мөнирә балалары белән төнге караңгылыкта чакрым артыннан чакрым калдырды. Чалманаратны чыгып, озак та бармадылар, юлга авып торган урманнан бүреләрнең көчле улавы юлчыларны туктарга мәҗбүр итте. Бу бер бүре улавы гына түгел, ә бөтен бер өерне куркытып аваз салуы иде. Ул елларда Актаныш тирәсендә йөрүче бу соры ерткычлар санап бетергесез иде. Кышын алар авылларга кереп абзарлардан сарыкларны да алып киткәлиләр иде. Берне генә алып китсәләр ярар иде әле, абзардагы бөтен малны буып чыгалар бит.

Ә җәен бу ерткычлар көтүләргә һөҗүм итәләр. Күпне күргән көтүчеләр дә бүреләрнең сарыкларны яки бәрәннәрне бик ыспай гына сыртларына салып элдертүләренә шаккаталар иде.

Актаныш юлында бүреләрнең төнге улавы Мөнирәнең хәтерендә шушы ерткычларга бәйле коточкыч вакыйгаларны яңартты. Беренче әтәчләргә хәтле булса да көтәргә кирәк дип, ул балалары белән кирегә, Чалманарат авылына таба борылды. Авыл кырыендагы өйдә яшәүче, ирен фронтта югалткан тол хатын, бүреләр туе үткәнче дип, аларны бик теләп кунарга кертте. Менә шушында инде Мөнирә «сер итеп кенә» үзенең тормышы турында сөйләде.

Актаныш якларында халыкның ничек интеккәнен ачлыкны үзе татыган кеше генә белә. Сугыш елларында әле халык ничектер чыдады. Сугышка кадәрге запаслар ярдәм итте. Сугышның тиз бетәчәгенә өмет уты сүнмәгән иде — шул коткарды. Бар халыкны чолгап алган ачлык һәм үләт сугыштан соңгы кырык алтынчы елда башланды. Кырык җиденчедә аннан да начаррак булды. Кешеләр бөтен гаиләләре белән колхозда коры хезмәт көненә — «таяк»ка эшләделәр. Хезмәтләре өчен алар колхоздан бер грамм

да ашлык алмадылар. Башка урыннарда ничек булгандыр, белмим, ә менә безнең Актаныш якларында кырык сигезенче ел икмәкле булды. Чапаев исемендәге колхоз да ашлык хәзерләү планын вакытында үтәде. Партия райкомы хезмәт көненә икешәр йөз грамм икмәк бирергә рөхсәт итте. Ел дәверендә фидакарь эшләгән һәр хуҗалык икешәр-өчәр, иң күбе дүрт капчык арыш, икенче сорт бодай алды. Шулай да кешеләрнең күңелләре күтәрелеп китте, кышын ачтан үлмәячәкләренә өметләре артты.

Чапаев исемендәге колхоз амбарларында ашлык калган иде әле. Колхоз рәисе, идарә әгъзалары белән киңәшеп, хезмәт көненә тагын икешәр йөз грамм ашлык бирергә булды. Бу турыда район җитәкчеләренә әйтеп торуны кирәк дип санамады. Хәзерләүләр планы үтәлгән иде. Идарәдә ничек карар кылдылар — шулай эшләделәр.

Гомер-гомергә шулай килә бит: һәр коллективның, һәр милләтнең үзенең сатлык җаны була. Хәер, сатлык җанның милләте дә юк инде. Авылның менә шундый бер «яхшылык теләүчесе» дәүләт ашлыгын «әрәм-шәрәм итүләре» турында кирәк җиргә хәбәр итә. Колхоз рәисен, киңәшмәгә дигән булып, район үзәгенә чакырдылар. Актанышка барып җитүенә КПЗ-төрмәгә ябып та куйдылар.

Ике атнадан соң Актаныншта ветеринария табибы булып эшләүче туганнары Җамал апа, Түбән Карач аша үтеп барышлый, Мөнирәгә арестантларны Минзәләгә алып китү вакытын хәбәр итте. Пешкән әйберләр, сохари, бер банка атланмай, бераз эремчек әзерләп, Мөнирә Актаныш төрмәсе янына килде...

Ирен, балаларының сөекле әтиләрен очрата алмау гарьлегеннән елап алганнан соң, яулык чите белән күз яшьләрен сөртеп алды да:

— Йөгерик, улым. Барыбер куып җитәчәкбез,— диде.

Мөнирә белән Мәгъсүм, «уф алла»ның тәртәләреннән эләктереп, тау ягына, Актанышбаш авылына таба йөгерделәр. Башта юл тигез иде, арбаны җиңел генә тартып бардылар. Тиздән басу башланды. Ерак та түгел, игеннәре җыелган кырларны сукалап йөрүче «НАТИ» тракторы гөрелтесе ишетелде. Тракторчы кырны гына сөреп барса ярар иде әле. Ул бит җәй буена тыгызланып тигезләнгән басу юлы аркылы чыкканда да сабанын кирәгенчә күтәртми. Нәтиҗәдә юл чокырлы-чакырлы булып беткән.

— Шушы юлны сөрмәсә булмый микәнни инде,— дип зарланды Мөнирә, арбаны сөйри-сөйри.

Сикәлтәле юлда арбаның дыңгырдавыннан уянып, Мостафидә елый башлады. Әнисе аны кулларына алды һәм сабыен юата-юата сөргән җир өстеннән алга таба йөгерде. Унбер яшьлек Мәгъсүм ашамлыклар һәм тальян гармун салынган арбаны үзе генә тартып барды.

Тиргә батырган сөрүле җирне үтеп, Актанышбашка килеп керделәр.

— Моннан арестантлар узмадымы? — дип сорады Мөнирә беренче очраган карчыктан.

— Әле генә үтеп киттеләр, җаныем, и-и...— диде карчык.— Әле генә әнә теге тыкрыкка кереп киттеләр.

Тиз арада авыл урамын үтеп, басу капкасы янына килеп җиттеләр. Мөнирә әкрен генә атлап баручы колоннаны күреп алды. Алларыннан җигүле ат бара. Арбага ике конвоир утырган. Алар артыннан, кулларын артка куеп, ундүрт арестант бара. Колонна артыннан арбага җигелгән тагын бер ат. Анысында ярым яткан хәлдә надзирательләр бара.

— Алар! — диде Мөнирә.

Колхоз рәисе гаиләсен күреп алды булса кирәк, конвоирдан туктап алырга сорады. Мөгаен, аңарга рөхсәт иткәннәрдер, ул кирегә, гаиләсенә каршы китте. Ир белән хатын кочаклаштылар. Аннары әтисе Мәгъсүмне кысып кочаклады. Конвоирлар моны күреп, гаҗәпләнүдән башларын селкеп куйдылар. Арбадан сикереп төшеп, әйберләрен, күкрәк баласын арбага салырга, Мәгъсүм белән Мөнирәгә утырырга тәкъдим иттеләр.

— Ә монысы нәрсә? — диде конвоир, тальян гармунга бармагы белән төртеп күрсәтеп.

— Болай гына, гадәт буенча,— диде Мәгъсүм.

Әнкәсенең каршы килүенә дә карамастан, ул аны яулыкка төреп арбага салган иде. Мәгъсүм тальянкада уйнарга кече яшьтән үк өйрәнде. Ул тирә-юньдә бердәнбер гармунчы иде. Музыка коралын һәрвакыт үзе белән йөртте.

Конвоирлар Минзәлә керәшеннәре булып чыктылар. Гармунны алар зур кызыксыну белән карадылар. Аларның берсе (соңыннан билгеле булганча, бу алар арасында иң башы булып чыкты) кисәктән генә сорап куйды:

— Әллә уйный беләсеңме?

— Беләм,— диде Мәгъсүм, уңайсызланып кына.

Мөнирә кызын имезергә тотынды. Әтиләре арба кырыенда бару уңаеннан хатыны пешергән коймак белән сыйланды.

Конвоирларның икесе арбадан арттарак калып барды. Актанышбаштан шактый ара киткәч, конвоир башлыгының күңеле чыдамады булса кирәк, арба янына килде дә, ягымлы гына итеп, Мәгъсүмгә мөрәҗәгать итте:

— Уйнап күрсәт әле...

Мәгъсүм ашыкмыйча гына яулыкны чиште, перламутрдагы кояш чагылышыннан конвоирның күзен камаштырып, тальян гармуны килеп чыкты. Конвой башлыгының күзләре ялтырап куйды. Мөгаен,

жандармнар күңеле дә моңга сусаган булгандыр. Ул түземсезлек белән әле тальянкага, әле аның хуҗасына — үсмер малайга карады.

— Нинди көй уйныйм? — дип сорады Мәгъсүм.

— Ниндине беләсең...— диде конвоир.

Мәгъсүм, энкавыдышникларның озата баручы атына утырып, тальянкасының төрле рәсемнәр белән бизәлгән күреген тартып җибәрде, һәм ул елларда һәркемнең яраткан җырын— «Шахта көе»н уйный башлады. Аның моңы, күңел кылларын тибрәндереп, игеннәре җыелган басуларга, урман полосаларындагы алтын яфраклар белән бизәлгән нәфис каеннар арасына таралды. Әбиләр чуагының соңгы көннәре. Кая карама, шунда урман, урман полосалары кояшта ялтырауычы сары яфраклары белән әкият дөньясын хәтерләтеп торалар иде. Ара-тирә ак пәрәвезләр оча. Кояш, үзенең җир патшалыгына соңгы нурларын сибеп, офыктан күтәрелә иде.

Колоннадагы арестантларга да җан кергәндәй булды. Тальянкадан агылган моңлы көйне ишетеп, алар борылып малай утырган арбага таба карап алдылар.

Әгәр читтән күзәтеп торсаң, бу гаҗәп бер сәфәр кылу иде. Алда, арбада, конвоирлар, уртада арестантлар атлый. Алар артыннан шулай ук конвоирлар бара. Бөтен бу процессияне музыка озата. Әллә инде бу кешеләр Сабан туена бара, әллә инде күрше авылга — туйга.

Баш конвоир кинәттән генә арбага сикереп менде дә, гармунчы янәшәсенә утырып, гармунга кушылып җыр сузып җибәрде. Тавышы ярыйсы гына моңлы иде. Ул чын күңелдән, матур итеп җыр башлады.

Йөгерә барам, йөгерә кайтам,
Шахта юлларында мин.
Эшлим, ашыйм, рәхәт яшим
Совет илләрендә мин.

Бу авылара юл иде. Тирә-юньдә кешеләр күренмәде. Шуңа күрәдер, баш конвоир шикләнмичә, оялмыйча, бөтен күңелен биреп җырлады.

Шахтер егет күмер вата
Вак-вак итеп кисәген.
Гомерем булып таш басмаса,
Ташламам, җанкисәгем...

Мәгъсүмнең әтисе арба белән янәшә бара һәм улын мактый:

— Иллә дә маладис инде син, улым. Гармуныңны үзең белән алып бик дөрес эшләгәнсең.

Бара-бара Шәрип авылына килеп җиттеләр. Авылга керер алдыннан, баш конвоир этиләренә колоннага басарга, ә гармунчыга бераз тынып торырга кушты. Шәрипне чыгып, ярты чакрымнар киткәч, конвоир башлыгы янә этиләрен чакыртып алды да Мәгъсүмгә мөрәҗәгать итте:

— Җиббәр тагын.

Мәгъсүм «Сарман»ны уйнап җибәрде. Баш конвоир да гармунга кушылды.

Сарман буйларында яшел алан,
Печәннәре җитәр берзаман...

Җыр, еракларга, алтын яфракларга күмелгән урманнарга барып җитеп, серле рәвештә кире әйләнеп кайта сыман иде.

Бу минутларда барлык арестантлар да күз яшьләрен тыя алмыйлар иде. Алар арасында дүрт хатынкыз да бар. Мөнирә дә күз яшьләрен сөртә-сөртә, юл уңаена иренә авылдагы яңалыклар турында сөйләде. Элеккеге колхоз рәисе хатынын дикъкать белән тыңлады, кай араларда сүз кыстыргалады:

— Балаларны сакла. Әнкәй ничек анда? Аны кыерсыта күрмә.

Бары тик җиде айлык Мостафидә генә, барысыннан да канәгать булып, жандарм арбасына чалкан яткан килеш, сентябрь кояшы шәүләләрен авызы белән тоткалый иде.

Мәгъсүм тальянкасын тартуын дәвам итте. Баш конвоир, музыка тәэсиреннәнме, күзләрен йомып, бик оста итеп җыр суза иде:

Сарман буйларыннан үткән чакта
Тыңларсыңмы, җырлар җырлармын.
Күзләреңне тутырып карарсыңмы?
Зәңгәр таудан яулык болгармын.

Сугыштан соңгы авыр елларда хәзерге заманыбызның «ультрамашина»лары элдертә торган Пучыдан Актанышка баручы туры асфальт юл кешеләрнең төшләренә дә керми иде. Юллар барлык авыллар аша үтә иде. Менә арестантлар колоннасы да Теләкәй авылына якынлашты. Баш жандарм колоннаны тәртипкә китерде. Мәгъсүм тальянкасын яулыкка төрде. Чагыштырмача зур саналган бу авылда төшке аш ашап алырга һәм ял итәргә булдылар.

Төштән соң колонна тагын юлга чыкты. Пучыга, аннан Минзәләгә юл Иске Кормаш һәм Яңа Кормаш араларыннан үтә. Асылда, сиксәненче елларда асфальтны нәкъ менә шушы беткән юл өстенә салдылар.

Көзге көн бик кыска. Кояш бик тиз түбән таба тәгәрәде. Аның нурлары да көндезге кебек җылы түгел иде инде. Колонна тау буендагы борылышка килеп җитте. Мөнирә балалары белән моннан Яңа Кормаш авылындагы үзәк усадьбада төшәргә, ә аннан ике чакрым ярымнар юл үтеп, Түбән Карач дигән бик матур исемле кечкенә генә авылга — туган җиренә барып җитәргә тиеш.

Юллар чатында баш конвоир колоннаны туктатты һәм саубуллашу хөрмәтенә «Сарман»ны уйнауны сорады. Мәгъсүм, гармунын кулына алып, моңлы көйне сыздырып җибәрде. Конвоир гармунга кушылды:

Сарман буйларыннан үткән чакта
Тыңларсыңмы, җырлар җырлармын.
Күзләреңне тутырып карарсыңмы?
Зәңгәр таудан яулык болгармын.

Колхоз рәисе күкрәк баласын кулларына алып сөйде дә, улы Мәгъсүмне кочаклап, кулларына күтәрде. Аннары хатыны Мөнирәне кочагына кысты. Шуннан соң ашыкмыйча гына колоннага барып басты. Колонна башлыгы да юлга кузгалыр алдыннан Мәгъсүмне кочагына алды һәм битеннән үпте.

— Тормышта беркайчан да боекма. Ә тальянкаңа килсәк, ул сине һәрвакыт коткарыр. Сакла син аны. Ә хәзер саубуллашу хакына уйна әле тагын «Сарман»ны,— диде.

Мәгъсүм, юл кырыена баскан килеш, ихлас күңеленнән уйнады. Колонна офыкка таба, Минзәлә ягына таба ераклашканнан-ераклаша барды. Баш конвоирның үзәк өзгеч тавыш белән чын күңеленнән җырлавы озак вакытлар ишетелеп торды:

Әмма аерылышулары бик яман, бик яма-а-ан...

Баш очыннан өчпочмак булып тезелеп, кыр казлары көньякка таба очтылар. Аларның каңгылдаулары гүя конвоир җырына кушыла иде:

Зәңгәр таудан яулык болгармын, болгармын,
болгармын...

Тиздән колонна кечке офыкта эреп күздән югалды.

Мөнирә белән Мәгъсүм, күз яшьләрен сөртә-сөртә, җиде айлык Мостафидә утырган һәм тальянка салынган «уф алла»ны сүзсез генә тартып бардылар. Алар үз авылларына кайталар иде. Җырның «Аерылышулары бик яман, бик яман, бик яма-а-ан...» дигән сүзләре аларның колак төбендә берөзлексез яңгырый иде.

### *Мөнирә ихатасы*

Хәзер инде безнең өчен күптәнге саналган сугыштан соңгы елларда, шәһәр халкы заводлар сызгырткан гудоктан-гудокка яши иде. Һәр заводның, хәтта кечкенә генә производство артеленең дә үз гудогы бар. Иртән, төш вакытында эш төгәлләнгәннән соң, һәркайсы үз җаена, үзенә генә хас тавыш чыгарып кычкырта. Кайсыдыр ягы белән алар таң әтәчләрен хәтерләтәләр иде. Авылда кем әтәче кычкырганны белгән кебек, шәһәрдәгеләр дә үз заводларының гудок тавышын әллә кайдан беләләр. Бу гудокларны һич кенә дә бутарга мөмкин түгел.

Ул елларда сәгатьләр бик сирәк кешедә генә бар иде. Ә кул яки кесә сәгате артык байлык саналды. Менә шулай яшиләр иде инде кешеләр. Катгый расписаниене кырыс нәчәлство ничек төзесә, гудоклар шулай кычкырта бирәләр. Ә менә шушы гудоклы эш тәртибенә сыешмый кара әле?! Сине каты җәза көтә. Унбиш минутка соңга каласың икән — сине шул ук көнне ярты елга чаклы төрмәгә утыртырга мөмкиннәр. Производствоның мөһимлеген дә исәпкә алалар, хәрби заводта эшлисең икән — аңа күбрәк. Аларда тәртип бигрәк тә каты иде. Ә бит андый предприятиеләр ул чакта күпчелекне хасил итте.

Авылда, билгеле инде, гудоклар юк иде. Ә сәгатьләр турында сөйләп тә тормыйм. Кул сәгатьләре юк та юк инде. Хәтта күкеле стена сәгатьләрен дә көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың. Авылда кояш чыгуга, кояш батуга юнәлеш алып эшләделәр. Колхозда кояш чыкканнан соң эшкә китәләр, баеганнан соң өйләренә кайталар.

...Кырык тугызынчы ел июненең соңгы көннәре. Сугыштан соңгы авылда бу иң авыр, әйтеп бетергесез читен көннәр иде. Бәрәңгенең дә җитәр-җитмәс запасы төгәлләнгән вакыт. Ипине инде аны, гадәттә, бәрәңге белән яңа елга хәтле генә ашыйлар иде. Күп вакыт ипи телемендә, күзгә керердәй булып, алабутаның чем-кара орлыклары җемелди иде. Яңа бәрәңгегә кадәр ике атналар бар иде әле. Ике атна дип әйтү якынча гына — яз ничек килә бит — иртәме, соңмы, җылымы, әллә салкынмы — барысы да шуңа бәйле. Бу елгы июньнең көннәре кояшлы, җылы булды. Бакчаларда бәрәңге чәчәген коя башлаган, сабакларының кайберләрендә бәрәңге алмасы тәлгәшләре дә күренгәли иде инде.

Ачлык кырды гына кешеләрне. Шулай да күбесен кычыткан, яшь алабута яфрагы ише үләннәр коткарды — аларның барысы да ул чакның төп ризыгы булды. Аякларында бераз хәле булганнар, ун-унике чакрымнар үтеп, Агыйдел болыннарына юа җыярга йөри башладылар. Бу сусыл үләннең анда чамасы юк иде. Ачлыктан интеккән колхозчылар, болынга килеп җиту белән, кыргый суганны талымсызланып авызларына алалар, алай да нәфескә артык юл куймыйлар — чамасын белмисең икән, шунда ук дөнья белән саубуллашуың бар. Юаны җыеп, капчыкларга тутырганнан соң, өйдә хәлсез ятучы картларны, карчыкларны, балаларны туендыру өчен авылларына юнәләләр. Юа кайту белән, өйдәгеләрнең йөзләрендә яктылык күренеп киткәндәй була. Алар, барысы бердәй булып, хәлсез кулларын үлемнән коткаручы үләнгә сузалар. Ачлык булуга да карамастан, пөхтә итеп җыештырылган өйләрдә бермәл үлән чәйнәгән тавыш кына ишетелеп тора. Ашап туйганнан соң, юадан аш әзерлиләр. Сыерлары булганнар сөттә пешерәләр. Анысы инде аның гаҗәеп тәмле була. Мондый ашны пешерү өчен күп вакыт аертылган сөт файдаланыла.

Озакка сузылган авыр кыштан соң табигатьнең хуш ис аңкытып яңаруына да карамастан, май, июнь айлары елның иң авыр чорлары иде.

...Елга аръягындагы тау артыннан июнь кояшы үзенең куе кызыл боҗрасын күрсәтә башлаган гына иде әле, Мөнирә, ян капканы ачып, гаиләсенең терәге — туендыручысы, аксыл сары төстәге сөекле мүкләк сыерын һәм ике сарыгын кыр капкасына таба атлаучы көтүгә кушып җибәрде. Үгез бозауны бакча артына, елга буена алып чыгып казыкка бәйләп куйды да өенә керде. Балалары мышный-мышный тәмле генә йоклап яталар. Аларны уятырга иртә әле. Үзләре уянсалар да барыбер ашатырга ризыгы юк. Өендә ник бер бәрәңге, бер бөртек ярма булсын.

Балаларын уятудан куркып, Мөнирә аяк очларына гына баса-баса болдырга чыкты. Ишегалдына күз төшереп алганнан соң, колхоз бәрәңгесе чүбен утарга дип, басуга китеп барды. Эссе кояш нурлары астында эшләгәндә, авыл ягына караштыргалады. Тамакның ач булуы үзен сиздерә иде. Аннан да бигрәк аның күңелен ниндидер бер билгесезлек, аңлашылмый торган шом борчый иде. Нидәндер җаны сызлана, йөрәге яна. Хәер, сызланырга сәбәп тә калмаган кебек иде инде. Буласы булган, күрәсе күрелгән. Соңгы ун айдагы тормыш сынауларыннан да катыраклары булырмы икән?

1937 елдагыдан соң кырык сигез-кырык тугызынчы елларда Сталин кушаматлы мыеклы бөек җитәкче үзенең ватандашлары җанын аулау буенча икенче этапны башлап җибәрде. Илдәге хезмәт белән төзәтү лагерьлары — Җир шарының алтыдан бер өлешендә киләчәктә коммунизм төзелеше өчен ватандашларын тәрбияләү заводлары бичаралар белән тулды. Тәрбиягә бирелмәүчеләрне, сырхауларны исемсез лагерьлар зиратларына күмделәр.

Мөнирәнең эче пошуын эш белән мәшгульлеге дә баса алмады. Төш вакытын көчкә-көчкә генә җиткерде. Кояш иң югары ноктасына җитеп килә иде. Чүп утау буенча ярты көн йөкләмәсен үтәп, Мөнирә өенә кайтып китте.

Өлкәне — унике яшьлек Мәгъсүме уянган, тын гына баскыч төбендә утыра. Сигез яшьлек Фәнүсе дә, урыныннан торып, сәкегә менеп кунаклаган. Мөнирәнең кайтуын сизептерме, дүрт яшьлек Марсилы, бер яшьлек Мостафидәсе дә уяндылар. Комганнан су агызып юындылар да өстәл янына барып утырдылар. Ашарга юк иде. Мөнирә, балаларыннан гафу үтенгән сыман, яшькә чыланган күзләре белән аларның әле берсенә, әле икенчесенә карап торды. Ләкин, оялыптырмы, аларга яшен күрсәтмәскә тырышты. Мәгъсүм сүзсез утырды. Фәнүс һәрвакыттагыча кыбырсый, ә Марсил кулы белән бертуктаусыз яңагын ышкый. Бары тик әлегә тормыш турында берни дә белмәүче Мостафидәсе генә шыңшыйшыңшый: «Корсак ачты»,— дип кабатлый иде.

Ашарларына бернәрсә дә юк иде шул. Мөнирә ачлыктан нурлары тоныкланган күзләрен өлкән улы Мәгъсүмгә төбәде. Янәсе, өлкән улкае, нәрсә эшләргә соң инде? Кинәт ул бераз аертылган сөт калганын исенә төшерде. Һәм тиз генә чыгып, кар базына төшеп китте. Алып кереп, бу минутларда алар өчен иң кадерле булган шул сыекчаны казанга салды. Коры тизәк кисәкләреннән учак кабызып җибәрде. Аертылган сөт бик тиз кайнап чыкты. Мөнирә аны ата-бабадан бирле сакланып килүче фарфор чынаякларга салды.

Балалар, иреннәрен чапылдата-чапылдата, аертылган сөтне эчеп бетергәндә, капка шакыдылар. «Менә ул эч пошуы»,— дип уйлап куйды йорт хуҗасы. Мөнирә капка янына барып җитәргә дә өлгермәде, аны үзе ачып, аяклары бөгелер-бөгелмәс җигүле биянең тезгененнән тотып, Бaһау карт килеп керде. Актаныш якларында бөтен исемне дә үзләренчә кыскартып әйтәләр. Менә бу камыт аяклы чирләшкәне дә кыска гына итеп «Бaһау карт» дип йөртәләр.

Бaһау карт күңел кайтаргыч, җирәнгеч бер бәндә иде. Гәрчә ул колхозда берninди рәсми пост биләмәсә дә, авыл масштабында җәза акцияләрен үтәүдә башлап йөрүче иде. Партия райкомы тарафыннан Мерәс авылына җибәрелгән яңа рәис Әминә Билалова Бaһау картка игеннәрне терлекләрдән таптатмауны, Чапаев исемендәге колхоз кырларындагы социалистик милек фондыннан ашлык урлауга юл куймауны йөкләде.

Аңардан бигрәк тә авыл малайларына көн юк иде. Гадәттә бит малай-шалайга бозауларны, бәрәннәрне, каз бәбкәләрен карауны йөклиләр. Уенга бирелеп, аз гына онытылып китәсең икән, тегеләре

шундук иң яхшы елларда да ун центнердан артык ашлык бирмәгән социализм басулары чиге саналган канау аша чыгып китәләр. Баһау картның күзләре үткен, дәүләт чикләрен бозучыларны ул бик тиз күреп ала һәм күп тә үтми, «диверсант» мал-туарлар социалистик милек сакчысының лапасына куып кертеләләр. Төнгә кадәр ул аларны чыгармый тота. Малларын алырга килгән малайларны теленә нинди әшәке сүз килсә, шулай тирги-тирги куып җибәрә. Алай гынамы әле? Бозауларны милициягә тапшыру белән куркыта. Малайлар Баһаудан да бигрәк эти-әниләреннән куркалар иде. Алар эштән кайткан җиргә маллар «кяфер» кулында булса (карт-корылар Баһауны шулай дип атыйлар иде), малайларга көн бетте диген инде. Чөнки авыл кешеләре Баһаудан куркудан түгел, аның каршына үтенеч белән барырга җирәнәләр иде. Алай да берәрсе нинди дә булса үтенеч белән барса, Баһау, мыскыллап, авызын ерып куя. Янәсе, бу мизгелдә биредә аңардан да зур нәчәлник юк.

Баһау карт, колхоз биясен тезгененнән җитәкләп, ишегалдына керде. Атын болдыр янында туктатты. Арба артыннан ук әле дә булса кияүгә чыкмаган колхоз рәисе Әминә Билалова пәйда булды. Аның холкы да әйбәттән түгел иде. Колхозчыларның бердәнбер хуҗасы, колхозның берничә артык сыерына һәм тере дисәң хәтерең калырдай үләргә торган өч биягә ия бу хатын үзен бик зурдан, тәкәббер тота иде. Кулында ниндидер язу.

— Әйдә, ач киртәңне! — диде боерулы тавыш белән авыл «прокуроры» Баһау карт.— Мунчаңны төйибез. Колхозның элеккеге рәисе, ягъни синең ирең тарафыннан совет колхозына китерелгән зыян исәбенә.

— Менә, Мөнирә,— дип, «прокурор» картның сүзен куәтләгәндәй, колхоз рәисе Әминә кулындагы кәгазенә күрсәтте.— Әле кичә генә миңа Актанышта бирделәр. Гаиләңнең ишле булуын исәпкә алганнардыр инде, шәфкатьлелек күрсәткәннәр. Сыерың урынына мунчаңны сүтеп алырга һәм үгез бозавыңны колхоз файдасына бирергә кушканнар.

Балаларның барысы да ишегалдына йөгереп чыктылар. Марсил белән Мостафидә болдыр янында басып торучы Мөнирәнең күлмәк итәгенә килеп ябыштылар. Тиктормас Фәнүс Баһау картның арбасыннан чыбыркысын алып яшерергә өлгерде. Мәгъсүм сүзнең ни турында баруын аңларга тырышты.

Суд, колхоз рәисенә Сталинның ун елын бирүдән тыш, Чапаев исемендәге колхозга китерелгән зыянны совет акчалары белән түләтергә дигән хөкем карары да чыгарган иде.

Судтан соң күп тә үтмәде, Мөнирәләргә погонлы, портупеялы кобурасына галәмәт зур «Макар» тыккан НКВД начальнигы, район халык суды вәкиле һәм Яңа Кормаш авыл советы рәисе килеп керде. Мөнирәнең йорт-җирен энә күзеннән үткәрделәр. Ләкин зыянны капларлык сыердан кала бернәрсә дә тапмадылар. Хуҗа хатын, балалары хакына сыерны калдыруны сорап, начальникларның алларына барып тезләнде. Ялынды, елады. Конфискацияләнергә дигән әйберләрен бер ай гына булса да алмый торуларын үтенде. Әз-әзләп булса да туганнарыннан акча җыярга, 1943 елны Камчаткага вербовать ителеп киткән туганнарына хат язып, акча сорап торырга вәгъдә итте. Мөнирәнең ул вакытта күкрәк баласы да бар иде. Ул хуҗаны утыртканнан соң ярты елдан туды. Туып ярты ел да тормады, ачлыктан үлде. Мөнирәнең туйганчы ашамаганлыктан үз сөте юк иде, ә сабыйның алабута белән бәрәңге боламыгын ашыйсы килмәгән, күрәсең.

Ул вакытта чиновниклар шәфкатьлелек күрсәттеләр — түләүне өч айга кичектереп тордылар. Ләкин бурычка алырдай беркем юк иде. Бары да ач-ялангач. Камчаткага туганнарына язу белән дә бик үк килеп чыкмый икән — хат бер якка гына да биш-алты ай йөри. Өстәвенә, аларның анда, дөнья читендә, ничек яшәвен белгән кеше юк бит әле.

Ул елларны күршедәге Яңа Кормаш җидееллык мәктәбендә этиләренең дусты, татарча бик яхшы белә торган мари кешесе Тимкин Михаил Тимофеевич директор булып эшли иде. Ул тумышы белән күршедәге Мари Суксу авылыннан. Тарих укыта. Тәнәфес вакытларында еш кына шул мәктәптә укучы Мәгъсүм янына килеп, тормыш хәлләре, этисе турында сораша. Яшь балалар хакына сыерны калдырырга, ә аның урынына мунчаны һәм бозауны алуларын сорап Татарстан Югары суды рәисе Акулов исеменә хат язарга нәкъ менә Тимкин киңәш иткән дә иде инде. Казанга шундый хатны Мәгъсүм язды. «Бозау ул зур булып үсәчәк бит»,— дип тәмамлады ул хатын. Аннары аны ял көне 25 чакрым ераклыктагы Актаныш үзәк почтасына илтте. Авылда, хатны ачып, серне белүләре бик ихтимал иде.

Суд карарын үтим дип, бердәнбер туендыручысы — мүкләгөн биреп җибәргән булса, гаиләнең ачтан үләсен көт тә тор.

Бер айдан соң Акуловтан җавап килде. Җавап дигәннән, җавап түгел инде ул, Актаныш район суды рәисе исеменә язылган хатның күчермәсе (янәсе, халыкны төрмәгә суд җибәрә). *«Гаиләнең ишле булуын, дүрт яшь бала барлыгын исәпкә алып, китерелгән зыянны 1949 елда туган бозау һәм җавап бирүче усадьбасындагы мунча белән капларга рөхсәт итәргә».*

Шушы эчтәлектәге хат килеп төшкәч, сабыйлар шатлыкларыннан сикерешә башладылар. Мөнирәнең бит алмалары буйлап яшь тамчылары тәгәрәп төште. Шатланырлык та бит: үзләрен туендырып торучы малкайлары алар белән кала. Бозауны алалар икән, алсыннар инде. Сыерлары тагын берне, бәлки икене дә китерер әле. Мунчаны сүтәләр икән, сүтә бирсеннәр. Өйдә, тагаракта юынырлар.

Уйда гына барысы да җиңел эшләнә. Кай арада күңелең белән әллә кайларда йөрисең, әлләниләр башкарасың. Кем әйтмешли, уй уй инде ул, ә тормышта, чынбарлыкта бөтенләй башкача килеп чыга. Менә Мөнирә белән өлкән улы Мәгъсүм дә, язын Казаннан Акуловтан хат алгач: «Бәлки, онытырлар әле»,— дип уйлаганнар иде. Кәгазьдә әйтелгәннәрне тормышка ашыру өчен әле дә булса район үзгеннән килмәүләре аларның бу уйларын тагын да ныгыта төшкән иде.

Онытмаганнар икән, хәерсезләр. Әнә бәдбәхет Баһау бәрәңге бакчасына чыга торган киртәләрне җимерергә дә тотынган инде. Бакча уртасында ялгызы басып торган мунча янына аты белән үтмәкче. Инде вакытлар үтү белән корымга баткан бу кара мунчаны Шәфыйк бабай салган булган. Ә Әминә район судыннан килгән кәгазен селки-селки бозау турында сорый:

— Кайда ул? Кая куйдың бозавыңны?

— Әнә бакча артында бит, бәйләп куйган.— Мөнирәнең беренче дулкынлануы узган иде инде. Баштагы каушавы үтеп, күңеле беркадәр тынычланып калды. Сыерны алып китмиләр бит әле, шатланырга кирәк. Исең киткән икән, мунча белән бозау!

Тамаклары ачлыгын бер мәлгә онытып, балалар да йөгерешеп йөри башладылар. Бары Мәгъсүм генә мунча ягына үтү өчен Баһау картка киртәләрне алырга булыша иде.

Дөресен генә әйткәндә, Мөнирәгә мунчаны биреп җибәрүе дә бик кызганыч. Гаиләнең бөтен тормышы шунда үтте ләбаса. Ул елларда барлык хатыннар да балаларын өйдә табалар иде. Бәбине кендек әби кабул итеп ала, аны шунда ук мунчага алып китә, йомшак кына парлый, юа. Хуш ис аңкытып торган йомшак себерке белән берничә тапкыр сабыйның күтенә дә чәпәп ала. Гадәт шундый иде. Ә җомга көннәрендә бөтен җиренә төтен сеңгән, бүрәнәләре чем-кара корым белән капланган мунчада юынулар чын-чынлап бәйрәм төсе ала иде. Ә кичләрен, үләннәр кыстырып бәйләнгән каен себеркесе белән парланганнан соң, гаилә җырлап торучы самовар янында озаклап мәтрүшкәле чәй эчә.

...Баһау карт атын ияртеп карачкыл төзелеш ягына таба китте һәм шунда ук эшкә дә тотынды. Әзерләп куелган балтасы белән мунча түбәсенә сукты. Черек такта, вак-вак кисәкчекләргә таркалып, коелып төште. Түбәне эчке яктан сыланган сумала гына тоткан икән. Түбә минут эчендә «сүтелеп» бетте. Тик колхоз арбасына төяр нәрсә генә булмады. Баһау карт мунча алдын сүтәргә кереште. Монда эшкә яраклылары чыккалады. Йөк өстенә салу нияте белән, ул аларны төяргә ашыкмады.

Мөнирә тимер көрәк алып килде, түшәм өстенә менеп, туфракны бер урынга ыргыта башлады.

Баһау карт бик җитез кыяфәт белән төп эшкә — бүрәнәләрне тәгәрәтеп төшерергә тотынды. Бура почмагында черемәгән ник бер бүрәнә булсын. Алары да шул ничәмә еллар сумалага гына ябышып торганнар икән.

— Эшкә ярар җире юк моның,— диде Баһау карт бераз читтәнрәк күзәтеп торучы Әминәгә.

— Әйдә инде, кансага ягарга ярар әле,— диде Әминә эшлекле кыяфәт белән.— Кышкы көн бөтенесен ашап бетерер.

Баһау карт, бүрәнәне бүрәнәгә салып, мунчаны колхоз арбасына бик җыйнак кына төяп бетерде. Мунча корымыннан үзе дә кап-кара шүрәлегә әйләнде, бары тик мөгезләре генә юк иде. Чын-чынлап негр инде менә. Төтендә ысланган камыт аяклы негр.

Баһау карт мунча бүрәнәләрен колхоз конторына алып китте.

— Канса кырына гына бушат! — дип әмер биреп калды ярдәмчесенә колхоз рәисе. Бераз басып карап торганнан соң, үзе дә, урам аркылы чыгып, шул якка таба китеп барды.

Озак та үтмәде, Баһау яңадан борылып килде. Авыл халкы телендә «канса» дип йөртелгән колхоз конторы Мөнирәләр каршында ук диярлек иде. Ул, утызынчы елларда раскулачить ителеп, Магнитогорск металлургия заводы төзелешенә сөрелгән мулла Гирфан бабай Дәүләтбаев йортында урнашкан иде.

Баһау карт белән колхоз рәисе юк арада Фәнүс белән Марсил, мунча почмакларындагы карачкыл бүрәнә кисәкләрен алып, бәрәңге сабагы арасына яшерделәр. Кечкенә булуларына карамастан, алар инде ягулыкның ни икәнен яхшы беләләр иде. Алар көн саен диярлек сыерлар төшереп калдырган «коймак»ларның җәйге кояшта кипкәннәрен иске чиләккә җыеп йөриләр...

Бәрәңге буразналары арасыннан үтеп, Баһау янәдән атын мунча янына китереп туктатты. Берничә минуттан мунчаның калган өлеше белән дә эш төгәлләнде. Аның урынына кечкенә генә туганнар каберлеген хәтерләтеп, су кайнату өчен урнаштырылган казаны белән мич кенә утырып калды.

— Ничек казанны алып китмәде бу Баһау? — диде Мөнирә гаҗәпләнеп һәм янәшәсендә басып торучы балаларына карады.

Баһау карт артыннан капканы япканда, күрше Югары Карачның Муллагали хатыны Закирә апа үтеп бара иде.

— Нәмә булды? — Ул гаҗәпләнеп Мөнирәгә карады.

— Менә, хөкүмәткә бурыч түләдем,— диде Мөнирә. Һәм булган хәлне сөйләп бирде.

— Син каян кайтып барасың соң? — дип сорады үз чиратында Мөнирә.

— Менә, Дөрбешкә пристаненнан кайтып киләм әле,— диде Закирә.— Өшәр авылында яшәүче Сәкинә апаны пароход белән Казанга исәрләр йортына озаттык.

Менә шушында инде Закирә йөрәк яргыч хәлне сөйләде. Сәкинә апа, ирен фронтка озатканнан соң, биш яшьлек улы белән кала. Күп кенә авылдашлары кебек аның ире дә Бөек Ватан сугышында «хәбәрсез югала». Улы белән бик озак көтәләр сөекле этиләрен. Ләкин ул сугыш кырыннан әйләнеп кайтмый. Сугыштан соң ачтан үлмәс һәм салымнарны каплау өчен, булган әйберләрен әкренләп сата башлыйлар. Башта, бер баш кәҗәне генә калдырып, үзләрен туендырып торучы сыерны саталар. Бара-тора кәҗәгә дә чират җитә, ә аннан соң инде тавык ишеләр... Ә салымны һаман таләп итеп торалар. Маен бир, йомыркасын, йонын, бәрәңгесен... Шуның өстенә акчалата да әле. Боларның барысын да каян аласың. Өйдә, лапаста тычкан авызына салырлык бер бөртек ашлык юк. Хезмәт көннәренә колхоз берни дә бирмәде. Финагентлар, партия райкомы, НКВД вәкилләре авылда кунып яттылар. Кичләрен кешеләрне кансага чакыралар, өй саен йөреп, көч җитмәслек салым түләүне таләп итәләр, көчләп Сталин заемына кул куйдыралар. Алар таләп иткәннәрне үти алмаганнарның кайберләрен авыл зинданына — канса конторының караңгы чоланына ябалар.

Актаныштан килгән Сталин опричниклары да ирен сугышта югалткан Сәкинә апаны шулай җәзалыйлар. Шулай итеп, алар аерым бер татар авылында да коммунизмның бик уңышлы «төзелүе» турында Казанга, аннан Мәскәүгә хәбәр итеп торалар.

Колхозда йончып эшләп кайтканнан соң, опричникларның кичке җәзалауларына чыдый алмыйча, көннәрнең берендә, хәтта бердәнбер улына да әйтеп тормыйча, Сәкинә апа бәрәңге сабаклары арасына яшеренә. Колхоз бригадиры аны өч көн буена эзли. Районның агент-опричниклары төн уртасына кадәр өе янында каравылда торалар. Сәкинә апаны таба алмыйлар.

Дүртенче көнне ул, бәрәңге сабаклары арасыннан чыгып, сәләмә киемнәрдән конторга юнәлә һәм биредә район, авыл властьлары вәкилләренә ташлана, аларны бумакчы була, киемнәренә, чәчләренә ябыша. Аерым бер татар авылында коммунизм төзүче тыйнак, тыңлаучан, фронтта ирен югалткан хатын акылдан яза.

Район опричниклары Актаныштан тиз арада табиблар чакыралар. Сәкинә апаны алар карамагына тапшырып, Казанга психоневрологик диспансерга, икенче төрле әйтсәк, юләрләр йортына озаталар.

Закирә дә Югары Карачтан Өшәр авылына очраклы гына килеп чыкмаган. Сәкинә апаның улы, әнисе туган авылына киткәндер дип уйлап, туганнары янына Югары Карачка килә.

Билгеле булганча, кичке авылның үзенең яшәү рәвеше. Ишегалларында сыерлар мөгри, сарыклар, кәҗәләр бәэлди. Сөйләшүләргә чиләк шалтыравы, капка япкан тавышлар килеп кушыла.

Фәнүс колхозныкы дигән үгез бозауны ишегалдына алып керде. Колхоз рәисе Әминә көзгә кадәр бозауны үзләрендә тотарга, тәрбияләргә кушты. Кушты гына түгел, боерык бирде. Үстереп, соңыннан аны колхозга тапшырырга тиеш булдылар.

Көтүдән кайткач, сыер, иләмсез зур борын тишекләрен тагын да зурайтып, ютәлли башлады. Мунчаны сүтеп алганнан соң калган корым, сумала исе аның борын тишекләрен кытыклый иде булса кирәк.

Ун литрлы чиләкне тутырып сөт савып алганнан соң, Мөнирә яртышар литрлы банкаларга салып балаларына бирде. Аннары яшь кычыткан яфрагы салып, бер казан сөтле аш пешерде. Беркадәр вакытка ачлык үзен оныттырып торды.

Бакча уртасында зур чуен казаны белән бергә, кап-кара булып, мич күренеп тора иде. Мөнирә күршесе коесыннан казанга су ташыды. Мунчаны сүткәндә коелып калган йомычкаларны, утын кисәкләрен җыеп, мичне кабызып җибәрде. Мунча нигезен куе төтен чолгап алды. Ялкын телләре күренә башлады. Су бик тиз җылынды. Ачык һавадагы мунча әзер иде. Мәгъсүм, Фәнүс һәм Марсил бергәләшеп юындылар. Алардан соң Мөнирә Мостафидәсе белән юынды.

Мунча сихәтеннән соң алар байтак вакыт баскыч төбендә утырдылар. Күк йөзендә бихисап йолдызлар җемелди иде. Көнозын эшләп арыган авыл халкы төнге караңгыда йокыга талды. Бары тик йолдызлар гына каядыр еракларга дәшәләр иде сыман.

— Киттек, балаларым, йокларга,— диде Мөнирә пышылдап кына.

Алар төнлә генә булса да тынычланып алырга дип өйгә керделәр. Иртәгә бу тормышта кешеләрне тагын ни көтәдер — анысы билгесез иде.

* * *

Мөнирәләр йортында мунча белән булган хәлләрдән соң өч айдан артыграк вакыт узды. Октябрьнең беренче салкын көннәре килеп җитте. Мөнирәләр йорты каршындагы алты почмаклы өйнең олы ягында Чапаев исемендәге колхозның кансасы иде. Кече якта кызы Кайдафә һәм улы Зөфәр белән Хәмдидә апа яши. Хәмдидә апаның ире Самат абый сугыш алдыннан фаҗигале төстә үлде. Әтиләре булмаган күп кенә гаиләләр шикелле алар да сугыш һәм сугыштан соңгы елларның бөтен ачысын татыдылар. Әле хәзер дә, ярты гасырдан артык вакыт үтүгә карамастан, Зөфәрне искә төшерү белән, күзгә яшь килә. Әле дә хәтеремдә: июньме, әллә июль иде инде — Яңа Кормаштан үзебезнең Түбән Карачка кайтып

киләбез. Безнең авыл янында гына арыш өлгереп килә, ләкин сөтчел орлыклары юк иде әле. Зөфәр арышның бер башагын өзеп алды да бөртекләр барлыкка килә торган өлешен суыра башлады.

— Юк! — диде Зөфәр үпкәләгән сыман.— Бөтенләй буш әле, иртәрәк шул.— Берничә адым атлаганнан соң, ул тирән сулап әйтеп куйды: — Э-эх, арышлар серкә җибәрсәләр, оҗмахка чыгар идек инде...

Дустымның бер башак турында әйткән сүзләре гомерем буе минем күңелемнән чыкмады. Йөрәктән чыккан андый сүзләрне онытырга мөмкинмени? Эх, кешеләр, кешеләр! Бәхетле, гармонияле яшәү өчен безгә нәрсә җитми соң?!

Октябрь төннәренең берсендә Хәмдидә апа яисә аның кайсы да булса баласы ашарга әзерләү өчен мич ягарга уйлый. Ничек килеп чыккандыр, миңа билгеле түгел, мичтән утлы күмер атылып идәндәге салам өстенә төшә. Моны берсе дә күрми кала. Берничә секунд эчендә алты почмаклы йорт ялкынга чолгана.

Утны беренче булып Мәгъсүм күрә. Күршеләрне, бөтен авылны уята. Мөнирә йорты янында да эссегә чыдар хәл юк иде. Ул, тиз генә өйалдына кереп, чормага менеп-төшеп йөри торган баскычны алып чыкты. Аны өй түбәсе кырыена куйды да Мәгъсүмгә кычкырды:

— Мен тизрәк өй түбәсенә.

Мәгъсүм атылып өй түбәсенә менеп китте. Мөнирә аңа бер чиләк су бирде:

— Әкренләп бөтен түбәгә агыз!

— Ә үзе чиләкләрен шалтырата-шалтырата күрше коесына йөгерде.

«Үч алу» кансасы, шуның белән бергә кешеләр яши торган ягы да, унбиш минут эчендә янып бетте. Контор янында Баһау карт өеп куйган Мөнирә мунчасы да янды.

Мөнирә белән Мәгъсүм өйләрен зур янгыннан саклап кала алдылар.

Менә шулай 1930 елда коммунизм төзелеше файдасына конфискацияләнгән авыл мулласының алты почмаклы йорты һәм гади колхозчы Мөнирәнең корымга баткан мунчасы 1949 елда бер мизгелдә янып беттеләр.

Дөрес, манарасы киселгән элеккеге мәчет бинасы бар иде әле. Анда башлангыч мәктәп иде. Шушы документаль юлларның авторы да заманында шунда укыган.

Тиздән ул мәчетне дә сүттеләр һәм аның бүрәнәләре Крупская исемендәге үзәк усадьбаның хуҗалык йортларында ятып череп беттеләр.

### *Комсомол билеты*

Январь суыгы зәһәрләнә. Бу суыктан курыккан шикелле, кояш та тиз генә офыкка төшеп батты. Мәгъсүмнең куллары, туңып, үзенә буйсынмый башлады. Суык иске кайры тун аша аның тәненә үрелә, ыштыр ураган аякларын чеметә. Япа-ялан кырда туңып үлүдән куркып, Мәгъсүм тиз генә олау өстеннән бастырык буйлап шуып төште. Сикергәләп, чана артыннан йөгерде. Тәне бераз язылып, җылынып китте. Үзенең чабата эзләренә карап көлемсерәде: гел исерек мотоциклчы йөргән кебек инде.

Шушы зәмһәрир суыкта Мәгъсүмне Кама белән Агыйдел кушылган урындагы болынлыктан колхоз печәнен алырга җибәрделәр. Атлар җитмәгәч, үгез җигәргә туры килде. Бу сукмаклар, болынлыклар балачактан тыныч анысы: Крупская исемендәге колхоз белән берләшкәнче үк, печәнне гел шуннан чабалар иде.

Уйларыннан арынып, Мәгъсүм өмет тулы күзләрен юлга текәде, әмма офыкка кадәр сузылган юлда җан әсәре күренми. Хәер, бу суыкта кем йөрсен инде! Печәнгә бергә барган иптәшләре аны Дербешкада ук узып киттеләр. Атта булгач, аларга рәхәт. Кайберләре Мәгъсүмнең аркан-сбруйлы ябык үгезен мыскыллап көлделәр.

Иң соңгы олауда барган әрем телле Гавис барысын да уздырды:

— Әйдә, әйдә! Син дә бер кайтып җитәрсең. Бу сиңа этәң белән рәхәтләнеп тарантаста йөрү түгел! — дип төрттерде ул эче көлеп.

Әле олау өстендә, әле сикергәләп чана артыннан йөгерә торгач, Мәгъсүм дә Озын күпергә килеп җитте. Аннан соң юл икегә аерыла. Сулда — Агыйдел култыгында урнашкан Өшәр авылына китүче юл сузылган. Бу авылны Иске Семиостров дип тә атыйлар иде. Кар яхшы өйгән быел, Өшәр юлы күренеркүренмәс кенә калган. Ә менә уңга киткән юл Бүләк аша Мәгъсүмнең туган авылы Карачка илтә. Аннан Крупская колхоз үзәге Кормашка да бер генә атлам кала. Озын күпер Дербешка пристане белән Карачның уртасына урнашкан дияргә була. Димәк, авыр юлның күбрәге үтелгән.

Кызык инде, Озын күпер дисәләр дә, бернинди дә күпер түгел үзе: сазлык өстеннән ике чакрымга сузылган дамба ул. Халык аны Җен күпере дип йөртә. Җәй, көз көннәрендә яңгыр сибәләп кенә китсә дә, күпер, сазлык чолганышында калып, бермә-бер озыная. Җен күпере бу якның хатын-кызларын бик нык тилмертте. Ул чорда Дербешка базары бик данлыклы иде: май, сөт, йомырка кебек ризыкларны сатып, арыш ипие алырга халык гел шунда йөрде. Төсе уңып беткән иске киндер күлмәк, чабата кигән,

«уф алла» арбасы тарткан апа-җиңгиләрне Озын күпер күп күрде. Мәгъсүмнең дә әнисе белән шушы күпердә черки куа-куа төн чыккан чаклары булды. Бу каһәр суккан күпернең тагын бер исеме бар. Аны Әҗби күпере диләр. Бусы инде якында гына урнашкан Рус Әҗбие дигән авыл исеменә бәйле. Ләкин шулай да күпчелек халык бу урынны Озын күпер дип йөртә. Кыш көне, якын-тирәдәге барлык күлләр, сулыклар төбенә кадәр туңып беткәч тә, бу дамба аша узу бик куркыныч. Кыр җилләре дамба буена кар китереп өя дә, кайда юл, кайда сазлык икәнен гел чамалап булмый. Әгәр олау әз генә читкә тайпылса, үгез яки ат мизгел эчендә төпсез кар чоңгылына төшеп бата.

Кичке эңгер-меңгер төште. Суык сындырырга уйламый да. Мәгъсүмнең керфекләре бозланып катты. Үгез дә үшән генә атлый. Арыды мескен хайван. Эчәсе, ашыйсы килә торгандыр.

Мәгъсүм үзе дә курка башлады. Якын-тирәдә җан әсәре юк. Бүләк авылына да өч чакрым бар әле.

Кинәт үгез туктап калды, авыр ухылдап, уң ягы белән тәртәгә егылды. Ул соң чиккә җитеп хәлдән тайган иде. Шулай итеп, мескен үгез үз гомерендә беренче тапкыр В.И.Ленинның хәләл җефете — Крупская исемендәге колхозда коммунизм төзүдән баш тартты.

Мәгъсүм, бер кочак печән алып, үгезнең борынына төртте. Әмма тегесенең моңа исе дә китмәде, ул башын борды һәм, тынлыкны ярып, авыр итеп ухылдады.

Мәгъсүм, олауга менеп, чыбыркы белән бар көченә үгезгә сукты. Үгез, бер ун адым йөгергәч, хәле бетеп, тагын ауды. Мәгъсүм тагын чыбыркы шартлатты, әмма бу юлы үгез селкенеп тә карамады. Үзенең Крупская исемендәге колхозда төп эш көче икәнлеген оныткан шикелле, тик ята бирде. Мәгъсүм, иркәләп, үгезнең муенын кашыды, әмма коммунизмның тарту көче назлауга да битараф калды. Аптыраган Мәгъсүм печән өстенә менеп утырды. Аның баш миен «Нәрсә эшләргә?» дигән фәлсәфи сорау боргычлады. Колхоз милкен ташларга ярамый. Моның өчен төрмәгә утырталар. Бер уч ашлык өчен дә утыручылар күп. Үгез ял итеп алганчы, олау өстендә утырсаң, катып үләсең. Суык кырык тирәсендә булыр. Җитмәсә, ачлык үзәккә үтә. Киндер капчыкта тәгам ризык та юк. Арыш оны белән алабута кушып пешерелгән ипикәйнең соңгы телемен Мәгъсүм иртән Дербешкадан чыкканда ук ашап бетергән иде. Кинәт аның исенә төште: юлда ни булмас дип, инәкәе аның кесәсенә бер кап шырпы тыкты бит! Мәгъсүмнең тәмәкене авызына алып караганы да, бу турыда уйлаганы да юк.

Аһ, бу суык! Кул һәм аяк бармаклары тәмам туңды. Ни дә булса эшләргә кирәк, юкса бу япа-ялан җирдә туңып үлүең дә бар! Мәгъсүм кесәсеннән шырпы тартмасын алды һәм печәнгә ут төртте. Салкын печәнгә сүрән генә ялкын үрләде. Бик күп булса ун секунд үткәндер, Мәгъсүмнең куллары, бите җылынып китте. Ялкын бөтен олауга күчмәсен өчен гәүдәсе белән каплап, аны сүндерде. Ә үгез селкенеп тә карамый ята бирә.

Суык калтырата башлагач, Мәгъсүм янә ут үрләтеп алды. Ләкин өченче тапкырында ул ялкынны вакытында сүндерергә өлгермичә калды. Ут, күз ачып йомганчы, бөтен олауны ялмап алды. Мәгъсүм тунын салып, ялкынны «тукмый» башлады. Шул мизгелдә коты алынган үгез сикереп торды, колхоз ягына ыргылды. Мәгъсүм олаудан егылып төште һәм башы белән карга чумды. Көрт «әсирлегеннән» котылып, тунын кигән арада, ялкын ураган олау, төн каралыгына кереп, күздән югалды. Мәгъсүм үкси-үкси бар көченә үгез артыннан чапты. Уттан өреккән малкайны куып тоту ансат эш түгел. Кинәт, (ни могҗиза!) олау туктап калды. Мәгъсүм хәлдән таеп килеп җиткәндә, мәрхәмәтсез ут колхоз чанасын «җиңеп» килә иде. Үгез дә юк, тәртә дә юк. Янып көлгә әйләнгән колхоз милкен күргәч, Мәгъсүм: «Ничә ел бирерләр икән? — дип уйлап куйды.— Әтисе янына бер лагерьга җибәрсәләр иде, ичмасам, бергә утыруы җиңелрәк булыр иде».

Күмерләнеп барган чананы әйләнеп чыккач, Мәгъсүм «үгезен каян табарга инде?» дип алга атлады. Ике йөз метрлап киткәч, юлда яткан үгез күренде. Аннан янган киез итек исе килә иде. «Уф,— дип җиңел сулады Мәгъсүм. Һәм, картлар кебек, үзалдына сөйләнеп куйды,— хет үгезе исән калган. Болай булгач, төрмәгә озакка утыртмаслар». Бу уйлардан бераз моңсу булып китте: аз срок белән этисе янына — Колымага җибәрмиләр.

Мәгъсүм үгезне муеныннан кочып алды, матур сүзләр белән иркәләде. Әкрен генә дилбегә өзеген тартты. Үгез хуҗасына буйсынды. Торып басты һәм күмерләнгән тәртәне сөйрәп, Мәгъсүмгә иярде. Тиздән Бүләк авылы этләренең һау-һаулап өргәне ишетелде, берән-сәрән генә утлар да күренде. Күк йөзе бераз яктырып китте, тонык кына йолдызлар да күз кысты. Соңгы вакыйгалардан аптырашка калган үгез бер карышмый атлады да атлады. Кинәт үгез еш-еш сулыш ала башлады. Мәгъсүм, куркып, як-якка каранды. Йа Ходай, ерак та түгел, сындай катып, өч бүре утыра. Мәгъсүмнең коты очты, аяклары мамык сыман җебеп төште.

«Болай булгач, чынлап утыртачаклар. Бүреләр үгезне ашаса, төрмәдән котылу юк инде»,— дигән уй яшен тизлегендә баш миен чарлады. Бүреләр үгезгә тикле үземне ашарлар дигән фикер унбиш яшьлек малайның уена да килмәде.

Мәгъсүм бар куркуын җиңеп, бүреләргә каршы атлады. Әллә тамаклары тук иде, әллә йон исен яратмадылар — бүреләр селкенеп тә карамады. Мәгъсүм үгезен җитәкләп авылга таба китте. Бераздан төннең кара пәрдәсе бүреләрне дә «йотты».

Инде кайтып җитәрәк, авыл ягына төшкәндә тагын бер шәүлә күзгә чалынды — әллә бүре, әллә башка җәнлек, аңларлык түгел. «Беттек, бүреләр чолгап ала хәзер»,— дип, Мәгъсүм үгезнең тезгененнән тартты. Кара шәүлә якынайганнан-якыная. Шулчак төнге куркыныч тынлыкны ярып, инәкәенең тавышы ишетелде:

— Мәгъсүм! Улым! Кайда син?

Мәгъсүмнең йөрәге чеметеп алды, тамагына төер утырды. Аның әнкәсе, энеләрен, сеңелләрен йоклатып, колхозчы улын эзләргә дип чыккан. Караңгы төн, зәмһәрир суык дип тормаган. Якынрак килгәч, әнисе Мәгъсүмне кочып алды.

— Исәнме син, улыкаем? Исәнме? Исәнме?

Мәгъсүм түкми-чәчми барысын да сөйләп бирде.

Инәкәе:

— Әле ярый үзең исән калгансың, балам. Үгезне дә саклагансың. Молодец, улым…— дип, малаеның күңелен күтәрергә тырышты.

Алар авылга кергәндә, вакыт бик соң иде инде. Авыл халкы татлы йокыда. Вәлихан бабайның эте ялкау гына өреп алды. Үгезне утарга бикләп, алдына печән китереп салдылар. Бераздан инәкәй җылы су эчерде.

Көн яктырмас борын бригадир Муллагали килеп керде. Бусагадан ук: «Печән кая?» — дип акырды. Мәгъсүм сәкедән төшкәнче, әнисе Муллагалигә төнге вакыйгалар, Озын күпердә чыккан янгын турында сөйләп бирде.

Бригадир, каты гына җикеренеп:

— Әтисе янына китәр. Урыны төрмәдә моның. Хәзер үк председательгә йөгерәм! —диде.

Мәгъсүм тиз генә үгезне колхозның мал абзарына илтте дә үзе колхоз үзәге булган Яңа Кормаш юлына таба атлады.

Яңа Кормаш Түбән Карачтан әллә ни ерак түгел — нибары ике чакрым ярым.

Колхоз рәисенә бригадир Муллагали барын да җиткергән. Рәис хисапчы Мияссәр белән май кебек җылы бүлмәдә кызып-кызып бәхәсләшә иде.

— Ну, ничек анда, әниең сохари киптердеме? Әтиең янына Колымага китәргә туры килер сиңа.

Шул минутта хисапчы Мияссәр шалт-шолт чут төймәсен тартты:

— Тәк, печән олавы. Беренче сортлы болын печәне фәлән сум,— шалт төймә сулга,— тә-әк, чана бәясен өстибез,— тагын шалт-шолт,— әле үгез исән калса ярый. Бастырык онытылган. Ул да акча малы.

Гүя Мияссәр чут төймәсен тартмый, ә чаж-чож итеп Мәгъсүмне яңаклый. Рәис, күзләреннән очкын чәчрәтеп:

— Син бит ут төртүче. Социалистик милекне ут төртеп яндыручы. Аңлыйсыңмы син шуны? — дип акырды.

Шулвакыт бүлмә ишеге киң итеп ачылды. Киез итеген кага-кага яшь чибәр егет килеп керде. Комсомолның Актаныш райкомында бүлек мөдире булып эшләүче Марат Галиев иде ул. Керә-керешкә сөрән салды:

— Менә хәзер Мәгъсүмгә дә комсомол билеты бирәбез. Кичәге тантанада үзе була алмады.

Рәис кырт кисте:

— Нинди комсомол билеты ди аңа. Ул бит социалистик милекне яндыручы. Аңа тизрәк сохари киптерергә кирәк. Әтисе янына төрмәгә китәчәк.

Бу кадәр мәсхәрәләнүгә иртәдән бирле түзгән Мәгъсүмнең сабырлыгы шартлап сынды. Ул урамга атылды һәм Яңа Кормашның үзәк урамыннан Түбән Карачка таба чапты.

Әтиең янына төрмәгә китәсең дигәннәре дә ул кадәр җанга тимәгән иде. Иң үкенечесе шул: кичә бар яшьтәшләренә тантаналы төстә комсомол билеты тапшырганнар, ә Мәгъсүмне бүген төрмә белән куркыталар. Яз көне генә ничек рәхәт иде. Җиде классны тәмамлагач, район үзәге Актанышка 25 чакрым җәяү барганнар иде. Аларны комсомолга кабул иттеләр. Ләкин ул чакта комсомол билетлары булмагач, соңрак бирербез дип вәгъдә иттеләр. Кем уйлаган аны менә шулай аяныч хәлдә калырмын дип?

Авылны чыкканда, Мәгъсүм кар шыгырдавыннан, артыннан кемнеңдер тиз-тиз килгәнен чамалады. Ул борылып карады һәм тукталды. Аның каршында Актанышның комсомол райкомы бүлек мөдире Марат Галиев иде. Ул сул кулы белән Мәгъсүмнең җиңеннән тартты. Ә уң кулы белән комсомол билеты һәм значок сузды.

— Мә, егет, ал. Тыңлама син аларны. Миңа да райком каршында отчет бирәсе бар...

Бүлек мөдире яшь комсомолның кулын кысты һәм, борылып, килгән юлыннан кире китте. Мәгъсүм көтелмәгән бу шатлыктан ни сөенергә, ни еларга белмичә Түбән Карачка таба атлады.

# Алимент

Габдрахман бабай үлем түшәгендә бик озак азапланып ятты. Заманында типсә тимер өзәрдәй таза, киң җилкәле, озын буйлы, каһарман бу ир-атны хәзергә кешелек дөньясы өчен ят, дошман булган яман шеш — рак авыруы тәмам ашады, эштән чыгарды. Үләсе көннәрендә Габдрахман бабай еш кына аңын югалткалады. Шуңа күрәдерме, хәл белергә килгән туганнары, авылдашларына ул үлгән сымак күренә иде. Тик аның белән ярты гасыр чамасы бергә яшәп, бу дөньяның ачысын-төчесен бергә татыган карчыгы Бибинур апа гына ап-ак бәз күлмәк астында сизелер-сизелмәс кенә леп-леп иткән йөрәк тибешен тоеп торды. Ул картының үлә алмыйча интегеп ятуының серен дә яхшы белә иде.

Һушына килгән минутларда Габдрахман бабай, озын керфекләрен салмак кына күтәреп, сагынудан саргайган күзләре белән бүлмәне йөртеп чыккач, ничәнче кат инде:

— Кайтмадыласрмы? — дип сорап куя.

Әледән-әле бирелгән шомлы бу сораудан Бибинур апа тетрәнеп куя һәм җавабын ничек тә булса йомшартыр өчен кирәкле сүзләр эзли:

— Юк шул әле. Кайтырлар әле, кайтырлар, Алла бирсә!

Бу сүзләр Габдрахман бабайның җанын өшетеп җибәрә, алар аның йөрәгенә тавышсыз, хыянәтчел ук булып кадалалар сыман.

Ул тагын һуштан яза...

Юк, Габдрахман бабай ничек булдыра алса, шулай Газраилне алдап, үлемне уратып үтә, гөнаһлы бу фани дөньядан һич тә китәргә ашыкмый иде әле.

Бабай, күп еллар элек Агыйдел буена урнашкан туган авылларын ташлап, Көнбатыш Урал башкаласы дип йөртелгән Пермь шәһәренә киткән ике улы — Зиннур һәм Габделнурны көтә. Алары да инде, мескен башлар, туган якларыннан күңел көрлеге типкәннән генә кузгалып китмәделәр, ә чыдар әмәлләре калмагач, дуамал колхоз бригадиры һәм үзләренә азрак туган тиешле астыртын, әмма хәйләкәр колхоз рәисенең кысрыклауларына түзә алмыйча еракларга китеп олактылар.

Билгеле, баштарак Габдрахман бабайның уллары ел саен Сабантуйларына кайтып йөрделәр, авылдагы ата-аналарын сөендереп, шәһәр күчтәнәчләре җибәрделәр. Кайткан чакларында калай түбәләр ябабыз, калайдан җилләткеч торбалар ясыйбыз һәм зур акчалар эшлибез, дип мактана иделәр. Шулайдыр, аталары өйрәткән һөнәр егетләргә зур шәһәрдә югалып калмаска ярдәм иткәндер. Габдрахман бабай үзе дә заманында Актаныш ягының атаклы калай мич чыгаручысы иде.

Еллар үтә торды. Алар үткән саен, егетләр дә авылга сирәгрәк кайта, әти-әниләрен оныта башладылар. Күчтәнәч салынган посылка һәм акча квитанцияләре дә килүдән тукталды. Хөкүмәт тарафыннан билгеләнгән колхоз пенсиясенең күләме бик аз: барлыгы унике сум, ә терлек-туар тотарга аларның көче юк. Картлар турында кайгыртуны ире һәм ике баласы белән Чаллыда яшәүче эш сөючән, әмма үткен телле кызлары Вәсилә алды. Ай саен ул алар янына кайтып торды һәм азык-төлек белән тәэмин итте. Актанышка таба барган машиналарның шоферлары белән сөйләшеп, капчыклап он, шикәр йә ит консервлары төяп җибәрде. Шулай итеп, биш ел вакыт тоелмыйча да үтеп китте. Берзаман Пермьнән Чаллыга күчеп килгән гаиләләрдән Вәсилә абыйлары турында кыска гына мәгълүмат алды. Хәбәр күңелсез: туганнары хатыннары белән аерылышып, эчкечелеккә бирелгәннәр. Куллары алтын булгандыр инде, әлеге эшләрендә эшләп йөриләр, ди. Әти-әниләренә, ичмасам, хәлләрен сорашып ике-өч юл хат та язмыйлар.

Улларының болай сансыз кыланышларына Габдрахман бабай белән Бибинур әби артык рәнҗемәделәр. Ачлык елларында, аннан соңгы авыр заманнарда да югалып калмыйча тәртипле, эш сөючән итеп үстергән малайларының шундый җавапсызлыкларына гына борчылдылар алар.

Ничек кенә булмасын, балалык хисе көчле иде аларда. Улларын еш телгә алдылар: бала чактагыча башларыннан сыйпап иркәлисе, сөясе килә иде аларның. Мондый гаделсезлек, оятсызлыкка кызлары Вәсиләнең генә ачуы нык кабарды. Ата-анасын карау бөтенләе белән аның җилкәсенә төшкәнгә күрә түгел, юк, бу яктан караганда ул киң күңелле кеше. Соңгы кискән икмәге белән уртаклаша ул алар белән.

Ләкин түзеп торуның да бер чиге буладыр. Бер килүендә, өчәүләп, бала чактан ук таныш булган самовар җырын тыңлап сөйләшеп утырганда, Вәсилә түзмәде, йөрәк ачысы белән кискен итеп әйтеп куйды:

— Әткәй, әнкәй, җитте, башка түзә алмыйм, иртәгә үк сезнең исемнән оятсыз улларыгыздан алимент түләтергә гариза язам...

Картлар баштарак кызларының бу сүзләренә әллә ни әһәмият бирмәделәр, гадәттәгечә кызып китү дип кенә кабул иттеләр. Вәсиләнең берничә чакрым ераклыктагы авыл советына барып яздырып кайткан гаризага кул куярга кирәклеген белгәч кенә, ата-ана уйга калды. Бу — ике ут арасында калу белән бер. И Аллам, бу кискен борылышка авылдашлары, туганнары ни әйтер, ни йөз белән аларның йөзенә карамак кирәк, ә? Хөкем каршына басучылар аларның үз уллары була түгелме соң? Мондый адымны ничек атлыйсы? Озакка сузылган тынлыкны Бибинур әби бозды. Ул башындагы яулыгының бер очына яшьләрен сөртә-сөртә болай диде:

— Безгә бу җирдә күпме яшәргә калгандыр, белмим, ләкин без олы кешеләргә әллә ни күп әйбер кирәкми. Ничек тә булса очларбыз гомер дигәнен, әмма...

Шулай диде дә аждаһа авызыдай зур итеп ачылган мич авызына төбәлде. Шушы минутларда карчык убыр мич авызының чирек гомер буена күпме салам, кизәк ашаганы турындамы, әллә бөтенләй башка нәрсә турында уйландымы икән — әйтүе кыен, әмма ул яңадан бәхәскә кушылмады.

Габдрахман бабай да, кайчандыр мал-туар, кош-корт белән тулы ишегалдына тәрәзә аркылы күз сирпеде. Әйе, хәзер ул бушап калган, бернинди җан иясе дә күренми.

Вәсилә дә, үзенең яман эш эшләгәнен аңлагандай, тынып калды. Шомлы тынлыкны ерып, тагын Бибинур әби:

— Ярар, кызым, илт бу кәгазьне район үзәгенә, каткан бәгырьләре эреп китмәсме...

— Дөрес, энкәй, оятсыз бу бәндәләргә шулай кирәк,— дип, әнисенә имза куясы урынны бармагы белән төртеп күрсәтте.

Тик йөзе сулып барган карт кына дәшми иде әле. Гаризага имза куйганда да авыз ачып бер кәлимә сүз әйтмәде.

Суд карары озак көттермәде, килеп тә җитте. Бер-ике ай вакыт үттеме, юкмы, ерак Актаныш ягындагы бер авылның элемтә бүлегенә ай саен аз-маз күләмдә алимент акчасы килә башлады. Картлар бу акчаларны үз аяклары белән барып алудан баш тарттылар, авылдашларыннан уңайсызландылар булса кирәк. Хат ташучыны да капка төбендә генә каршы алып, акча кәгазенә ашык-пошык кына кул куеп җибәрә торган булдылар. Бибинур апа бу акчаларның бер тиененә дә кагылмады, улларының икесенең дә акчасын икегә аерып, әбисеннән мирас булып калган тукылган сөлгегә төреп, 54 ел элек Габдрахманга кияүгә чыкканда үзе белән алып килгән иске агач сандыкка салып куя торган булды. Улларына кайтарып бирергә уйлады ул. Ә Габдрахман карт бу акчалар белән бөтенләй кызыксынмады, өзелеп сагынып улларын көтте.

Бу вакыйгадан соң берничә ел вакыт үткәч, Пермьнән кайткан берәү:

— Габделнур белән Зиннурны күрдем, һәрвакыттагыча «салмыш» иделәр. Мин авылга кайтам, әтиәниегезгә нәрсә дип әйтим, дигәч, тегеләр: «Безнең әти-әниебез башка юк, алар безне, алиментка биреп, кеше алдында хур иттеләр»,— дигәннәр, имеш.

Бу хәбәрдән соң тагын дүрт ел вакыт үтте. Менә Габдрахман бабай үлем түшәгендә ята. Соңгы минутларына кадәр саташу катыш:

— Кайтмадылармы? — дип сорый.

Табиблар тарафыннан расланган телеграммага каршы да җавап килмәде.

Ниһаять, Габдрахман бабай мәңгегә күзен йомды. Нәкъ ярты ел дигәндә, Бибинур әби дә салкын җир куенына керде. Аны карты белән янәшә җирләделәр.

Тормыш дигәнең бик катлаулы нәрсә. Кеше китә, акренләп онытыла.

Габдрахман бабай белән Бибинур әбине һәм аларның уллары турында да авыл халкы оныта башлады. Сирәк-мирәк кенә кызлары Вәсилә туган ягына кайтып олыларга әти-әнисенең рухына укырга дип садака өләшә иде.

Менә шулай берзаман мин, бу язманың авторы, үземнең Актаныш ягындагы туган авылыма кайткач, бабам, әбием һәм башка туганнарым күмелгән зиратка барырга булдым.

Каберлектә уйланып басып торганда, бер почмакта кабер киртәсенә сөялгән карачкыга күзем төште. Таныш булмаган бу затка якынрак килергә булдым. Исәнләштем, үземнең кем һәм кайдан икәнлегемне әйттем.

— Ә сез кем буласыз? — дип соравыма ул, озак кына дәшми торгач, ишетелер-ишетелмәс кенә тавыш белән:

— Зиннур мин. Минем әти-әниләрем монда күмелгән. Габдрахман белән Бибинур...— дип җавап бирде.

Үземнең авылдашымны балачак төсмерләре белән генә көчкә танып алдым. Барыбызның да бәхет эзләп авылны ташлап китүебезгә инде ничә дистә ел узса да, безгә Зиннур абый белән дә очрашырга язган булган икән. Кайда дисең әле — зиратта.

— Минем яшьтәш Габделнур бар иде, ул хәзер кая? — дип кызыксындым.

— Үлде. Эштә фаҗигале төстә үлде,— диде авылдашым.— Ә менә мин әти-әни янына дип килдем...

— Әйдә, авылга төшәбез,— дим авылдашыма.— Берәр чынаяк чәй эчәрбез.

— Юк! — дип, кискен итеп әйтеп куйды Зиннур абый.— Ямалыга, пристаньга ашыгам. Чаллы — Чайковский метеорына. Аннары икенче метеор белән Пермьгә чаклы.

Бераз сөйләшеп алгач, Зиннур абый белән зираттан чыгып киттек. Мин туган авылыбызга, ул Ямалы пристанена таба.

Берничә минуттан артыма борылып карасам, ябык гәүдәле авылдашым Зиннур абый, болытлар арасыннан кыеклатып төшкән кояш нурлары астында шомлы шәүлә эзләре калдырып, әкрен генә офыкка таба атлый иде.

# Бер алдашкач...

Ашыгулар ялгышуга була,
Ашыгырга никтер яраттым.
Ашыгулар — урман,
Ялгышларым — буран,
Йөгерә-йөгерә кереп адаштым.

*Нурия Измайлова*

Вераның кәефе иртәдән үк кырылган иде, йөрәктәге төер тишелә алмыйча ни гомер җанын бимазалый. Юк, болай булмый. Бу билгесезлектән ничектер котыласы, кемгәдер сөйлисе, һич югында киң җиһанга чыгып кычкырасы килә.

Шунда гына чәй эчеп утырган Котдуска таба борылып, йотлыга-йотлыга:

— Хәшәрәт, кысыр тәре, синең аркада мин бала табу, ана булу бәхетеннән мәхрүм булып йөрим,— диде. Ачу катыш, токмач салынган сөзгечне су краны астындагы раковинага атып бәрде дә аш бүлмәсеннән тиз-тиз чыгып та китте.

Көтелмәгәндә башланган бу җәнҗал аяз көнне яшен суккандай итте. Котдус җавапсыз калды, йөрәге дөп-дөп итеп типте, чигәләренә кайнар кан йөгерде, башы чатнаудан күз аллары караңгыланып китте. Ун минутлап шул халәттә утырганнан соң, залга чыкты, китап киштәсеннән кулына эләккән бер китапны алып диванга барып ауды. Бу — Бенвенуто Челлининың «Алтын куллы оста» дигән китабы булып чыкты.

Котдус, карап-нитеп тормыйча, китапның бер битен ачып шунда төбәлде һәм автор белән киңәшкәндәй итеп әкрен генә:

— Әйтегез, миңа ни хәл итәргә? — диде.

Урта гасырларда яшәгән итальян остасы дәшмәде.

— Йа Аллам, беркайчан да уянмаслык итеп йокыга талдыр! — диде Котдус, ишетелер-ишетелмәс кенә итеп.

Әмма Котдусны яткач та йокы алмады. Китапны түшенә кыскан килеш бер ноктага төбәлеп тик ятты. Вера белән бергә яшәгән чаклар, кинокадрлар булып, бер-бер артлы күз алдыннан үтте.

КамАЗ төзелә башланган еллар Котдус язмышында хәлиткеч роль уйнадылар. Шунда килеп ул зур, шул вакытта тормышында ажаган шикелле генә ялтырап киткән мәхәббәтен тапты.

Язмыштан узмыш юк, дип, халык тикмәгә генә әйтмидер. Урал якларында Котдус (анда аны Костя дип йөрттеләр) тулы канлы тормыш белән яшәде. Утыз дүрт яшьләрендә аның тормышы түгәрәк, күңеле күтәренке иде. Бөтен уңайлыклары булган зур фатир, сөйгән хатыны, чибәр кызчыгы бар иде. Берберсен яратышып яшәделәр. Эштә дә төшеп калганнардан түгел — төзелеш тресты начальнигы урынбасары.

Шулай кайгы-хәсрәтсез, тыныч кына яшәп яткан бер мәлдә газеталар, радио һәм телевидение көнетөне Чаллыда төзеләчәк галәмәт зур завод турында яза, сөйли башладылар. Бәрәкәт, Котдусның туган ягында ич бу! Йөрәк чеметтереп куйды, Котдусның күңеле туган ягын сагынды.

Күп тә үтмәде, хатынына, урнашу белән үк килеп алам, дип, ул Кама ярларына таба юл тотты.

Аны шунда ук бер төзелеш трестының җитештерү-технология җиһазлары белән тәэмин итү идарәсенә начальник урынбасары итеп билгеләделәр һәм җитәкче кадрлар өчен төзелгән тулай торактан урын бирделәр.

Котдус эшне җиренә җиткереп, ару-талуны белми эшли, кул астындагылардан да шуны таләп итә белә иде.

Гадәти эш көннәренең берсендә, дөресрәге, 8 Март бәйрәменә бер атна каларак, аның секретаре, кабинетка кереп, хуҗалык тауарлары кибетенең товароведы кабул итүне үтенә, диде.

— Керсен,— диде Котдус, язып утырган кәгазьләреннән башын күтәрмичә генә.

Егерме ике яшьләрдәге аксыл сары чәчле кызыкай кабинетка күбәләктәй очып кергәндәй булды.

Котдус-Костяны әйтерсең лә ток сукты. Кыз чыннан да, кояшлы, аяз көнне чәчәктән-чәчәккә кунып очып йөргән аксыл коңгырт күбәләккә охшаган. Аның зур зәңгәр күзләре елмаеп кабинет хуҗасына төбәлгәннәр. Котдус эсселе-суыклы булып китте. Йа Хода!

Кыз үзен Вера Ивановна дип таныштырды, кулындагы балалар бакчасына берничә комплект мебель җибәрү турында язылган кәгазьне Котдуска сузды.

Хуҗа кәгазьне алып имзалады һәм кызны счет яздырып алу бүлегенә җибәрде. Кыз ишек янына җитәрәк, борылып:

— Әйбер-мазар кирәксә, рәхим итегез,— диде.

— Ә сез телефон номерыгызны калдырыгыз,— диде Котдус.

Шушы минуттан Котдусның җаны җилкенә башлады, йөрәген әлегә кадәр сизелмәгән шомлы дулкын иркәләде, теге аксыл коңгырт күбәләк гел күз алдында очып йөрде. Котдус җәтмәгә эләккән чур-

тандай бәргәләнде, суккаланды, әледән-әле шылтыратырга дип, телефон трубкасына үрелде, ләкин сөйләшергә курыкты.

Алтынчы март көнне түзмәде, хуҗалык тауарлары кибетенә шылтыратты. Телефонны Вера алды.

— Сезне мин сигезенче март белән котлыйм,— диде Котдус, шуннан соң гына Костя дип үзе белән таныштырды.

Кыз тыела алмыйча каты итеп кычкырып көлеп җибәрде:

— Иртәрәк түгелме соң? Ярар инде, игътибарыгыз өчен рәхмәт,— диде.

Димәк, барысы да җайлана. Котдус аның, минем көнчел ирем, ике балам бар. Телефоннан ләчтит сатып утырырга минем буш вакытым юк, дип әйтер дип уйлаган иде.

Юк-барны сөйләшә торгач, Вераның да Чаллыга әле күптән түгел Ростов өлкәсеннән килгәнлеге мәгълүм булды. Иреннән аерылган. Ир белән ул өч ай гына яшәп калган. Аның сүзләренә караганда, ир рәхәтен рәтләп татырга да өлгермәгән. Балалары юк. Тулай торакта ике кешелек бүлмәдә яши.

Котдус-Костя эштән соң «УАЗ»ик белән Вера янына киләчәген әйтте. Очрашырга сүз куештылар.

Шофер аларны «Студенческая» тукталышында төшереп калдырды. Верага сигезенче, ә Котдуска азрак сулга табарак урнашкан өченче торак комплексы кирәк иде.

Алар озак, ике-өч сәгатьләп, әлегә төзекләндереп бетерелмәгән Муса Җәлил проспекты буйлап арлы-бирле сөйләшеп йөрделәр. Сигезенче мартны Вераның эш коллективы белән бергә «Ровесник» кафесында үткәрергә карар кылдылар.

Икенче көнне Котдус бик кыйммәтле бүләк сатып алды. Сәгать дүртләр тирәсендә ул, Верунчикны (ул аны шулай атый башлаган иде инде) эшеннән каршы алып, тулай торакка кайтарып куйды. Котдус-Костя үзен күкнең җиденче катында итеп сизде. Хисләрдән җиңелчә генә башы әйләнеп китте, мамыктай ак болытларга утырып каядыр еракларга очып китәсе килде.

Бәйрәм кичәсенә җәяү генә бардылар. Чибәр һәм ялгыз хатын-кызлар коллективында озын буйлы, каратутлы, коңгырт күзле Котдус иксез-чиксез игътибар үзәгендә булды. Әле яңа гына алган Финляндиядә тегелгән модалы кримплен костюмы буй-сынына килешеп тора, ул гел елмайды, үзен бик иркен тотты. Монда кайсысы чибәррәк — күбәләк Верамы, әллә Котдус-Костямы, аерып әйтү мөмкин түгел иде, чөнки алар тышкы кыяфәтләре белән бер-берсенә пар булырдай тиң кешеләр.

Бәйрәм бик матур һәм искитәрлек тиз үтеп китте. Алдагы көннәрдә дә ике яшь йөрәкнең мәхәббәте көннән-көн чәчәк атты, ныгыды.

— Аллага мең рәхмәт! — дип кычкырып, Котдус, кулларына күтәргән Вераны күккә чөя-чөя, тулай торак бүлмәсе буйлап йөгерә-йөгерә әйләнде. — Мин Алланы кешеләрнең йөрәкләрен бергә бәйләгәне өчен яратам! — дип өстәде Котдус.

Шулай өч айлап вакыт үтте. Котдуска Яңа шәһәрдә төзелгән йортларның берсеннән ике бүлмәле фатир бирделәр. Ләкин ул күчәргә ашыкмады, үзе шикелле үк түрәләр белән бергә тулай торакта яши бирде. Ничек Уралдан хатынны һәм кызны алып килергә, дигән сорау аның күңелен телгәли башлады. Ә Вера белән нәрсә эшләргә?

Хатын-кызның сиземләү сәләте җәнлек-җанварларныкыннан һич тә ким түгел. Вера Котдусның икеләнүен бик тиз тоеп алды һәм мәсьәләне кабыргасы белән китереп куйды:

— Костя, җанкисәгем! Әйдә, берьяклы булыйк. Йә тегендә, йә монда. Миңа ярты бәхет кирәкми...

Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, хатыныннан бер-бер артлы ике хат килеп төште: йә бөтенләйгә өйгә кайт, йә булмаса шунда кал. Мин моннан беркая да китмим.

Бер ярты ай уйланып йөргәннән соң, Котдус-Костя җитди бер карарга килде. Вераны яңа фатирга алып кайтты. Чаллыда ул елларда катнаш никахлар ташкыны ярларыннан тулып ташкан чак. Котдус-Костя белән Вера да шул сафларны тулыландырдылар. Хатыны белән аерылышу турында әлегә уйланмады, ләкин мин анда яңадан әйләнеп кайтмыйм дип, төп-төгәл әйтеп, җавап хаты җибәрде. Кызыннан акчаны кызганмады, гел җибәреп торды.

Яшь пар күктән төшкән бәхеттән ләззәтләнделәр, сөештеләр. Әкренләп фатирга яңа җиһазлар алып куйдылар. Вераның Дон буенда яшәгән туганнары кунакка килә башлады.

Ничек кенә авыр булмасын, Котдус үзен көчкә җиңеп хатыны белән аерылышырга дип кайтып китте. Көннәр үтә торды. Яшьләрнең мәхәббәте көннән-көн үсте, зурайды. Шулай итеп, өч ел вакыт та үтеп китте. Тора-бара Вераның йөзендә канәгатьсезлек билгеләре күренгәләде, еш үпкәли, көйсезләнә башлады. Беркөнне сак кына итеп, Котдуска болай дип сүз катты:

— Безгә бала алып кайтасы иде, вакыт үтә бит.

Беренче хатыныннан баласы булгангамы, Котдусның бу турыда уйланганы булмады. Ул әкияти тылсымлы мәхәббәт хозурында яшәде. Вераның сүзләренә дә шаяртып кына җавап бирде:

— Безнең яшьтә әле... Берзаман әмәлләп куярбыз берне,— диде.

Нигәдер «әмәлләп» булмады. Тагын бер елдан Верочкасы, итагатьле генә итеп, бу турыда Котдусның исенә төшерде: «Нәрсә безнең балалар булмаска охшаганмы?»

Котдус һичнинди кинәсез, йомшак кына итеп: «Хатын-кызлар табибына барып кара, тикшерен»,— диде.

Бер атнадан кичке аш вакытында Вера иренә мондый яңалык әйтте:

— Табибта булдым. Ирең башта эндокринологка күренеп карасын. Аның анализлары нәтиҗәсеннән чыгып, сезне тикшерербез дип әйтте. Менә сиңа эндокринологка барырга юллама,— диде.

Вераның катгый таләпләренә бик исе китмәде Котдусның. Ләкин шулай да тикшерелергә барып кайтты. Атна буена аны бик җентекләп тикшерделәр һәм соңыннан кулына «сәламәт» дигән белешмә тоттырдылар. Кыскасы, гаеп аңарда булып чыкмады. Котдус-Костя уйланып калды. Бу белешмәне әгәр өзелеп яраткан Верасына күрсәтсә, аны хатын-кыз буларак бик каты хәсрәткә салачак, ә Котдус олы мәхәббәтен югалтачак. Бу уйларны хәтта уйлаганда да аның йөрәге бик каты типте, аңа бик куркыныч булып китте.

Котдус әүвәл баш табиб белән киңәшләшергә уйлады. Алар бик якын танышлар иде. Бергәләп шифаханәне төзи башлап, аны эксплуатациягә тапшырган һәм шунда бик нык дуслашкан иделәр.

Ике ир-ат бик озак серләштеләр. Котдус үзенең мәхәббәтен һәм яраткан кешесенең хатын-кыз горурлыгын саклап калырга карар кабул итте. Баш табибтан үзенең нәсел калдырырга сәләтсез ир дигән белешмә язып бирүен үтенде. Янәсе, моңа ул үзе гаепле икән.

Белешмәне укып чыкканнан соң, Вераның йөзе ачылып китте. Димәк, ул сау-сәламәт, тулы кыйммәтле хатын-кыз. Аннары, уйланып китеп, Котдустан сорап куйды:

— Костя, шулай булгач синең кызың каян килде соң?

— Ул туганнан соң мин бик каты итеп бөерләргә һәм аннан түбәнрәк әгъзаларга салкын тидергән идем, шуннан рәтләнеп китә алмадым. Кышын балыкка баргач булды бу,— дип, күзләрен күтәрмичә генә алдады Котдус.

Тормыш берни булмагандай дәвам итте. Вераның табигатендә һәм тәртибендә әллә ни үзгәреш сизелмәде. Ләкин Котдуска ничектер югарыданрак, зәгыйфьрәк кешегә карагандай кызганыбрак карады. Котдус моны сизенсә дә, эшне куертмады, аңа калса бу бик вак мәсьәлә иде. Вера ятим балалар йортыннан бала алырга кирәклеге турында ешрак сөйләнә башлады. Ләкин Котдус хатынының тәкъдименә каршы чыкты.

Шушы көннән Вера танымаслык булып үзгәрде. Еш кына төрле гаепләр табып иренә ташланды, кыскасы, Дон казаклары каны уянды аңарда. Үзара мөнәсәбәтләр көннән-көн бозыла барды. Берзаман Котдус өйгә бик соң һәм шактый салган килеш кайтты. Мәскәүдән бер түрә килгән иде, шулар белән табигать кочагына чыктылар. Верунчик Котдусны мондый кыяфәттә күрү белән чәчрәп чыкты:

— Татарская морда! Теләсә кая теләсә кем белән сөйрәлеп йөреп монда кайтасың...

Татарга карата әйтелгән мондый кабахәт сүзләрне Котдус кичерә алмады. Сикереп торып Верунчикны яхшылап яңаклап алды.

Соңыннан Котдус сөекле хатыныннан гафу үтенеп йөрсә дә, үзара мөнәсәбәтләр күпере бик нык чатнаган, ишелеп төшү дәрәҗәсенә җиткән иде.

Бу ызгыш-сугыштан соң бер атна чамасы вакыт үттеме-юкмы, юк-бардан гына тагын гауга чыкты. Вера, чыгырыннан чыгып, үзенең холкын күрсәтте.

— Хәшәрәт, кысыр тәре, синең гаеп белән мин бала табу, ана булу бәхетеннән мәхрүм булып йөрим,— дип ачыргаланды.

«Әйе, ялганлау — ярты тормыш булды»,— дип уйланып куйды Котдус.

Икенче көнне Верунчик эштә чагында үзенең өс-башын, берничә яраткан китабын, кырына торган машинкасын бер сумкага салып, шоферының фатирына илтеп куйды. Шоферның хатыны бала табарга дип туган якларына кайтып киткән иде.

Ике көннән соң ук ул Алабуга шәһәренә яңа автомобиль заводы төзелешенә китте.

...Бу хәлләрдән соң егерме елга якын вакыт үтте. Үткән елны Чаллы Сабан туенда бик сөйкемле хатынын, ун һәм ундүрт яшьләрдәге ике кызчыгын җитәкләгән Котдусны очраттым. Без кочаклашып күрештек. Кайчандыр дус булып йөргән Котдусым олыгаеп, тазарып киткән, матур булып чәчләренә чал кергән. Шушы ук ягымлы елмаю, шушы ук чемкара кашлар.

— Бу чибәркәйләр кемнәр? — дип сорадым Котдустан.

— Минем алабугалылар. Анда мин яңа оя кордым, ике бала үстерәбез.

— Ә беренче хатының кая?

— Күптән инде яңадан тормышка чыкты. Олы кызымнан ике оныгым менә боларны куып җиттеләр инде,— диде ул, кызчыкларына ымлап күрсәтеп.

— Ә Верунчик? Күбәләккәең кайда?

— Фатирыбызны алмаштырып әти-әнисе янына Донга күчеп киткән.

Бераз сүзсез торганнан соң, Котдус авыр сулап:

— Дустым, син ярага тоз сипмә, яратам мин аны, аксыл сары чәчле күбәләккәемне. Бүгенгә кадәр өзелеп яратам. Аллама мең рәхмәтлемен, аҗаган шикелле ялтырап кына киткән кебек булса да, олы мәхәббәтемне тапканым өчен. Алла безне кавыштыра да, аерылыштыра да. Бу гөнаһлы җирдә безнең язмышларыбыз шундый...

Шунда ерак түгел генә утырган гаиләм янына әйләнеп кайттым.

— Нәрсә турында шундый озак итеп сөйләштегез,— дип сорады хәләл җефетем.
— Олы мәхәббәт турында,— дигәнемне сизми дә калдым.

## Өй алдында шомыртым ла…

Кич белән бик соң гына, өй тәрәзәләрендәге җемелдәп янган утлар бер-бер артлы сүнә башлаган бер мәлдә, безнең фатирның звоногына бастылар, дерт итеп киттем. Чөнки звонок тавышы миңа үтә катгый, өзек-өзек һәм ничектер хәвефле сыман тоелды. «Мондый вакытта кем булуы мөмкин?» — дип уйлап ишеккә таба атладым. Беренче фатирдан Зәйнәп апа икән ләбаса. Олы яшьтә булгангадыр, безнең йортта яшәгән һәркем аңа Зәйнәп апа дип эндәшә иде.

— «Ашыгыч ярдәм»гә шалтыратырга рөхсәт итегез, зинһар,— диде ул, гафу үтенгән кебек.— Рәиснең хәле авыр.

Ни гаҗәп, «ашыгыч ярдәм» машинасы бик тиз килеп җитте. Миндә дә кызыксыну уянды. Һәм эшнең ни белән бетәсен карарга дип, балконга чыктым.

Урамда саф һава, шомырт чәчәкләре исе борынны кытыклый. Йа Алла, безнең ишегалдында бөдрәләнеп үсеп утырган бу шомырт агачын шушы Зәйнәп апаның олы улы Рәис хәрби хезмәткә китәр алдыннан утырткан иде. Күз тимәсен, әнә теге шомырт куагы да, монысын куып җитеп, икенче каттагы тәрәзәләргә үрелә башлаган. Аны Рәиснең кече энесе Ранис шулай ук армия сафларына китәсе көннәрдә утыртып калдырды.

Менә подъезд ишегеннән беренче булып Рәис килеп чыкты. Аякларын көчкә өстерәп, арткы ишегенә кызыл тәре төшерелгән «рафик»ка таба юнәлде. Аның артыннан: «Улым! Рәисем!» — дип сөйләнә-сөйләнә Зәйнәп апа атлый.

— Җәһәтрәк атла, апа, хисләргә бирелмичә генә,— диде медицина хезмәткәре һәм сул кулы белән Зәйнәп апаны этеп җибәрде дә, уңы белән машина ишеген гөрселдәтеп ябып куйды. Машина, шул секундта ук урыныннан кузгалып, үкерә-үкерә төнге караңгылыкка кереп югалды.

Кирәк бит шулай туры килергә, ике көннән шушы ук «ашыгыч ярдәм» машинасы аңсыз яткан Рәисне яңадан өйгә алып кайтты.

— Дәваларга соң инде,— диде табиб, Зәйнәп апага таба борылып.— Улыгызның бавыры эшләүдән туктаган. Кыскасы, өметсез. Наркотиклар куллануның нәтиҗәсе бу.

Рәис ике көннән, аңына килә алмыйча, утыз алты яшендә бу фани дөнья белән мәңгегә саубуллашты.

...Зәйнәп апа белән Васил абый Яр Чаллыга КамАЗ төзелешенең иң кызган чагында Пермь өлкәсеннән күчеп килгән иделәр. Дөресрәге, туган якларына кайттылар. Алар илленче еллар уртасында Пермь якларына икмәк эзләп киткән иделәр. Чит-ят җиргә килгәч, башта аерым-аерым тулай торакта яшәделәр. Өч ел үттеме, юкмы, аларга өч бүлмәле фатир ачкычын тоттырдылар. Торак урын беренче катта булса да, бүлмәләре аерым, киң, иркен иде. Менә балалары да, тәгәрәшеп үсеп җитеп, берәм-берәм мәктәпкә киттеләр. Бу ишле гаиләнең башлыгы Васил абый төзелештә ташчы булып эшли, ә Зәйнәп апа аның бригадасында төрле эшләр башкара иде.

Аларның тормышы, көннән-көн рәтләнеп, гел уңай якка гына тәгәрәде. Олыгая барган көндә язмышның болай шәфкатьле елмаюына Зәйнәп апа да, Васил абый да сөенеп бетә алмадылар. Артыгын кыланып, кеше шаккатырырлык булмаса да, уртача яшәр өчен бөтен әйбер дә җитәрлек иде. Ләкин ни хикмәттер, бәхетле еллар бик тиз үтүчән булалар. Менә уллары Рәискә дә хәрби хезмәткә чакыру турында кәгазь килде. Бөтен йорт халкы җыелып озатты аны. Бу хәл әфган сугышы тәмамланыр алдыннан булды. Улын озатканда, Зәйнәп апа бертуктамый елады да елады. Мескенкәем, улының шушы чикләнгән контингентка эләгүеннән курыккандыр инде.

Ләкин Зәйнәп апа юкка гына борчылмаган, аның күңеле алдан ук нидер сизенгән икән.

Ярты еллап хезмәт иткәннән соң, Рәис кыска гына язылган бер хатында, Әфганстан башкаласы Кабулдан ерак түгел генә урнашкан Бәһрам шәһәрендә хезмәт итәм, барысы да әйбәт, дигән иде.

И-и, шулай әйтүе генә җиңел. Шушы ярты ел эчендә Зәйнәп апаның чәченә тәмам чал керде, йөзе сулды. Васил абый ир-ат буларак сабыррак кыланса да, барыбер бирешә, үз эченә бикләнеп, сөйләшмәскә әйләнде. Еллар үтә тордылар...

Безгә калса, әле кичә генә Рәисне армиягә озаткан идек, ә ул инде әнә солдат киемен киеп үзе утырткан шомырт төбендә басып тора.

Өйалдына тиз-тиз генә өстәл әмәлләп куйдылар, кемнең нәрсәсе бар, шуны алып чыгып, шушы өстәлгә тезделәр. Бу солдат кайту хөрмәтенә оештырылган мәҗлес иде.

Зәйнәп апаның шатлыгы эченә сыймый, азрак салып алган Васил абыйның да теле ачылды. Без дә ярыйсы гына сыйландык. Дистә елга сузылган мәрхәмәтсез әфган сугышы бетеп, кешеләр иркен сулыш алдылар.

Ләкин күңелле генә бәйрәм итеп утырган бу кичтә әфган сугышының безнең илгә алып килгән башка афәт турында беркемнең дә уена килми иде әле. Әйе, башта бу афәт турында теләр-теләмәс кенә, ярым пышылдап, һәлакәтнең тирән мәгънәсен аңламыйча гына сөйләделәр. Соңыннан, беренче фатирга ниндидер төксе, сөяк белән тирегә генә калган билгесез кешеләр йөри башлагач кына, бу афәтнең безнең өй тирәсенә якынлашканын сизендек. Бу турыда Зәйнәп апага да җиткердек, шуннан соң теге шәүләләр берән-сәрән генә тәрәзә төбенә җыела башладылар. Аларның килеп басуы була, тәрәзә тавышсыз-тынсыз гына ачыла да аннан башта Рәиснең башы күренә, аннары тәргәк тоткан кулы сузыла. Кемнәрдер түзмичә хәбәр иткәннәрдер: беркөнне өйалдына милиция хезмәткәрләре килеп төште. Рәиснең тәрәзә аркылы наркотиклар сатканлыгы билгеле булды. Бу шөгыльгә ул Әфганстаннан өйрәнеп кайткан икән.

Рәискә ике ел бирделәр. Ләкин аны төрмәгә утырту белән генә безнең подъезд тирәсендә тынычлык урнашмады. «Кәеф» күтәрү эшенә Рәис үзенең энесе Ранисны һәм 10 нчы класста укучы сеңлесе Альбинаны да өйрәткән булып чыкты. Абыйсының «көнчыгыш запас»лары беткәч, Альбина бу хезмәтне өй шартларында ясарга өйрәнә. Башта ул, стакан күтәреп, күршеләреннән кыяр, помидор тозларга кирәк дип, әҗәткә серкә сорап йөри. Аннары подъездда әллә нинди исләр аңкый башлый. Беркөнне икенче катта яшәүче күршебез Наташаның башы авырта, күз аллары караңгылана башлый. Шунда ул көчле ацетон исен сизеп ала. Күршеләрнең бу кыланышка ачулары килеп милиция чакырталар. Милиция, килеп, күрше-күләннән сорау алып, беренче фатирда тентү үткәрде. Наркотиклар ясау җайланмалары, инәләр табылды. Милиция хезмәткәрләре беркая да эшләмәгән Ранисны һәм укуын ташларга өлгергән Альбинаны кулга алдылар.

Шушы көннән башлап безнең подъезд халкы өчен тормыш чын-чыны белән тәмугка әйләнде. Зәйнәп апа гаиләсенә килгән бөтен бәхетсезлекләрне дә бездән, күршеләреннән күрде, явызланды, каргады. Васил абый егерме ел буена тату гына яшәгән күршеләре белән исәнләшми, сөйләшми башлады. Бу хәл берничә елга сузылды. Шушы еллар эчендә Ранис та Чечнядан хәрби хезмәттән дары исе иснәп кайтты, ә Рәис шул вакыт эчендә ике мәртәбә төрмәдә утырып чыгарга өлгерде. Тик шомырт агачы каплап торган беренче каттагы беренче фатир тәрәзәсе янындагы тормыш кына һич тә үзгәрмәде, элеккечә дәвам итте. Ранис белән Альбинаны берничә мәртәбә милиция алып китте, ни сәбәптәндер, аларны бер-ике көннән өйләренә кайтарып җибәрә иделәр. Әшәкелекнең чиге юк. Хәзер инде күршеләребез бу тәрәзә янында күрше өйләрдән дә яп-яшь малайларның җыела башлауларын күзәтәләр иде.

Ләкин Рәисне күмгән көнне беренче фатир хуҗаларының күршеләре белән булган ике арадагы кызган атмосфера ничектер сүрелә. Менә «ГАЗ-53» машинасының кузовында аннан-моннан гына кадак белән каккалап ясалган такта табут эчендә сап-сары йөзле Рәис ята. Тирә-яктагы урындыкларда, үз яшенә караганда күпкә картрак күренгән әнисе Зәйнәп апа һәм сеңлесе Альбина утыралар. Ранис күмүдә катнашмады. Ул психик авыруларны дәвалау хастаханәсендә ята иде.

«ГАЗ-53» машинасы әкрен генә кузгалып китте. Аның артыннан башын түбән игән Васил абый һәм биш-алты туган тиешле кеше бара. Машина алдына туган-тумачалары лалә, кыңгырау һәм кайчандыр үзе утырткан шомырт чәчәкләре сиптеләр. Җыелган халык дәшмичә генә басып торды, күбесе бу вакыйганы балконнан күзәтте. Наркотик матдәләрнең исен туйганчы иснәгән Наташа сүзсез генә күршеләрдән унар сум акча җыя һәм үзалдына әкрен генә:

— Ул дөмеккән нәрсәнең юлына шомырт чәчәкләре түгел, ә киндерботаклары һәм мәк саламы җәясе иде,— ди.

Мәетне озатучылар тавышсыз-тынсыз гына полиэтилен капчыкка ун тәңкәләрен ташладылар. Иске йөк машинасы тиздән борылышка кереп күздән югалды. Беренче фатирның тәрәзәсе янында көне-төне көтүләре белән өерелешеп йөргән теге адәмнәрнең берсе дә күмү процессиясендә катнашмады. Чөнки Рәиснең алар өчен кирәге калмаган иде инде.

## Зифаның алтын бармаклары

Чаллының «Универсам» тукталышындагы урам аркылы чыга торган җир асты һәм шуңа терәлеп торган мәйданчык — шәһәрнең халык ташкыны кайнап торган урыннарыннан берсе. Аңлашыла ки, монда зур «Универсам» кибете бик күп төрле вак-төяк сәүдә нокталары һәм халыкка хезмәт күрсәтүгә корылган башка оешмалар тезелеп киткән. Якында гына зур үзәк базар.

Июль аеның эссе бер көнендә, урамның теге ягына чыгарга дип, шушы җир асты юлына төшеп барганда, бер хатын-кыз миңа исемем белән дәште. Мин башта артыма, аннары як-ягыма борылып кара-

дым. Кем бу? Таныш кеше дә юк шикелле. Юлымны дәвам итәргә дип, бер-ике адым атлаган идем, теге тавыш тагын кабатланды.

— Тьфү, шайтан, минем исемне әйтә ич,— дип туктап калдым. Яңадан әйләнеп, шунда сөт, яшел кыяр, помидор, җир җиләге һәм шуның ише Кама буенда үскән табигать җимешләре белән сату итүче хатын-кызларның йөзләренә карыйм.

— Якташларыгызны танымыйсызмы әллә? — ди сөт тутырылган өч литрлы банкалар белән әйләндереп алынган сөт сатып утыручы ханым һәм тезелеп киткән сөттәй ап-ак тешләрен күрсәтеп матур итеп елмайды.

Мин якынрак килдем һәм, мәхәббәтле итеп елмаеп басып торган ханымны танып алып, ирексездән кычкырып җибәрдем:

— Бәй, Кифая бит бу! Син бит, ә?

— Мин шул! — диде гаҗәпләнебрәк калган ханым һәм тагын да мөлаемрак итеп елмаеп куйды.

— Әй Аллам,— дидем якташымны, классташымны очрату шатлыгыннан каушап китеп,— синең белән күрешмәгәнгә инде егерме биш ел вакыт үтеп киткән икән. Үзең дә үзгәрмәгәнсең, сөт сатып утырган урыныңны да алмаштырмагансың.

— Судьба такой,— дип, ярым шаяртып урысчалатып әйтеп куйды якташым.— Монда мине «Сөт сатучы Кифая» дип кенә йөртәләр. Әйе, мине монда барысы да белә, минем үз сатып алучыларым бар.

Шулай көлешә-көлешә сөйләшеп торганда, минем күзем җир асты юлына төшү баскычының икенче ягында утырган бер хатын-кызга төште. Баш мие кайнарлык эссе кояш астында ул аягына ирләрнең шнурсыз кышкы ботинкасын, өстенә чәчәкләре уңып, таушалып беткән күлмәк кигән. Бите шешенгән, күз төпләре кара көйгән. Каршында, бетон идәндә, алюминий савыт ята. Ул пычрак, яргаланып беткән кулларын узган-барганга сузып хәер сораша.

Минем шушы хәерчегә таба төбәлеп караганымны сизеп, Кифая серле итеп кенә сорап куйды:

— Танымыйсыңмы?

— Ю-ук,— дидем мин сагаеп кына.

— Игътибар беләнрәк кара. Зифаны хәтерлисеңме? Алтын кул Зифаны, беләсең инде. Теге ресторан буфетында эшләгән Зифа, исеңдәме?

Алюмин савытка зыңгылдап төшкән тәңкә тавышлары мине уйларымнан айнытып җибәрде, ә теге теләнчедән тирә-якны тутырып сасы ис килә иде.

— Чынлап та шулмыни бу? — дидем мин, гаҗәпләнүемнән туктый алмыйча. Шул минутларда КамАЗ төзелешенең һәм шәһәренең беренче еллары искә килеп төште. Ул елларда монда Советлар Союзының барлык почмакларыннан халык агылды. Татарстанның да бик күп шәһәр һәм авылларыннан килүчеләр шактый иде. Шулар арасында минем классташым Кифаяның да гаиләсе бар иде. Ул бездән ике-өч чакрым ераклыктагы күрше авылдан иде. Мин ул авылга бишенче, алтынчы, җиденче классларга укырга йөрдем. Мәктәпне тәмамлагач, мин Сарапулга киттем. Ә Кифая күрше авыл малаена кияүгә чыкты. Алар икәүләшеп чем-кара күзле матур ике малай үстерделәр. Балалар үсеп җитеп, аларны урнаштыру турында мәсьәлә алга килеп баскач, 1973 елны, авылдагы йортларын сатып, Чаллыга килделәр. Ләкин алар мескенләнеп вагоннарда яшәп йөрмәделәр, тоттылар да Элеватор тавыннан бер йорт сатып алдылар, терлек-туарларын да бөтенләе белән шунда күчерделәр. Хәтта тавыкларын, казларын да алып килделәр.

Танышларының гаҗәпләнеп биргән сорауларына:

— Ни пычагыма ул шәһәр фатиры, безгә үз йортыбызда яшәү күбрәк ошый,— дип җавап бирделәр алар.

Сыерлары нәселле, күп сөтле, тәмле. Үзләреннән арткан сөтне ул буш вакытларында, өч литрлы банкаларга салып, Иске шәһәрдәге «Универсам» янына сатарга алып чыга иде.

Кичәге колхозчы Кифая эшнең дә балаларын, терлек-туарын карагач кына барып эшләп кайта торганын сайлады. Ул беренче ачылган ресторанга идән юучы булып керде. Производство цехлары арасындагы озын-озын коридорлар, ресторан залы һәм буфет идәне аның бизмәләренә кергә иде.

Буфетның ул чакта тулы һәм алмаштыргысыз хуҗасы булып югарыда әйтелгән Зифа эшли иде. Баштанаяк алтынга күмелгәнгәдер инде, аны Алтын кул Зифа дип йөртәләр иде. Чыннан да, аның авызы тулы алтын теш, колагында алтын алка, һәрбер бармагында зур-зур алтын йөзек иде. Аңарда патша әһелләренә генә хас булган бер гадәт бар иде. Әгәр кемнедер чакырып аласы килсә, алтын йөзеге белән өстәлгә шакый иде. Тәэсире көчле иде, билгеле. Ул заманнарда алтынны бик хәлле һәм элемтәләре зур кешеләр генә таба һәм кия ала иде. Коточкыч кыйммәт иде алтын ул чакларда.

КамАЗның удар төзелеше чорында анда «коры» закон хөкем сөрде. КамАЗчылар әле дә бер вакыйганы онытмыйлар. 1971 елның 45 градуслы салкын декабрендә А.Н.Косыгин Чаллыга килгән иде. Шунда төзүчеләр аңардан аракы сатарга рөхсәт сораганнар, ә ул болай җавап биргән: «Дуслар, КамАЗ ул безнең илдә әлегә кадәр күрелмәгән зур төзелеш. Аны аек баштан төзергә кирәк». Алтын кул Зифа ул чакта җәмгыятьнең фәрештәсе иде. Хәмергә сусаганнарга чәркәне тутырып бирде, вак-төяк белән вакланмады, граммнар белән эш итүне гади официанткаларга калдырды. Үзе зурдан кубып эшләде. Ты-

елган эчемлек «сыек валюта»ны аңа базадан, Минзәләдән яисә Удмуртиядән машинасы белән китереп бирделәр. Һәм ул аны илле процентка арттырып астан гына сатып ятты. Керем искиткеч зур иде. Аны кемнәр беләндер уртак эшли икән дип тә сөйләделәр. Ләкин конкрет рәвештә беркем дә бернәрсә дә белә алмады, кыскасы, аны белерлек тә түгел иде.

Алтын кул Зифаның ухажерлары буа буарлык иде. Аларны ул алмаштырып кына торды. Ул үзенең көне буена ана җылысын тоймыйча тилмереп утырган икесе ике атадан булган малайлары янына шуларны ияртеп кайтты.

Кешене зур акча һәм дәрәҗә боза. Зифа үзенең чикләнмәгән хокукларын һәм дәрәҗәсен сизә иде. Аның өчен җитәкчеләр дә, аның эшен тикшерергә тиешле түрәләр дә чүп кенә иде. Аңа ни кылса, шул рөхсәт ителде. Буфетның корылма өстәле артында ул еш кына «салмыш» көе басып торгалый иде. Хезмәттәшләре белән ул югары тонда сөйләште. Ә Кифая кебек идән юучыларны ул, гомумән, кешегә дә чутламый иде.

Бигрәк тә азрак салып алгач, ул акыл өйрәтә башлый иде:

— Кифая, синең дөньядан нинди яхшылык күргәнең бар? Ишәк кебек эшлисең, терлек колы булып гомерең үтә. Әле яңа төзелеш башладыгыз. Нигә кирәк сиңа ул, ә?..

Тиздән мин Чаллыдан күчеп киттем. Кифая шулай ук ресторанда идән юуын һәм көн саен «Универсам» янында сөт сатуын дәвам итте. Кирпечтән матур зур өй төзеделәр. Уллары берсе артыннан берсе хәрби хезмәткә барып кайттылар. Аннары кайсы КамАЗга, кайсы төзелешкә эшкә урнашып, кичке институтларга укырга керделәр.

Ә Алтын кул Зифа эчүгә сабыша башлады. Аракы аңа башта баю чыганагы булса, соңыннан яшәү өчен зарури әйбергә әйләнде. Ансыз яшәүнең әһәмияте юк иде аның өчен. Эш сәгатьләрендә еш кына буфетны бикләп куеп, бер-ике сәгатькә аракы әрҗәләре өстенә ятып ял итә торган булды. Әйе, хәрам мал Зифаны тәмам харап итте.

Ресторанга яңа директор килгәч, түзмәде, Зифаны икенче буфетка күчерде. Монда инде клиентлар башка, ничек дип әйтим, «икенче сорт»лы иде. Ә Зифа бу кайгыдан бөтенләй эчүгә сабышты. Шул вакытларда аның олы улын тәртип бозган өчен төрмәгә утырттылар, күп тә үтмәде, икенчесен дә ябып куйдылар.

Зифаны савыт-саба юучы итеп күчерделәр. Бармакларындагы алтын йөзекләрен салырга мәҗбүр булды һәм бераздан ул аларны әрәм-шәрәм итеп юк-бар бәягә сатып та бетерде.

Күп тә үтмәде, фатирларны хосусыйлаштыру мөмкинлеге турында хәбәр килде. Зифа ике бүлмәле фатирын хосусыйлаштырып, аны, өстәмә акча алып, бер бүлмәле фатирга алмаштырды. Ә малайлары, төрмәдән кайту белән, тагын әллә нинди маҗараларга эләгеп икенче кат шунда киттеләр.

Теге, Зифа эшләгән ресторан, реформа өермәсе кагылгач, банкротка әйләнде, тиздән аны бөтенләйгә ябып куйдылар.

Көне-төне бәйрәм итә торгач, Зифаның фатир акчасы тиз бетте. Әмма ул озак уйлап тормыйча, аерым фатирын тагын, өстәмә акча алып, бер бүлмәгә алмаштырды. Бу акча да озакка җитмәде. Бүлмәсен сатып апасына яшәргә килде. Янәсе, берничә көнгә генә. Ләкин апасы бу сәрхушкә озак түзмәде, фатирыннан куып чыгарды...

Менә мин, уйларыма чумып, бу юлдан язган сасы бәндәне кая күрдем икән дип басып торам. Әһә, искә төште бит каһәр суккан нәрсә. Бер кичне соң гына кунакханәдән чыгып, мин шәһәрара сөйләшү пунктына киттем. Шунда идәндә бер пычрак киемле хатын аунап ята иде, шул булды, күрәсең. Икенче мәртәбә мин бу шакшы хатынны үзе кебек үк бер хатын-кыз белән Чаллының тимер юл вокзалында Мәскәүгә барганда күргән идем...

Дөнья диген... кайчандыр чәчәк атып торган гөл кебек чибәр, эшлекле Алтын кул Зифа бүген алюмин савытка чылтырап төшкән тиеннәрне күзе белән озатып, санап утыра. Кыяфәтенә кеше карарлык та түгел. Моны күрмәс өчен, мин аркам белән Зифага борылдым һәм, классташыма карап:

— Кифая! Ничек хәлләрең? Ирең ничек? — дим.

— Аллага шөкер! — ди Кифая тагын елмаеп.— Малайлар гаиләләре белән үз фатирларында яшиләр. Ирем пенсиядә. Оныкларны, малларны карый. Үземне күрәсең, элеккечә үк сөт сатам. Улларым белән бик тату яшибез, бер гаилә кебек. Бик яхшы агач мунча салдык, әйдә берәр вакыт безгә дә рәхим ит. Рәхәтләнеп мунча керерсез.

— Сүз юк,— дип елмайдым мин җавап итеп һәм хушлашып китеп бардым.

Халык массасына ияреп мин җир асты юлына төшеп киттем.

* * *

Ярты еллап вакыт үткәч, Яңа ел алдыннан шушы ук мәйданчыкта сөт сатучы Кифаяны очраттым. Ул өстенә җылы дубленка, аягына киез итек кигән, башына йомшак мамык шәл бәйләгән. Ә каршы якта, шушы урында ук, пычрак пальто, тапталып беткән иске ирләр итеге киеп, Алтын кул Зифа басып тора.

Әйе, бу фани дөньяда һәр кешенең үз урыны бар.

Классташым Кифая белән исәнлек-саулык сорашып, сөйләшеп алгач, мин аңардан:

— Алтын кул Зифаның малайлары кая? — дип сорадым.
— Икесе дә утыралар, кеше талаган өчен.
— Ә синекеләр ничек? Исән-саулармы?
— Аллага шөкер! — дип елмайды ул.— Яңа ел алдыннан гына миңа кече киленем онык бүләк итте.

# Дустым Газинур

Октябрь аеның ял көне иртәсе. Вакыт-вакыт яңгыр сибәләп ала. Күптән түгел генә шаулап торган пляж тынып калган. Яр буендагы ятып ял итәр өчен җайланган ятаклар бушап калды, җыелма киенүчишенү корылмаларын сүтеп, җыеп алдылар. Коену сезоны үтү белән, курортлы шәһәрдән ял итүче яшьләр кинәт юкка чыктылар. Алар урынына аллеяларда һәм яр буенда олы яшьтәгеләр күренә башлады, боларга көньяк кояшы мөһим түгел, буш вакытта льготалы путевкалар белән азрак сәламәтлекләрен ныгыту теләге көчле аларда.

Лазаревски — Сочи автобусына кузгалып китәргә әле ярты сәгатьләп вакыт бар. Автобус йөртүче йомыш белән диспетчерлык бинасына кереп китте. Минем белән янәшә урын нишләптер буш иде.

— Кемдер йоклап калган бугай,— дидем мин ярым шаяртып. Минем сүзләремә җавап бирүче булмады.

Менә шифаханә ягыннан өстенә куе зәңгәр плащ, башына хәзер инде бер кеше дә кими торган модадан чыккан яшел фетр эшләпә кигән бер ир-ат автобуска табан юнәлде. Сул як ягына сизелерлек аксаклый иде. Бер кулына таяк, ә икенчесенә яшь әстерхан чикләвеге үсентесе тоткан.

— Бакчагамы? Дачагамы? — дип тартынып тормыйча сорап куйдым.— Әйе, әстерхан чикләвеге утырту өчен нәкъ вакыты...

Юлдашым өстендәге плащын һәм эшләпәсен салып куйды. Аның чәчләре әле яңа гына юынып чыккандай юеш иде. Кыяфәтенә караганда аңа 70 — 75 яшьләр биреп була.

— Минем бакчаның кайда икәнен әйтимме? — дип елмаеп куйды яңа танышым.— Татарстанда, Казан тирәсендә, Идел буенда. Лазаревскига мин дәваланырга гына килдем. Хәрби комиссариатка рәхмәт инде, сугыш ветераны булгач, бушлай путевка бирделәр. Ә моны базардан сатып алдым әле. Дустым янына Сочига барам, аңа илтәм. Хәер, башта танышыйк әле, минем исемем Әнвәр.

Чыннан да, дөнья тыгыз ул, якташларны кайда гына очратмыйсың. Мин дә тумышым белән Татарстаннан дигәч, без бер-беребезне гомер буена эзләп табышкан кешеләрдәй шатланыштык. Сораулар ява башлады.

— Нәрсә, сезнең дустыгыз бу үсентене Сочида сатып ала алмыймыни? Әллә бүләк-күчтәнәч итеп алдыгызмы? — дип кызыксындым мин.

— Әйе, бүләк-күчтәнәч итеп,— диде Әнвәр әфәнде, авыр сулагандай итеп,— и-их, озын тарихлы вакыйга бу. Күрәсеңме? — дип, сул аягына бармагы белән төртеп күрсәтте һәм өстәп куйды: — Кырык өченче елда Днепр аръягында, Кременчуг тирәсендә калдырдым... Безнең өчен шунда сугыш тәмамланды. Безнең өчен дип, минем һәм дустым Газинур Хуҗиәхмәтов өчен диюем... Ул Ульян ягыннан иде. Урта мәктәпне тәмамлагач, Мәскәү авыл хуҗалыгы институтына укырга кергән булган. Сугышның беренче көнендә үк үз теләге белән фронтка киткән. Минометлар взводы командиры иде.

Максатыбыз бер — Днепрны кичеп чыгу. Сентябрьнең караңгы бер төнендә Кременчугтан ун-унике чакрым ераклыктагы урында алты көймәгә төялеп, елганы аркылы чыгарга керештек. Елга уртасына җитәрәк, безнең өскә артиллерия һәм миномет утлары ява башлады. Берничә көймәнең асты-өскә килде.

«Алга, егетләр!» — дип, Газинур әмер бирде һәм беренче булып салкын суга сикерде. Ярга йөзеп чыгу белән, «ура!» кычкырып атакага ташландык, кыска гына вакытта кечкенә бер плацдарм яулап алдык.

Дошман белән каты бәрелешләр тәүлектән артыкка сузылды. Ялан кул белән безне җиңә алмасларына ышанган фашистлар безнең өскә танклар җибәрделәр...

Гаять зур тимер машиналар ажгырып өскә ташландылар, алар артыннан җәяүле гаскәриләр. Взвод командиры боларны зур игътибар белән күзәтте.

«Алдан килгәненә төбәгез, сулга табарак алыгыз, ноль егерме» диде, ниһаять, Газинур. Шунда ук мина очып китте һәм танк артына барып төште. Гитлер пехотасы төрле якка таралды, менә икенче мина, фашистлар танкларын ташлап йөгерәләр. Сыекча тутырылган шешәләр оча башлады. Бер танк, икенче, өченчесе яна, калганнары борылып шылдылар.

Шулвакыт кулын күкрәгенең уң ягына куеп, взвод командиры саргая башлаган үлән өстенә йөзтүбән килеп төште. Исән калган алты кешедән торган взвод белән мин командовать итә башладым.

Икенче тәүлек үтеп барганда, елганың сул ярында безгә ярдәмгә өстәмә көчләр күренде. Каты сугышта мин яраландым, ләкин егетләр нык торды, плацдармны бирмәделәр. Шушы көннән Днепрның сул ярында урнашкан Украина җирләрен азат итү башланды...

Фронт госпитальләрендә аз-маз дәваланып йөри торгач, Сочидагы зур госпитальгә килеп эләктем. Ул вакытта Сочиның барлык хастаханәләре һәм ял йортлары барысы да диярлек фронт өчен эшли иделәр. Палатада Газинурны очраткач исем китте. Караваты янына килдем. Ул йоклый иде.

— Газинур! Бу мин — Әнвәр Хәлиуллин,— дип шыпырт кына эндәштем.

Ул әкрен генә күзләрен ачты һәм сынаулы караш белән миңа озак кына карап торды да барлык тавышына кычкырып җибәрде:

— Әнвәр! Җаным! — дип, миңа таба бар гәүдәсе белән ыргылгандай итте. Ләкин шунда ук кире караватка ауды һәм башын чайкый-чайкый елап җибәрде.

— Ярар, Газинур,— дидем мин, тамагыма тыгылган төенне йотарга тырышып.— Тиздән фашистлар капкынга эләгәчәк...

Озак түзеп торырлык рәтем калмады, үзем дә сулкылдап елап җибәрдем.

Соңыннан Газинур сораштыра башлады.

— Ничек анда хәлләр, уң як ярда?

— Ярыйсы, фашистка бирешмәдек, саклап калдык. Хәзер безнекеләр Киевка керү юлларында сугышалар.

...Газинур көн үткән саен азрак сөйләшә, күз алдында сүнә башлады. Миннән үзем турында күбрәк сөйләвемне үтенде. Көн саен иртән институтта бергә укыган кызы Земфирага хат яздырды. Газинурның әнисе үлгән, ә әтисе сугышта иде.

*«Кадерле Земфира!* — дип хат яза башладык.— *Әлегә үзем яза алмыйм. Бу хатны минем иң якын дустым...»* — Хәзергә җитәр,— дип авыр сулап, күзләрен йомды Газинур.— Бүген нигәдер начаррак сизәм үземне, хатны иртәгә язып бетерербез.

Ул көне буена күзләрен ачмады, ә иртәгесен җан бирде. Мин Земфирага дип язылa башлаган хатны кулыма алып озак еладым.

Газинурны, барлык шартларын китереп, Сочи каберлегенә җирләделәр. Берничә атнадан мин терелеп җиттем. Бер аяксыз калдым калуын. «Инде кая барырга?» — дип, госпитальдән чыккач, уйланып басып тордым.

Казанда ерак кына туганнарым бар иде, куян шулпасының шулпасы дип, шуларга юл тоттым. Эзләп таптым. Эшкә урнаштым. Соңыннан гаилә корып җибәрдем...

Без утырган «Икарус» автобусы Сочига якынлашып килә. Мамай тавына күтәрелдек. Безнең алда әкияттәй матур курортлар шәһәре. Яңгыр туктады. Кояш чыкты.

— Менә шулай, дустым, туганкаем,— диде Әнвәр әфәнде.— Дустым Газинур янына Сочига килеп тә җиттем бугай. Бу агачны аның баш очына утыртам. Кыска гына гомерле дуслыгыбызның якты бер истәлеге булып үссен.

## Васыять

Туган йорт... Аңа багышлап күпме җырлар язылган һәм җырланган. Бу кыска гына сүзләрдә олы мәгънә ята. Ул төрле яшьләрдәге кешеләр өчен дә бик кадерле, аеруча хатын-кыз шушы сүзләрне телгә алу белән авыз эченнән туган җиргә багышланган, җанга якын җырларны көйләп йөри, бала чакта чәчләрен үргән йомшак куллы әниләрен, әбиләрен, туган йортларын күз алдына китерә.

Туган йорт... Ул шыксыз, иләмсез зур казармаларда хәрби хезмәтне тәмамлап туган якка тизрәк әйләнеп кайтырга өметләнеп яткан солдатларның төшләренә кереп йөдәтә, сагыну утын тагын да дөрләтеп җибәрә. Ниндидер сәбәпләр аркасында туган җирләрен калдырып, чит илләргә чыгып китеп, шунда гомер кичергән ир урталарын да уратып узмый ул туган йортка кагылган татлы хисләр. Ул хисләр бигрәк тә олы буын кешеләренә хас.

Туган йорт ул авыл кешесе өчен элек заманнарда бала тудыру йорты, балалар бакчасы, пионерлар лагеры һәм хезмәт дәресләре остаханәсе ролен дә уйнаган. Ә бу «әкияти йорт»ның тәрбиячеләре дә, укытучылары да безнең әти-әниләребез, әби-бабайларыбыз, апа-абыйларыбыз булдылар.

Туган йорт төшенчәсе адәм баласына: татармы ул, русмы, башкорт яки удмуртмы — изге дога кебек якын ул. Аның төшенчәсен гади сүз белән генә аңлатып та, сөйләп тә булмый, ул зур мәгънәгә ия. Туган йортны «туган нигез», «туган туфрак», «изге йорт» төшенчәләре белән атап була. Төп йорт ул — әби-бабайлар йорты.

Бик күп татар гаиләләрендә бүген дә «төп йорт»та төпчек малай кала. Аннары шушы кече малайның улы кала һәм шулай кабатланып бара. Бу кавем-кабилә тарихының язылмаган законнары.

Барлык гасырларда да, иң авыр ачлык һәм дәһшәтле сугыш елларында да татарларда «төп йорт»ка аерым караш яшәгән. Шушы йортка шатлыклы һәм кайгылы минутларда барлык туганнар җыела, үзара фикер алышып, мөһим мәсьәләләр чишелә.

Нинди дә булса сәбәпләр белән туган нигезне югалту — нәселне дәвам иттерүчеләр өчен һәлакәткә тиң вакыйга ул.

* * *

Кырык беренче елның кояшлы якты июнь көнен Мәгъсүм томан аша гына хәтерли. Аңлашыла да, ул вакытта аңа барлыгы дүрт яшь ярым гына иде. Ләкин төп йортка җыелган әтисе, аның ике туган абые һәм ике апасы йөзләре аның хәтеренә мәңгегә уелып калган. Ир-ат туганнар фашист илбасарлары белән сугышка китәргә җыенганнар. Саубуллашу сүзләре һәм күз яшьләреннән соң алар аягүрә басып Мәгъсүмне уратып алдылар һәм, әле генә чәче алынган такыр башыннан сөеп:

— Мәгъсүм, син төп йортта хуҗа булып каласың, кара аны, яхшы сакла,— диделәр.

Мәгъсүм озак вакытлар бу сүзнең мәгънәсенә төшенә алмый йөрде. Менә кырык бишенче елны сугыш бетеп, исән-аман фронттан кайткан әтисе һәм аның олы абыйсы төп йортта, самовар артында үзләренең сугыш кырында һәлак булган уртанчы энеләре, туганнары, авылдашлары турында әрнеп сөйләштеләр.

Теге сүзләрнең серенә Мәгъсүм кырык сигезенче, Сталин-Берия машинасының тагын барлык көченә эшли, исән-аман сугыштан кайткан фронтовикларны лагерьларга озата башлагач кына төшенә башлады бугай.

* * *

Шушы фаҗигале елларда Татарстан авыллары буйлап төрле җирдән күпсанлы вербовкалаучылар (эшкә яллаучылар) йөри иде. Татарлар аларны, көлеп, «гербовщиклар» дип атады. Алар авыл халкын Мәскәү, Урал, Себер төзелешләренә, Кизел, Донбасс, Кузбасс шахталарына эшкә кыстадылар.

Хәзергә кадәр, инде ярты гасыр вакыт үтүгә карамастан, Мәгъсүм колагында шушы хәерчелектән качып шахталарга, адәм баласы түзмәслек авыр эшләргә китеп баручы авылдашларының:

Китә казлар Донбасска,
Мин дә уйлап торам әле
Шул казлардан калмаска...—

дип җырлаганнары яңгырап тора.

Ә колхозда хәерчелек белән бергә бригадир ише вак-төяк түрәләрдән һич күз ачарлык түгел: тоташ кыерсыту, рәнҗетү, күз яше...

Мәгъсүмнең әнисе дә, бик озак уйланганнан соң, колхоз идарәсе исеменә күрше Удмуртия Республикасының Сарапул шәһәренә китәргә теләген белдереп, гариза язды. Ул елларда колхозчыларның хәле крепостной крестьяннныкыннан да мөшкелрәк иде. Авыл халкына паспорт бирелмәде. Ни гаҗәп, Мәгъсүмнәр гаиләсенә колхоздан китәргә рөхсәт иттеләр.

Соңыннан беленде, колхоз рәисе рөхсәтне юри генә биргән икән. «Кая барсын соң ул дүрт бала белән, чит-ят җирдә кемгә хаҗәт алар»,— дип уйлаган.

Теләкәй авылыннан өйне сатып алучы да табылды. Бәһасе турында килешкәч, булачак өй хуҗасы балта белән ниргәгә суккалап алгач, рим цифрлары белән тамгалап та чыкты. Тук-тук, барысы да әзер. Әмма көтмәгәндә ерак Колыма төрмәсеннән Мәгъсүмнең әтисеннән хат килеп төште: *«Күчеп китсәгез китегез, ләкин өйне сатәргә бирмәгез. Онытмагыз! Ул безнең төп йорт, ата-бабалар нигезе».*

Хатны укыган Мәгъсүмнең әнисе бер мәлгә уйланып калды һәм йорт өчен алдан бирелгән бер өлеш акчаны хуҗасына кире кайтарды да, өйгә, фатирга дип, бер укытучыны кертеп, Сарапулга китеп барды.

Шулай итеп, хуҗалары үзгәрсә дә, бүрәнәдән салынган «төп йорт» тагын үз урынында сакланып калды.

* * *

Шәһәрдә Мәгъсүм производствода эшли алмады. Әүвәл урысча өйрәнде, аннан соң кичке мәктәпкә укырга керде. Авылдагы өйләрен, төп йортны сагынды. Армиядән соң кичке техникумны тәмамлады, соңыннан институтны. Бер промышленность предприятиесенә җитәкче итеп сайланды. Сирәк-мирәк кенә булса да туган авылына да кайткалап торды. Туган нигездә читтән кайткан авылдашлары яши иде.

Ул елларда Мәгъсүмнең барлык яшьтәшләре дә кайсы кая китеп беткән иде инде.

Татарстан җирендә КамАЗ төзелеше киң колач җәйгәч, Мәгъсүм, ике дә уйламыйча, Яр Чаллыга китте, чөнки ул туган авылдан йөз чакрым ераклыкта гына урнашкан. Мәгъсүм завод комплексының бер төзелеш трестында партком секретаре булып эшләде. Шулчак Яр Чаллыга аның янына авылдашы

Гилимхан килеп төште. Яшьтәш, мәктәп дусты. Армиядә хезмәт иткәннән соң, Кизел шәһәренә шахтага эшкә киткән иде ул.

— Шахтерлар шәһәрчегендә үзебезгә дә, балаларга да бернинди перспектива юк. Мине тизрәк фатир ала алырлык бер эшкә урнаштыр, зинһар,— диде дусты Мәгъсүмгә.

Кешеләргә ярдәмчел, йомшак күңелле Мәгъсүм үзенең классташын мәскәүлеләр эшләгән бер төзү идарәсенә стропальщик итеп урнаштырды. Ул эшләячәк төзелеш идарәсе Яңа шәһәрдә йортлар сала иде. Мәгъсүм «Главмосстрой» идарәсе җитәкчеләренең күбесен бик якыннан белә, дустанә мөнәсәбәттә иде. Тиздән Гилимхан, дусты Мәгъсүм ярдәме белән, өч бүлмәле өр-яңа фатир алды.

Гигант КамАЗ заводының беренче этабын төгәлләгәч, Мәгъсүмне башка күп кенә җитәкчеләр һәм белгечләр белән бергә яңа гигант — Волгодонскида төзеләчәк «Атоммаш»ка җибәрделәр.

Ерак юлга чыгар алдыннан Мәгъсүм туган авылына кайтып килергә булды. Төп йорт, карт бабайга охшап, бер якка авышкан, тузып беткән. Мәгъсүм өчен төп йорт белән саубуллашу бик кыен булды. Әйтергә кирәк, бу соңгы мәртәбә күрешү һәм чын-чынлап мәңгегә саубуллашу иде.

* * *

Җылы яклардагы бу яңа төзелеш Мәгъсүмне тулаем үзенә суырып алды. Бик озак ул туган җире — Татарстанына кайта алмады. Шулай итеп, егерме ел вакыт үтеп тә киткән.

Әмма еллар үткән саен, кендек каны тамган җир үзенә ныграк тарта, сагындыра. Мәгъсүм дә туган як дип тәмам өзгәләнде, төп йорт төннәрен аның төшләренә кереп йөдәтте.

Менә бер сәбәп килеп чыгып, аны яңадан Яр Чаллыга эшкә чакырып алдылар. Шәһәрдә эшләрен азмаз җайлаштырып, үзенең Шәбез елгасы ярына урнашкан туган авылына юл тотты. Бу юлы аны билгесез бер хис биләде, нишләптер бер сәбәпсезгә күңеле шомланды, йөрәге еш-еш тибәргә тотынды. Әйе, бу халәт юкка гына булмаган икән. Туган авылына якынлаша башлагач та, Мәгъсүм өйләренең урынында юклыгын күреп хәйран калды.

Йорт урынына якынрак килгәч, ул кулына балта тотып хуҗаларча нидер эшләп йөргән кешене күрде. Чәче агарган һәм шактый олыгайган бу кешедә Мәгъсүм үзенең авылдашы Гилимханның йөз чалымнарын таныды. Бу бит ул, аның классташы, Мәгъсүм Яр Чаллыда эшкә урнаштырып, фатир алышып биргән Гилимхан! Әйе, Мәгъсүмнәрнең төп йорты ата-бабалары нигезенә аның классташы тактадан дача йорты салып куйган. Йорт тирәсенә мул итеп бәрәңге утыртылган.

Мәгъсүм сүзсез катып калды. Бик озак әйтер сүзен таба алмый торды. Озын тынлыктан соң ул, көчкә телгә килеп:

— Ничек соң син болай? Әнә юл аркылы гына үзегезнең төп йортыгызның урыны буш тора...

— Монда булса ни булган,— диде Гилимхан, еш-еш итеп күзләрен йомгалап.— Сезнең иске өегезне җимереп ташладым. Сезнең бакча Шәбез елгасына терәлеп торгангамы, бик тә уңдырышлы. Менә шулай, кем өлгерми, шул соңга кала,— дип, авызын чалшайтып көлеп куйды: — Теләсәң, әнә безнең урынны ал.

— Ничек соң инде, бу бит безнең йөзләрчә еллар буена буыннан-буынга күчеп килгән туган җиребез, нигезебез урыны. Әнә тегендә — сезнеке! Ничек син шуны аңламыйсың, Гилимхан?

— Куй син, кемгә кирәк бүген синең бу киң күңеллелегең. Төп йорт, туган җир, имеш,— дип, агач кайрысын юна башлады.

...Әйе, төп йорт дигән изгеләрдән-изге төшенчә күңеле каткан, вөҗдансыз, хиссез, тамырларын югалткан, нигезен саткан кешеләр өчен — буш сүз ул.

...Еш кына Мәгъсүмнең күз алдына әтисе, әнисе, өстәл тирәсенә тезелешеп утырган энеләре һәм сеңелләре килә. Шул вакытта колагында кайтаваз булып әкрен генә: «Төп йортны сакла! Сак-ла-а-а!» — дигән тавыш яңгырый. Гомер үтеп чәчләренә чал төшкән Мәгъсүм мәңгелек дөньяга киткән бабалары, ата-анасы, туганнары, вөҗданы каршында үзен зур гаепле санады. Нишләсен, үти алмады шул аларның васыятьләрен.

## Ишан хәзрәт наратлыгы

Кайчандыр гөрләп яшәгән туган авылым Түбән Карачка кайтып киләм. Элеккеге күршеләребезнең хәлле генә хуҗалыклары таркалып, утырткан агачлары гына торып калган. Авылыбызның икенче башында — көнчыгыш якта күрше Калмаш авылына ярты чакрым ераклыкта, Шәбез елгасы куенына сыенып, Ишан хәзрәт зираты урнашкан. Аның тирә-ягында йөзьяшәр наратлар үсеп утыра. Шуларны күргән саен, Фәрхикамал әбинең сөйләгәннәре искә төшә. XIX гасыр азагында авылыбыз бик зур булган. Җиде урам-мәхәлләсендә җиде мәчет манарасы балкыган.

Бала чакта күп кенә вакыйгаларга һәм сүзләргә әллә ни игътибар бирмисең, әмма алар никтер хәтергә сеңеп кала. Ишан хәзрәт зираты янындагы басуны сөргәннән соң, без, авыл малайлары, әллә нинди матур сурәтләр төшерелгән керәч ватыклары таба идек тә аларны яшьтәш кызларга бүләк итә идек. Аларның сөенүләре! Тутыгып беткән эш кораллары һәм керәч ватыкларын Шәбезнең аръягында да таба идек.

Безнең табылдык «байлыкларыбызны» күргәч, Фәрхикамал әби карт кешеләргә генә хас бер горурлык белән сөйли башлый:

— Менә мин сезгә нәрсә дип сөйли идем? Элек Шәбезнең аръягында да урамнар бар иде. Ә безнең урам Ишан хәзрәт зиратына ук терәлгән иде.

Шушы урында бераз гына туктап тора. Йөзен кайгы-хәсрәт пәрдәсе каплап ала. Күзләренә кадәр сүрелә.

— Әй-йе, авылыбыз бик зур иде. Таралып бетте шул. Күпләр, җир өчен дип, башкорт якларына күчкәннәр. Агыйделнең теге ягындагы Ногай авылына, Илеш районының Яркәй һәм Исәнбәй авылларына карачлылар нигез салган. Күрше Татар Суксуына да иң башлап безнекеләр барып төпләнгәннәр. Күпне беләм мин. Шәфыйк бабагыз күп әйберләр турында сөйли иде, мәрхүм.

Без туганда бабабыз юк иде инде. Аның турында, нәсел-нәсәбебез, аларның шөгыльләре, холык-фигыльләре турында Фәрхикамал әбиебездән ишетеп үстек.

Әбиебез тумышы белән күрше Татар Суксуыннан. Туганнары тәрбиясендә үскән ятимә кызны, унҗидесе тулгач, Шәфыйк бабайга — кырык яшьлек тол иргә кияүгә биргәннәр. Бабайның беренче хатыны ниндидер авырудан дөнья куйган. Әбекәй килен булып төшкәндә, бабайның олы кызы белән бер яшьтә булган. Бу никахтан тагын дүрт бала туган. Әбиебез үзе дә яшьли тол калган. Бабайны ул һәрвакыт иң җылы хисләр һәм зур хөрмәт белән искә ала.

Бабай тирә-якта дан тоткан тимерчеләр нәселеннән булган. Кызганычка каршы, мин әти ягыннан да, әни ягыннан да тулы нәсел шәҗәрәбезне белмим. Әбекәй сөйләве буенча, безнең тимерчеләр нәселенең башында Хафиз бабай торган. Аннан Газиз бабай, аның улы Шәфыйк бабай, аннан соң Долмаган Шәфыйк улы, ә мин — Долмаган улы булам. Менә шушы безнең нәсел агачы.

Фәрхикамал әби сөйләве буенча, Шәфыйк бабай тимерчелек эшендә остазларын — әтисе белән бабасын да уздырып җибәрә. Аның үз тимерчелеге булган. Тимер чүкетергә дип Минзәләдән үк Шәфыйк бабай янына килгәннәр. Җәй көне алачык каршына бихисап булып ат арбалары тезелгән. Ат дагалауда бабайга тиң оста тирә-якта булмаган. Гомумән, ул чорда ат дагалаучы иң дәрәҗәле кеше саналган. Чөнки дагасы шәп ат җегәрле дә булган, хуҗаның да эше гөрләп барган.

Авыл җирендә шулай бит ул: әгәр кеше бер эшкә оста икән, димәк, ул башка эшне дә җентекләп, җиренә җиткереп башкара. Безнең бабай әле умарта да тоткан. Аның татлы мирасыннан безгә — төпчек малаеннан туган оныкларга да өлеш чыкты. Бабабызның умарта өйләре хәзер күреп күнеккән матур өйләр түгел иде, әлбәттә. Умарта дигәннәре тимер кыршау белән уратып алынган юан бүрәнәләр иде.

Ул бүрәнәләрнең эче куыш була. Кеше гәүдәсеннән дә олырак шундый дүрт бүрәнәбез бар иде.

Көз җитеп, беренче кыраулар төшкәнче, авыл ир-атлары, өмә итеп, бүрәнәләрне бакчадан өй базына кертәләр иде. Шул бүрәнәләрне тартканда, мин колагымны куеп тыңларга ярата идем: эчтә умарта кортлары гөж килә! Алар үзләренең бакчадан айга сәяхәт ясаганнарын башларына да китермиләр.

Ирләр бүрәнәләрне базга бастырып, бал кортлары өчен махсус ясалган тишекләрне ачып куялар. Ярдәмнәре өчен рәхмәтләр әйтеп, әбекәй ирләрне мич өстендә «җырлап» утырган әче бал белән сыйлый.

Кышкы суыкларда да умарта оясындагы тормыш туктамый. Базга бәрәңге, кишер алырга гел мин төшә идем. Төшкән саен бүрәнәләргә колагымны куеп, рәхәтләнеп, бал кортларының гөжелдәвен тыңлыйм.

Сугыш чорында да, сугыштан соң да авылда бер безнең генә умартабыз бар иде. Ә умарталыкларның шундый үзенчәлекле булулары борын заманнардан ук килгән, мөгаен. Башкорт ягы халкы гомергомергә Көнбатыш Урал тауларындагы урман һәм агачлыкларда кыргый умарталыклар үрчетеп, бал алганнар.

Илле икенче елның декабрендә безнең гаилә, туган җиргә тоташкан меңьеллык тамырларын кисеп, Удмуртиянең элек купецлары белән дан тоткан Сарапул шәһәренә күченеп китәргә мәҗбүр булды. Шәфыйк бабайдан ук калган туган нигезебездән, газиз йортыбыздан аерылу, авылдагы иң сөтле сыер саналган мүкләк сыерны чит кешеләр кулына калдыру бик авыр булды. Умарталыклар белән хушлашып йөрүем әле дә хәтеремдә. Мин, бүрәнәләрне кочаклап, соңгы тапкыр колагымны куйдым. Тик нигәдер бал кортлары элеккечә матур итеп гүләмиләр. Алар, безгә үпкәләгән шикелле, ниндидер моңсу көй көйлиләр иде. Гүя алар безне хыянәттә гаеплиләр! Тамак төбенә төер утырды, күзләрем яшьләнде. Түзмәдем, елап җибәрдем.

Безнең нәсел үзенчәлекле шәхесләргә бай булган. Мәсәлән, бабабызның әтисе Газиз бабай (изге җаны җәннәттә булсын) тимер сугу остасы булуы өстенә, бик үзсүзле холкы белән дә аерылып торган. Шуның өчен авылда аңа Сеңер Газиз дигән кушамат такканнар. Күпсанлы туган-тумача арасында бе-

рәр үзсүзле кеше булса, без дә аның исемен бик тиз генә Сеңер Газиз дип үзгәртәбез. (Газиз бабаебызның рухы бу чагыштыру өчен рәнҗемәсен.)

Ишан хәзрәт зираты турында сүз чыкса, мин әбекәйне мең сорау белән аптырата идем:

— Шундый матур урынга җирләнгән Ишан хәзрәт кем соң ул?

Әбекәй җавап эзләгәндәй бик озак кына тирә-якны күзәтә, соңыннан, һавага карап, серле генә әйтеп куя:

— Изге кеше. Бик изге кеше.

— Мулламы әллә?

Әбекәй башын чайкый. Чәч толымнарына үргән патша акчаларыннан ясалган көмеш тәңкәләре зыңгылдап китә.

— Юк, улым. Мулладан да зуррак. Наратларны исә ул үлгәч, аның кабере өстенә утыртканнар. Алар хәзер бик матур бакча шикелле үстеләр.

Коммунистлар хакимияте тарафыннан башта гарәп, аннан латин язуыннан ваз кичәргә мәҗбүр булган әбиебез милләт һәм диннең тарихын ничек белсен инде? Ул әби-бабаларыннан ишеткәннәрне генә түкми-чәчми безгә сөйли иде.

Ә без, сугыш һәм сугыштан соңгы ач балалар, яшь ленинчылар, ишан хәзрәтне түгел, гади мулланы да күрмичә үстек. Безне мәчет стеналарына эленгән Ленин һәм Сталин портретлары тәрбияләде. Ул заманда мәчетләрнең күбесе мәктәп һәм клубларга әйләнгән иде.

Әйе, балачагыбыз мәчетләрдә үтте. Тик без намаз, Коръән сүрәләре укыр урында «даһи» Сталин һәм «бөек» Ленинга мәдхия җырладык.

Беренче сыйныфта мин Такталачык авылында укыдым. Мәктәп Әҗмәт авылына чыгу юлындагы элеккеге мәчеттә урнашкан иде. Манарасы да исән иде. Икенче һәм дүртенче сыйныфны Түбән Карачта укыдым. Монда да мәктәп дигәнебез элеккеге мәчет иде. Тик манарасыз мәчет. Аны сугышка кадәр үк кисеп төшергәннәр дә мәчеттә башлангыч мәктәп ачканнар. Күрше Югары Карач мәчетенең дә язмышы нәкъ шундый булган. Авыл советы урнашкан Яңа Кормаш мәчетеннән клуб ясадылар. Манарасы да исән иде. Мин — шушы төбәктәге бердәнбер гармунчы — клубта тальян сыздырам, ә Кормаш яшьләре рәхәтләнеп бииләр иде.

Бездән бер чакрым ераклыктагы Калмаш авылында да манаралы мәчеттән мәктәп ясадылар. Ул мәктәптә безнең туганыбыз — Рәхимова апа бик озак еллар укытты. Нигәдер аңа бөтен кеше шулай фамилиясе белән генә дәшә иде.

Карачтан өч чакрым ерактарак, төньякка таба Татар Суксуы дигән зур авыл бар. Аның клубы да элеккеге мәчет иде. Ул клубта мин тальянымда күпме көйләр уйнадым, күпме кичләрне шунда үткәрдек!

Дистәләрчә еллар үтте. Тик мин һаман бер сорауга җавап таба алмыйм: мәчетләрдә Ленин һәм Сталин турында җырлап, тузан туздырып биеп үскән буыннан юньле кешеләр чыктымы? Милләтебезнең киләчәген дәвам итәргә лаекмы алар? Җавап таба алмыйм...

Сугышның соңгы елында без Такталачык авылында яшәдек. Әтиебез анда мал врачы булып эшләде. Такталачыкка барышлый Түбән Гәрәй, Чалманарат авыллары аша үтәбез. Ул авылларда да нәкъ Ишан хәзрәт зиратындагы шикелле агачлыклар бар иде. Шуларны күреп, бетмәс-төкәнмәс сорауларым белән әбекәемнең башын әз авырттырмадым мин.

— Ишан хәзрәт кебек изгеләр күп булганмыни? Чалманаратта да, Түбән Гәрәйдә дә шундый агачлыклар бар...

Әбекәй уйланып кына җавап бирер иде:

— Булгандыр инде... Болай, изгеләр күп булырга тиеш түгел дә ул...

Безнең авыл халкы язылмаган бер кагыйдәгә буйсынып яшәде: Ишан хәзрәт зиратын һәм наратлыкны берәү дә таптамады. Бу җирне авылдашларым изге итеп саклады. Җәй көне монда җиләк ишелеп уңа иде, әмма берәү дә аны өзеп авызына капмады. Көчле җилдән яки авыр кардан сынган нарат ботакларын да ягарга була, әмма берәү дә аларны күтәреп кайтмады. Алай гынамы соң, самовар кайнату өчен нарат күркәләрен дә җыймадык. Изге җиргә изге караш иде.

Мин кечкенәдән үк кызыксынучан булып үстем. Әллә нинди сихри көчләр мине шушы урынга тартып китерә иде. Өлкәннәр сизмәсен яки әбекәй, күреп, артымны кычыткан белән ярмасын өчен (бу юләр гадәтен бик ярата иде ул), мин, кармак тотып, бакча артлап кына Шәбез елгасына төшәм дә, кармагымны таллыкка яшереп, шомарып беткән партизан шикелле тирә-якка карана-карана, Ишан хәзрәт наратлыгына таба сызам. Кайвакыт минем партизанлыгымны саескан боза. Каяндыр килеп чыга да тотына баш өстендә әйләнә-тулгана кычкырырга! Агачлыкка барып җиткәнче шулай кычкыра. Әбекәйгә ялагайланып, шулай кылана дияр идең, әбекәй ишетми дә аны. Елга ярыннан әкрен генә наратлыкка менәм. Бу урын — калкулык. Әнә күрше Калмаш авылы уч төбендәге шикелле күренә. Этләренең өрүе, әтәчләренең кычкыруы (ничек кенә кычкырсалар да, безнең авыл әтәчләрен уздыра алмыйлар), халкының сөйләшүе ишетелеп тора. Наратлык авызында тораташтай катып калам. Монда үлән әллә ни куе

да, биек тә түгел. Нарат кәүсәләре зыңлап китә. Җир астыннан ыңгырашкан авазлар ишетелгән шикелле. Агачлар шыгырдап куя. Тәнгә суык йөгерә. Куркам да куркуын, әмма кызыксынуым көчлерәк.

Агачлыкта уналты нарат үсә иде шикелле. Бәлки, унбиш булгандыр. Кызганычка каршы, Галиҗәнап Вакыт баш миендәге сызыкларны тигезли шул! Колачка сыймастай юан, зур наратлар иде алар. Кәүсәләрен каплаган кайрылары сап-сары гәрәбә шикелле. Карандаш кебек төп-төз булып, биек булып үскәннәр. Агачның нәкъ очындагы ылыслары наратларны ыспай чалма ураган картка охшатканнар.

Кояш төшкән урыннарда табигатьнең иң зур шифасы — нарат сагызы күз яшьләредәй җемелди. Башны күтәреп карасаң, кеше йодрыгы кадәр нарат күркәләре күренә. Алар җирдә дә бихисап. Ара-тирә сынган ботаклар аунап ята.

Наратлыкның төньягында кеше биеклегендәге соры таш тора. Мин аңа якынрак киләм. Каралып беткән, җиргә якын өлешен мүк сарган. Ташның дүрт ягына да гарәп язуы белән нидер язылган.

Әбекәйнең кычытканыннан саклану инстинкты кайтырга вакыт җиткәнлеген искә төшерде. Килгән юлымнан кирегә борылам. Нарат күркәләре аягымны авырттыралар. Наратлыктан чыгуымны көтеп торган саескан янәдән кычкырырга тотынды. Таллыкка җиткәч, кармагымны иңемә салып, балыкчы кыяфәте чыгарып, бакча аша әбекәй янына кайтып кердем.

Әбиемнең, тоткан балыгың кая, диюенә, бүген балык чиртми, дип котылдым. Әмма бу көнне әбекәйнең «экзекуция»сеннән качып булмады. Чиртмәгән балык турында әллә ни төпченмичә, әбекәй бакчага чүп утарга кереп китте. Мин өй- алдындагы шкафтан нидер эзләгәндә, эткәйнең бүре атарга әзерләп куйган патронына юлыктым. Мылтык та шунда гына — кадакта эленеп тора. Аны күтәреп, ишегалдына чыктым. Күршебез Кендек әбинең коймасына карап бастым. Мылтыкны ачып, бүрегә дигән патронны корып куйдым. Мылтыкны төзәп, курокка бастым. Шарт иткән тавыш ишетелде, иңемә кинәт баскан авырлыкка түзә алмыйча җиргә егылдым. Күземне ачсам, мылтык янымда ята, көпшәсеннән төтен чыга. Ул да булмады, Кендек әбинең эте чинап җибәрде. Бераздан тынычланды тагын. Бакчадан әбекәй атылып чыкты. Кулында бер уч кычыткан. Эләкте дә соң миңа! Әбекәй мине — булачак хәрби һәм сәяси әзерлек отличнигын жәлләп тормады, рәхәтләнеп кычыткан белән «сыйлады». Бу көннән соң озак вакыт авыртынып, кычынып йөрдем. Искә төшсә, хәзер дә йөрәгем «жу» итә, теге төш кычытып куя.

Берәр сәгатьтән әбекәй тынычланды. Су ташый торган чиләкләремне алып минем якка атты. Алар белән мин Кендек әбинең коесыннан су ташый торган идем.

— Бар, су алып кайт! Ашарга пешерергә кирәк. Озакламый эти-әниең дә кайтыр!

Чиләкләремне шалтор-шолтыр китереп күршеләргә кердем дә кое чылбырын тарта башладым. Ул да булмады, этләре арттан килеп болай да авырткан урыннан тешләп алмасынмы!

Чылбыр кулдан ычкынды, чиләкләр җиргә тәгәрәде, үзем күршеләрдән чыгып чаптым.

Акырып елаган тавышка йөгереп чыккан әбекәй, әлеге вакыйгага бәя биреп, сүзне йомгаклап куйды:

— Мылтык белән шаяруыңа үч итеп тешләгән ул сине! Эт бик акыллы җан иясе бит.

Мылтык белән уйнауның ике нәтиҗәсе булды: берсе — яхшы, икенчесе — начар. Беренчедән, мине этләре тешли дип, күршеләргә суга җибәрми башладылар. Икенчедән, шуннан соң мин этләрдән курка башладым. Хәзер дә эт күрсәм, котым алына. Менә шундый психологик барьер булды ул. Беренче уңышсыз тәҗрибәм аркасында утлы коралга мәхәббәтем гомергә сүрелде.

Тагын шунысы истә калган: әбекәй, кырыс булса да, сатлык җан булмаган. Минем «сугышчан тәҗрибәм» хакында ул этигә дә, әнигә дә сөйләмәде. Кычыткан тәрбиясен җитәрлек дип санаган, күрәсең. Алай гынамы, шул көнне яңадан мылтыкны ачтырып (үзе ача белми) буш патронны чокып алды да, алъяпкыч кесәсенә яшерде. Мылтыкны яхшылап урынына элеп куйды.

Бер-ике көн үтүгә, аралар җайланды. Мин, берни белмәгәнгә салышып, әбекәйдән сорау ала башладым:

— Ишан хәзрәт каберендәге ташта аның исеме һәм ничә яшьтә үлгәнлеге турында язылган, диләр, дөресме шул?

— Әниеңнән сора. Ул укыган кеше, беләдер.

Чыннан да, заманына күрә әни — бик белемле кеше иде. Мулла-абыстайлар нәселеннән булып, мәдрәсә тәмамлаган. Латин язуын да өйрәнгән. 1927 елда гарәпчәдән латинчага, соңрак кириллицага күчкән буын вәкиле.

— Белмим шул, улым,— дип җавап бирде соравыма әни.— Безгә, хатын-кызга, Ишан хәзрәт зиратына керү зур гөнаһ бит.

Озак та үтмәде, мин тагын Ишан хәзрәт зиратына бардым. Таштагы гарәп хәрефләренә карап, озак уйландым. «Кем син, Ишан хәзрәт? Туган авылың малаена сереңне ач әле?»

Таш дәшмәде. Юан наратлар да һәрвакыттагыча әкрен генә шаулаштылар. Турыдан гына кайтырга уйлап, басуга килеп чыктым. Ишан хәзрәт наратлыгы читендәге куш наратны кем һәм кайчан утыртты икән? Аларга сокланып, озак кына карап тордым.

Серлелек, билгесезлек — җанга тынгылык бирми торган хис ул. Теге таштагы язу да миңа шулай тәэсир итте.

Алтынчы-җиденче классларда укыганда, мин, чабаталы яшүсмер, Актаныштагы почтага җәяү йөри идем. Әтиебезнең Колымада утырган чагы. Кара ипине киптереп, шул сохарины әтиебезгә җибәрәбез. Актанышка шул посылкаларны илткәндә, һәрвакыт Ишан хәзрәт наратлыгы кырыеннан үтәргә туры килә иде. Наратлык янына туктап, мәңгелек яшеллеккә сокланам һәм Ишан хәзрәттән ярдәм сорый идем.

Җидене тәмамлауга колхозда эшли башладым. Кышкы суыкларда үгез җигеп, фермадан Ишан хәзрәт наратлыгы янындагы басуга тирес ташый идем. Кышкы суыкларда карга күмелеп утырган наратларның матурлыгын күрсәгез иде бер! Бөек рәссам ясаган картинамыни!

Монда билгесез Ишан хәзрәт зираты икәнлегенә ишарәләп, таш кына моңаеп утыра. Наратлыкта беркайчан да кеше эзе күрмәссең. Агач тирәләрендә үзләреннән матур бизәкләр калдырып, төлке, куяннар гына йөргән.

1952 елның декабрь азагы. Әни белән икәү, чанага хуҗалык әйберләрен һәм азык-төлек төяп, Татар Суксуына таба барабыз. Әкрен генә кышкы кояш байый. Кар алсу төскә кергәндәй тоела. Туган авылыбыз белән хушлашып, читтән бәхет эзләргә китеп баруыбыз. Өр-яңа чабаталарыбыз астында кар шыгырдый. Һәркайсыбыз үз уйларына чумган...

Туган җиребездән аерылу шаһиты булган бу юл күптән юк инде. Колхоз тракторлары сөреп бетерде аны.

Түбән Карач авылы белән Татар Суксуының нәкъ уртасында бер калкулык бар иде. Бездә аны сырт дип йөртteләр. Сыртка менеп җиткәч, әнкәй белән икебез дә артка борылып карадык.

Елга үзәнендә туган авыл җәйрәп ята. Морҗалардан төтен чыга. Шәбез артында имән урманы күренә. Теләкәй авылы янындагы ялгыз карагач та моңаеп калган. Безнең авылның сул ягындагы куш наратлар, яшел чалмаларын безнең якка авыштырып, гүя безнең белән хушлашалар. Тагын да арырак Ишан хәзрәт наратлыгы күренә.

Күңелне сүз белән аңлатып булмый торган моңсулык биләп алды. Тамакка төер килеп тыгылды, тын алу авырлашты. Үксеп елап җибәргәнемне сизми дә калдым. Мине кочаклап әнием дә елый башлады. Туган авылым! Синнән мәңгелеккә дип аерылышабыз. Билгесез Ишан хәзрәт, син дә каласың инде...

Чана бавын тартып, Татар Суксуына таба атладык. Юлыбыз калкулыктан түбәнгә китте. Шатлык һәм кайгыларга чорналган тормышыбыз һәм шул тормышның шаһиты — Ишан хәзрәт наратлыгы калкулык артында калдылар...

Тыела алмыйча елыйм. Нигә елаганымны үзем дә аңламыйм. Моңсулык, сагыну һәм кемгәдер үпкәләү хисләре, бергә җыелып, күз яшьләре булып, ак кар өстенә тамалар.

Бер чакрымнан артык юлны шулай елый-елый бардык. Якын туганыбыз Хәдичә апаның өенә килеп кергәч кенә тынычланып калдык. Ул мәтрүшкәле кайнар чәй эчерде һәм сәндерәгә урын җәеп йокларга яткырды. Таң белән торып, без, әнкәй, Хәдичә апа һәм мин, Көләгеш күле аша елгачылар поселогы Дербешкага, аннан Сарапул шәһәренә юл тоттык. Бу шәһәргә без бәхет эзләп, ә Хәдичә апа — кызы Мохлисәне күрергә дип киттек.

Ул елны кыш буе карга күмелеп утырган туган авылым, куш нарат, ерактагы карагач һәм Ишан хәзрәт наратлыгы күз алдымнан китмәде.

Илле өченче елның язында беренче пароход белән туган авылыма кайтып төштем. Тәүге эш итеп, өебезне карап чыгарга булдым. Анда яшәүче укытучы апа чәй белән сыйлады. Чәе бик тәмле иде, әмма ул ни өчендер тамактан үтмәде. Әкрен генә өй эчен күзәтәм. Һәркайда балачактан җанга якын, кадерле әйберләр. Безне, малайларны, куркытыр өчен чыбык тыгып куя торган түшәм ярыгына кадәр сагындырган... Кендек каным тамган бу йортта, бу нигездә миңа бик авыр иде. Түзмәдем, урамга чыктым. Күзләремне яшь пәрдәсе каплады. Артык хисчән бала идем шул. Күршебез Зөбәрҗәт апа каршыга килә иде.

— Шәһәр егете нишләп елап йөри монда? — дип көлде ул.

— Өебезне кызганам! — дип җавап бирдем. Күз яшьләрем өчен оялып, Шәбез елгасына йөгердем. Шушы елга ярында ел саен сыер абзарыннан тирес ташып, аны калыпка салып таптап, киптереп кышка ягарга тирес әзерләп куя идек. Елга буйлап балачак эзләреннән уйланып бара торгач, Ишан хәзрәт зиратына килеп чыгуымны сизми дә калдым. Җир кипкән инде. Наратлык янында көздән чәчелгән арыш басуы ямь-яшел булып утыра. Күрше Калмаш авылы да янәшәдә генә. «Исәнме, билгесез изге Ишан хәзрәт. Авыр туфрагың җиңел булып, җаның җәннәттә булсын. Амин!»

Нәкъ бала чактагы кебек үк Калмаш авылы этләренең өргәне, капка шыгырдаганы, әтәчләренең кычкырганы һәм авыл халкының сөйләшкәне ишетелә. Елга аръягында имән урманы, арырак Шәбез елгасының борылып-сырылып аккан урынында Югары Карач һәм Яңа Кормаш авыллары күренә. Балачагымның ахирәтләре булган яшел чалмалы куш нарат мине, Сарапулның 16 яшьлек эшчесен, елак малайны, гаепләгән шикелле карап торалар. Каршымда әби-бабайларым җирләнгән зират.

Туган җирем белән икенче тапкыр хушлашуым булды бу. Бу юлы табигатьнең уянып килгән чагы иде. Ике көн кунак булгач, мин «Сөләйман Стальский» пароходына утырып, икмәкле шәһәр — Сара-

пулга киттем. Бу пароход Актанышның ярты халкын, Удмуртиягә алып китеп, ачлыктан коткарып калды.

Ул заманнан соң күп сулар акты. Төрле һөнәрләргә өйрәндем, армиядә хезмәт иттем, бик күп китаплар укыдым. Гаилә корып җибәргәч, хатыныма туган-үскән якларымны күрсәтергә уйлап, тагын авылыма кайттым. Сигез ел үткән, авыл үзгәргән. Өйләр азайган. Куш наратның берсе корып, икенчесе ятим калган. Колхоз басуын сөргәндә, наратның тамырларын актарып ташлаганнар икән. Корыган агач, мөгаен, берәр авылдашымның хуҗалыгын ныгыткандыр. Ишан хәзрәт наратлыгында да агачлар саны кимегән. Хәзрәткә, нидер сөйләгәндәй, унөч нарат шаулап утыра. Кабер өстендәге ташы исән. «Исәнме, билгесез изге Ишан хәзрәт! Авыр туфрагың җиңел булсын, җаның җәннәттә булсын!»

Бу юлы мин авылым белән озакка аерылдым. Дистә еллар буе читтә йөрдем, язмыш мине Русия империясенең бер ягыннан икенче ягына ташлады. Зур төзелешләрдә, җитәкче эшләрдә эшләдем. Озак кына журналист булып, каләм тибрәттем. Туган авылымны өзелеп сагындым, җирседем. Бала чагымда таптаган сукмакларым искә төшеп, җанымны сыкрата иде. Дөньяны танып белергә өйрәткән, очар канат куйган газиз оям — туган авылымны искә алмаган берәр көнем булды микән?! Һәм менә, ниһаять, теләгемә ирештем. Узып баручы егерменче гасырның кояшлы июнь көне. Мин туган авылыма кайтып киләм.

Бу юлы мине нибары дүрт хуҗалыктан торган авыл каршылады. Элеккеге хуҗалыкларның хатирәсе булып калган агачларга карап, Ишан хәзрәт зиратына кадәр сузылган урамыбызны күз алдына китерәм.

Туганнарыма кереп, ял итеп, чәйләп алгач, наратлыкны карап кайтырга уйладым. Миңа тугандашларым балалары да иярәләр. Алар, мин авылдан китеп, дистә еллар үткәч якты дөньяга аваз салган балалар, хәзер барысы да үз гаиләләре белән шәһәрдә яшиләр.

Авыл башындагы ялгыз нарат ахирәтем куш наратның ятиме юкка чыккан. Әйе, егерме биш ел элек минем бу нарат белән елый-елый аерылышуым бәхилләшү булган икән. «Яшен сугып, чәрдәкләп бетерде»,— диделәр энекәшләрем. Ятим агачларның да язмышы ятим кешеләрнекенә охшаган шул. Табигать тә кайчак ятимнәрне кызганмый...

Менә Ишан хәзрәт наратлыгы. Әллә ни үзгәрмәгән кебек. Әмма бу беренче карашка гына шулай икән. Наратлык янында кемдер онытып калдырган трактор тәгәрмәче аунап ята. Арырак — ашлама өеме, тирә-якта сирәк үлән каплаган колхоз басуы.

— Күпьеллык үлән,— дип көлешеп алдылар энекәшләрем.— Бу басуларга күптәннән берни дә чәчмиләр. Списать ителгән, ахры, алар.

Наратлыкка керәм. Унөч агач та исән, баһадирлардай утыралар. Чалмаларының шаулавы мине икенче дөньялыкка алып китә.

Кабер өстенә карасам, ни күрим, таш юкка чыккан. Якынрак килдем. Биек үлән арасында таш кисәкләре аунап ята.

Бу күренештән һушыма килә алмыйча торуымны күргән энеләрем сөйләп бирделәр: Ишан хәзрәт каберен ниндидер бәндәләр (аларны кеше дияргә тел әйләнми), хәзинә эзләп, ике тапкыр актарганнар. Изге урынны курыкмыйча, иркенләп мәсхәрәләгәннәр алар. Авылда аларга каршы чыгарлык егетләр калмаган шул, бар да шәһәргә күченеп беткән. Үз малларын көтүче әбекәйләр күреп калганнар: наратлыктан ике егет чыгып, мотоциклга утырып, күрше Калмаш авылына таба сыптырганнар. Шуннан соң авылдашларым зиратка килсәләр, ни күрсеннәр: Ишан хәзрәт кабере актарылып ташланган, өстенә яңа балчык ыргытып киткәннәр. Ташы исән булган әле. Шулкадәр актарынып, берәр нәрсә таптылар микән, гомумән, кабердә хәзинә булды микән? Билгесез.

Икенче тапкыр зиратны вертолет белән килеп актарганнар. Ташны әйләндереп атканнар, кабернең астын-өскә китереп, кире күмеп киткәннәр. Нефтьчеләр утырган вертолет булган, диделәр. Эзләгән байлыкларын таптылар микән? Әмма этлекләрен эшләгәннәр, таш, икегә ярылып, авып төшкән.

Уйланып озак басып тордым. Әгәр ташны төзәтеп, язуларын берәрсенә укытсаң, Ишан хәзрәтнең кемлеген ачыклап булыр иде инде. Бу фикерне энеләремә әйтүгә, алар тиз генә, авылга кайтып, көрәк, лом, тимер щеткалар алып килделәр. Таш ватыкларын бергә җыеп, чистартырга тотындык. Гасырлар тузанын тимер щетка белән шактый озак кыра торгач, гарәп хәрефләре күренде. Инде кемгә, ничек укытырга? Иң яхшысы, бөтен язуны карага буяп, фоторәсемгә төшерергә һәм берәр белгечкә күрсәтергә. Нәкъ шулай эшләдек тә. Туганнан туган абыем Рифкатькә, аның уллары Рафаил, Дамир, Илдар һәм оныгы Рамилгә рәхмәт яусын.

«Кодак» фотоаппаратым белән ташны дүрт ягыннан рәсемгә төшердем. «Сау бул, билгесез, изге Ишан хәзрәт! Кабер казып хәзинә эзләүче варварлар тынычлыгыңны алсалар да, туфрагың җиңел, ә изге җаның җәннәттә булсын. Без синең кемлегеңне барыбер белербез, хөрмәтле авылдашым. Килер буыннар да сине онытмаслар!»

Фоторәсемнәрне ясатып алдым. Озак та үтмәде, миңа Русиянең Баш мөфтие Тәлгат Сафа улы Таҗетдин белән очрашу насыйп булды. Мин аңа фоторәсемнәрне күрсәттем. Тәлгат хәзрәт таштагы язуларны укып бирде. Таш кырыйларына Коръән сүрәләре, гарәпчә шигырь язылган. Алгы ягындагы язуда болай диелгән: *«Ишан хәзрәт Ягъфәр Сабучы. Һиҗри буенча 1250 елда җирләнгән»*. Менә син кем

икән, кадерле авылдашым! Ягъфәр Сабучының безнең календарь буенча 1838 елда вафат булганын исәпләп чыгардым. Авылыбыз тарихы әнә нинди заманнарга ук барып тоташкан бит!

Тарихи чыганакларны искә төшерсәк, Болгар дәүләтенең хакиме Әлмуш ханның исеме дә Ягъфәр булган һәм ул иң беренчеләрдән булып ислам динен кабул иткән. Шуннан соң бик күп дин әһелләре дөньялыкта Ягъфәр исеме белән йөргәннәр.

Уфадан кайтуга, мин энеләрем белән тагын наратлыкка килдем. «Исәнме, изге ватандашым Ишан хәзрәт Ягъфәр Сабучы». Ясин сүрәсе укыдым һәм без якташыбызның әллә ничә тапкыр актарылган кабере каршында баш идек. Йөзьяшәр наратлар шавында изге җанның сүзләре ишетелгәндәй булды миңа.

«Сау бул, изге Ишан хәзрәт Ягъфәр Сабучы! Без сине хәтерлибез һәм беркайчан да онытмабыз. Авыр туфрагың җиңел булып, җаның җәннәттә булсын!»

## Вакытлы качаклар

Август аеның эссе көннәре. Вакыт — төштән соң. Без, бала-чагалар, лапта уены белән мавыгып китеп, күрше Калмаш авылы кызының иң соңгы йорт капкасына килеп, шатланып кычкырып җибәрүен сизми дә калдык:

— Сөенче! Шәйхенур абый сугыштан кайта! Сөенче! Шәйхенур абый өенә кайта!

Элек татар авылларында шундый бер матур гадәт бар иде: берәрсе ерак җирләрдән туган авылына әйләнеп кайтканда, аны беренче күреп калган кеше әти-әнисеннән яки туганнарыннан сөенче алырга чаба. Моның өчен аңа ул вакытларда бик яхшылардан саналган шәһәр күчтәнәче бирәләр: пирчәткә, яулык, портсигар.

Чынлап та, күп тә үтмәде, авыл башында җигелгән атлар күренде. Дербешка пристане ул вакытларда Актаныш, Калинин, өлешчә Минзәлә районнарының үзенә күрә «баш шәһәре» булып санала иде. Ул Агыйдел һәм Кама елгалары кушылдыгына урнашкан. Колхозчылар Дербешкага бодай ташый. Авыл халкы — ит, май, бәрәңге, көнбагыш. Дербешка аркылы бик күп ирләр яуга китте, аның аша исән калган, гарипләнгән бик күп солдатлар өйләренә кайтты. Сугыштан соң бу яклардан хезмәткә яраклы халыкның өчтән икесе Мәскәүгә метро, торак йортлар төзелешенә китеп барды. Шулай ук Донбасс, Кизел, Кемерово шахталарына, Сарапулның оборона заводларына, Ижау, Пермь шәһәрләренә, төньяк төбәккә урман кисәргә һәм Сахалин, Камчатка якларына балык промыслосына да бик күп эшче көчләр китте. Минем туган авылым Түбән Карачтан чыгып китүем дә Дербешка аркылы булды. Башта Пермьдәге һөнәр училищесына (ул вакытта Молотов шәһәре), ә аннан соң гаилә белән бөтенләйгә Сарапул шәһәренә. Болары турында соңрак.

Ә бүген, 1942 елның август көнендә, Дербешка пристаненнан юл уңаена туры килгән атка утырып, Шәйхенур абый сугыштан кайтты. Менә ул аттан сикереп төште, сул кулы, муенына бәйләнеп, асып куелган. Аны хатын-кызлар, бала-чагалар сырып алды. Бөтен авылга елау-сыкрау таралды, сораулар яңгырады:

— Минекен күрмәдеңме анда?

— Безнеке исән-сау гына йөри микән?

Бераздан соң тынычланган авыл халкы бая Шәйхенур абыйны китереп киткән атлы тарантас урынында дәшми генә басып торган кырык яшьләрдәге бер хатынны күреп алды. Ул үзе ябык кына, шәһәрчә киенгән, ә аңа берсе — 14, икенчесе 10—11 яшьләр чамасындагы ике кызчык елышкан. Кызлары да тал чыбыгыдай юка, нәзек гәүдәлеләр иде.

— Ә болары — безнең кунаклар була инде,— дип сөйләп китте Шәйхенур абый.— Урыслар. Ленинград блокадасыннан очраклы гына котылып калганнар, Ладога күле аша. Акулинаның ире — Иван, кызларның әтисе була инде, ул сугышта. Мин аларны үзем белән пароходка алдым. Сугыш беткәнче, авылда торырга урын табылыр дип уйлыйм.

Бу, әлбәттә, караңгы татар авылы халкы өчен көтелмәгән бер хәл иде. Әз-мәз урысча белгән ирләр барысы да сугышка китеп бетте. Хатын-кызлар һәм бала-чагалар телне бөтенләй белмиләр. Табигый ки, безнең блокадачы кунаклар да татарча бер авыз сүз дә белмиләр иде. Бердәнбер тылмач — Баһаветдин бабай кала. Аның урысча бераз запас сүзлеге бар.

Безнең өй элеккеге мулланың биш почмаклы йортында урнашкан колхоз кәнсәләренә каршы гына тора. Гадәттә, районнан килгән финагентлар, уполномоченныйлар безгә кереп кунгалыйлар. Бер тапкыр хәтта районның НКВД начальнигы Бариев үзе кунып чыкты. Гадәт буенча Акулина апаны да кызлары белән безгә җибәрделәр.

— Әйдә, кунып чыксыннар. Иртәгә күз күрер тагын,— диде Шәйхенур абый. Аның үзен икенче көнне үк колхоз рәисе итеп сайладылар.

Уракка төшкән көннәр. Шәйхенур абыйны асылмалы кулы белән теләсә кайда күрергә була иде: йә ул тимерче алачыгында, йә фермада, йә басуда арыш урган хатын-кызлар янында чуалып йөри, йә ындыр табагына барып чыга.

Безнең кунакларның бер буханка кара ипиләреннән башка берниләре дә юк. Беренче эш итеп әнием аларны өстәл янына утыртты. Сугышның беренче елларында тылдагы авыл өстәле чагыштырмача бай иде әле. Хәзинәдә ни бар — шуны куйдык. Ничек кыстарга? Әби дә, әни дә, мин дә ашамлыкларның урысча атамаларын белмибез. Ә кунаклар — татарчасын. Менә шунда күмәк «ликбез» башланды да инде.

— Ашагыз! — дип, әбием авыл калачына күрсәтә һәм бармагы белән авызына төртә. Ашарга кушуы, димәк.

— Бу ничек атала? — ди Акулина апа, эремчекне күрсәтеп.

— Эремчек,— дип җавап бирә әнием.

— Хлеб,— дип, Люба калачка ишарәли.

— Х-л-е-б,— дип көлемсерәп әйтеп куям мин. Кичке аштан соң Акулина апа өйгә күз йөртеп чыкты һәм киштәдәге китаплар өемен күреп, әнигә карап куйды.

— Бу — изге китаплар,— диде әни.— Коръән, сабак китаплары.

Шунда Акулина апа, хат язарга теләгән белдереп, әнигә бармаклары белән ишарәләр ясап күрсәтте. Әни сандыктан калын дәфтәр тартып чыгарды. Кунак апа аны кочаклап ук алды.

Бер табак бит ертып алып, Акулина апа, бик тырышып, химик карандаш кисәге белән язарга кереште, ә кызлары аның ягында үзләренчә нидер гөрләшеп тордылар. Менә ул өчпочмак ясады һәм шуңа адрес язып куйды.

— Фронт. Сталинград. Иван. Папа,— диде кызларына күрсәтеп. Без аның фронттагы иренә яңа адресын күрсәтеп хат язганлыгын аңладык. Тиздән ерак татар авылына башка фронтовикларның да өчпочмаклы хатлары ява башлады.

Икенче көнне үк Акулина апа авыл хатын-кызлары белән ындыр табагына эшкә төште. Ул бик җитез генә саламны эскерткә ташлый бара. Янында гына, әниләренә булышырга теләгәндәй, Люба белән Оля да бөтерелеп йөри.

Шулай итеп, качаклар бездә торып калдылар. Йокларга барысы да сәкегә тезелешеп яталар иде. Акулина апа бер генә эштән дә читтә калмады. Кыш көне колхоз сыерларын карады, өйдә әни белән әбигә хуҗалык эшендә ярдәм итте. Татарчаны да йөгерек кенә белә башлады. Ә бу вакытта кызлары авыл халкы белән теттереп татарча сөйләшәләр иде инде. Әбием белән мин дә, әни дә, үз чиратыбызда, алардан күп кенә урыс сүзләре отып калдык. Кышкы озын кичләрдә солдат хатыннары безнең өйдә җыелалар иде. Алар фронттагыларга җылы оекбашлар, бияләйләр бәйләделәр, кисетлар* тектеләр. Боларның барысын да посылка итеп, ерак сугыш кырларына җибәрделәр. Люба белән Оля да мондый кичләрне эшсез утырмадылар. Алар фронттан килгән хатларны кычкырып укыйлар иде. Еш кына үлем турындагы хәбәрләрне дә ишетергә туры килгәләде. Мондый чакта өйдә туктаусыз елаш була торган иде. Эшкә тотынсалар да, дәшми-тынмый гына эшләделәр. Дошманнан үч алырга сүз куешкандай, һәрберсе, үзалдына чиксез нәфрәт, ачу белән карап, эшләрен дәвам иттерәләр.

1943 елның салкын январь көннәрендә Иван абыйның да үлү хәбәре килде. Хәтеремдә, аннан башка тагын ике кешегә кара язулы кәгазь килгән иде. Дошманны татарча да, русча да сүгеп, Акулина апа өч көн елады. Безнең өй өч көн буена бу авазлардан тынмады.

Шәйхенур абый да яралы кулын бәйләмичә йөри башлады.

— Менә бит, кулым төзәлеп килә,— дип әйтә иде ул елмаеп. Ләкин ул озак юана алмады. Аны кабат сугышка җибәрделәр. Ни үкенеч: тиздән аның да үлү хәбәре килде. Колхоз эшләрен башкаруга җитәкче итеп минем әниемне куйдылар. Әнием авылда иң гадел, туры сүзле, ягымлы кешеләрдән санала. Ә Акулина апа аңа ярдәмче итеп беркетелде. Люба белән Оля да матур гына үсеп җиттеләр. Любасы кырык дүртенче елны күрше Мари Суксуы авылында урыс телен укытып йөрде.

Менә сугыш бетте. Җәйге җылы кичләрнең берсендә авылга, аркаларына биштәрләр асып, дүрт гарипләнгән солдат кайтып төште. Дистәдән артыгы сугыш кырында ятып калды. Кайтучылар арасында безнең эти дә бар иде. Ул тиздән колхозны җитәкләде.

Татарчага бик яхшы өйрәнеп җиткәч кенә, Акулина апа белән Оля кире Ленинградка кайтып киттеләр. Ә Люба балаларны урыс телендә укытырга калды. Кырык җиденче елны ул да китеп барды. Татарча бик җылы итеп язылган хатларында алар безне гел кунакка чакыралар иде. Ләкин күрешергә туры килмәде.

Ленинградлылар белән ара бөтенләйгә өзелде. Безнең араны якынайтып торган җеп очы югалды. Кызганыч, без аларның алдагы тормышларында нинди үзгәрешләр булганын белә алмадык.

## Татар язмышы

Зур булмаган бу өч татар авылы бик матур җиргә урнашкан. Авыл тирәсендәге кырлар эшкәртелми диярлек: аны сөрмиләр дә, чәчмиләр дә. Халыкның төп шөгыле: сарык үрчетү. Авылдан ук «Атоммаш» гигантының күккә ашкан торбалары күренеп тора. 20—25 чакрым ераклыкта гына шәһәрнең ыгы-зыгылы тормышы кайнап тора. Цимлян ГЭСының туктаусыз эшләгәне ишетелә. Мондагы татар авылларының (ә авыл халкы аны хутор дип атый) язмышы гаять катлаулы һәм аянычлы була. Кубань казаклары яшәү рәвешенә большевиклар керткән тәртипләр белән килешергә теләмиләр. Аларның күбесен гражданнар сугышында кырып бетерәләр, кайберләрен, туган нигезләреннән аерып алып, Себергә, төньякка җибәрәләр. Аерым хуторларда һәм станицаларда яшәүче халыкны тулысынча Әстерхан өлкәсендәге Нариман районының татар авылларына күчерәләр. Ә татарларның үзләрен Кубань казаклары йортҗирләрендә яшәргә мәҗбүр итәләр.

Большевиклар фикеренчә, казаклар Әстерхан җирләрендә артыгын кыландыра алмаслар, ә татарлар, үз чиратында, Кубань далаларында язмышларына күнеп яшәвен дәвам итәрләр. Ә чынлыкта моның киресе килеп чыга. Әлеге вакыйгаларның шаһиты, Нариман районында туып-үскән хезмәт ветераны, җитмеш яшьлек Касыйм Янбулатов менә нәрсәләр сөйләде миңа:

— Безне Кубаньга куып китерделәр һәм мәҗбүри җибәрелгән казакларның йортларына урнаштырдылар. Ләкин бу озакка бармады. Төнлә белән коралланган качкын казаклар кайчандыр үзләренеке булган өйләрне яндыра, күчеп килүчеләрне үтерә башладылар.

Менә шул вакытларда инде, утызынчы ел урталарында, ач һәм ялангач татарлар Дон арты далаларына килеп утырдылар. Кечкенә йортлар салып, әкренләп тормыш итә башладылар һәм алар шул җирләрдә төпләнеп калдылар. Алга китеп шуны әйтәсем килә: татарлар китеп беткәннән соң да, казакларга туган җирләренә кайтырга рөхсәт бирелмәде. Беренчеләре урынына белорус һәм Тамбов крестьяннарын куып китерделәр.

— Минем бик күп якташларым Ватан сугышы кырларыннан кайта алмады,— дип дәвам итте сөйләвен ветеран.— Сугыш алды елларында артык кешегә саналган татар ирләре беренчеләрдән булып яуга киттеләр. Сугыштан исән-имин кайтканнары сарык үрчетү шөгыленә кереште. Күпләре тимер юлда эшләде. Татарларның байтагы Волгодонски шәһәренә Цимлян ГЭСы, химкомбинат, атом электр станциясе төзелешенә китеп барды. Минем дә өч улым һәм кызым шул шәһәрдә эшләп, яшәп яталар. Бер сүз белән әйткәндә, әлеге өч татар авылы — Кутейник, Еловайка һәм Петровка авыллары — коммунизм төзелеше, шаулы сугыш еллары тәэсирендә эреп, югала барды. Әкренләп ул рус-татар авылына әйләнде. Дон җиренә бик күп Әстерхан татарлары буыны таралды. Җитмешенче-сиксәненче елларда миңа аларның кайберләре белән күрешеп сөйләшергә туры килгән иде. Мин аларның ел саен «Жигули», «Волга» машиналарын алмаштырып торуларына шакката идем. Каян аласыз моны, дип сорагач, алар, хәйләкәр елмаеп, урынын белергә кирәк, дип җавап кайтара иделәр. Тиздән серенә төшендем бит. Бер тапкыр шулай балыкчылар һәм кысла тотучылар белән Сал елгасына бардык. Кысларның монда иң симезләре, мөгаен, урыс чабатасы чаклы бардыр, кыскычлары да куркыныч булып ыржаеп тора. Ләкин безнең кызыклы шөгылебезне балык инспекциясе вәкилләре өзде. Җитмәсә, коралланганнар да. Ахырдан белдек, бу — саклый торган зона икән, мондагы симез-симез кысларны һәм бакаларны дәүләт бригадаларына гына тотарга ярый. Ә алар, үз чиратында, махсус савытларга салып, әлеге табышларны Ростовка җибәрәләр, аннан исә самолет белән Парижга. Ярар, кысласын аңлыйм инде мин аның, үзем дә яратам. Тик менә бакалары! Ләкин минем якташларым — әлеге деликатесны тотучылар, зәңгәр читле тәлинкәгә салынган, төрледән-төрле яшелчә белән бизәлгән һәм тәмләткечләр сибелгән, кыздырылган бака итен күрсәткәч, ирексездән авызымнан сулар килде. Франциягә җибәрергә хәзерләнгән мондый деликатес өчен минем танышларыма хөкүмәт чиратсыз «Волга» һәм «Жигули» бирә икән. Кысла белән баканың да бәясе югары — французлар моның өчен валюта белән түлиләр.

Бүген бу «сәүдә»нең торышы ничек соң? Эре кыслалар урынына җыен вак-төяк эләгә. Ярый инде, бакалары, үзләренең барлыгын белдереп, тирә-якка бакылдап, сөрән салып утыралар. Ләкин Франция белән бәйләнешләр әлегә туктатылган.

Яши әле татар авылы! Иртә саен бугаз киереп әтәчләре кычкыра, дала тюльпаннары да, кечкенә таҗларын кояш нурына коендырып, зур-зур сафлар булып үсеп утыра. Гадәттәгечә, ап-ак чәчәккә күмелгән бакчалары да хуш ис бөрки. Менә шулай яшәп ята татар авыллары: читкә сибелгән сәйлән бөртекләре кебек, аянычлы язмыш кичергән татар кешеләре...

## Әмма аерылышу бик яман…

Яңгырлы, тайгак һәм пычрак көзге көннәрнең берсендә, үз машинам белән Волгоград — Ростов — -Дон шәһәрләре арасындагы трассадан кайтып килгәндә, көтмәгәндә бик авыр юл һәлакәтенә юлыктым. Бу хәл дала түрендә урнашкан Морозовски шәһәре тирәләрендә булды. Тормозы какшаган. «Колхида» минем өр-яңа «Нива»ны бәрдереп китте. Машина йөртүчеләр «Колхида»ның ни икәнен яхшы беләләр. Тауларны җиңел генә кичә торган авыр йөк машинасы ул. Урыны да шундый аның. Күмер чыгару шах-

талары белән чуарланган тәбәнәк таулар тезмәсе белән киң иген кырлары кушылган җир. Мондый калкулыклар Ростов өлкәсенең яртысын биләп торалар.

Автоинспекция хезмәткәрләре узгынчы машинага утыртып, мине Морозовски хастаханәсенең травмотология бүлегенә озаттылар. Табиблар һәм шәфкать туташларының гаять зур тырышлыгы аркасында, мин, азрак рәткә килеп, күзне ачкач, иртәгесен мине, хастаханә арбасына салып, рентген кабинетына алып бардылар. Анда мине урта яшьләрдәге, тазарак кына бәдәнле, төскә матур гына ханым — табиб-рентгенолог каршы алды. Минем кәгазьләргә күз төшереп алгач:

— Сезнең исем-фамилиягез бик сирәк очрый торган, милләтегез буенча кем буласыз? — диде.

— Татар,— дип җавап бирдем мин.— Казан татары. Дөресрәге, Татарстанның Актаныш районында туып-үскәнмен. Хәзер Краснодар өлкәсендә яшим...

— Чынлапмы? — Ак халатлы ханым шатлыгыннан сикереп куйды.— Мин дә татар кызы бит. Без сезнең белән якташлар икәнбез. Мин үзем бу җирдә туып үссәм дә, эти-әниләрем Сарман ягыннан. Ачлыктан качып, утызынчы еллар башында аннан күчеп киткәннәр. Әлегә кадәр Сарман һәм Актаныш ягыннан якташларны очратканым юк иде әле. Алла бирсә колына, китереп куя юлына, дип әйтәләрме әле, сез дә шулай булдыгыз. Беркайчан да тарихи ватаныбызга кайтканыбыз булмады. Сез татарча беләсезме?

— Билгеле. Ничек инде? — дим, арбада яткан килеш. Миңа калса, ханым минем бу кабинетка нәрсә өчен килгәнемне онытып җибәрде бугай. Берничә минуттан мин дә, якташыма ымлап:

— Гафу итегез, исемегез ничек? — дим.

— Гөлнара. Гөлнара Йосыф кызы Новикова мин. Кызганычка каршы, мин үз телебезне бик начар беләм. Татар җырларын бик яратам, үзалдыма көйләп тә йөрим, тик сүзләрен генә белмим. Сез «Сарман»ның сүзләрен белмисезме?

— Әлбәттә, беләм,— дим, яңадан якташыма борылып.

Табибә, тәрәзә төбендәге телефон аппаратын алып, тиз-тиз генә номер җыя башлады. Кирәк номер җыелгач, җитди кыяфәткә кереп:

— Зәйнәп, тыңла әле мине. Монда бер авыруны китерделәр, юл һәлакәтенә очраган, ул безнең якташ булып чыкты, хәтта «Сарман»ның сүзләрен дә яттан белә.— Телефон трубкасын каплап, Гөлнара Йосыф кызы миңа кыскача аңлата башлады: — Бу минем туганым. Зәйнәп Ямбаева, майор. Ул әйтә, бәлки, сез «Шахта» җырының да сүзләрен беләсездер, ди.

— Беләм, беләм,— дим.

— Белә, белә,— ди Гөлнара ханым трубкага. Берничә секундтан минем якка күз сирпеп, өстәп куя: — Минем турындагы җырның сүзләрен белмисезме, дип сорый Зәйнәп.

— Һичшиксез,— дим, ак бинт белән бәйләнгән башым белән ымлап.— «Ал Зәйнәбем» дип атала ул җыр.— Һәм шушы җырның көен көйләп җибәрәм.

— Белә, белә,— дип сөенә ак халатлы ханым. Бераздан әңгәмәдәше белән сүзне болай дип очлый: — Ләкин кичке сәгать алтыдан соң килегез, барлык табиблар да кайтып китеп беткәч,— ди.— Якташымның хастаханәгә килеп хәлен беләсе килә. Татарча җырларның сүзләрен дә язып аласы иде, дип әйтә Зәйнәп ханым.

— Сез мине рентген рәсеменә төшерергә уйлыйсызмы? — дим ярым шаярып.

— Әле аны да эшлисе бармыни? — дип көлә табибә.— Ясыйбыз билгеле, Лондонның иң яхшы хастаханәләрендәге шикелле итеп.

...Кич белән әллә ничә кешелек зур палатага берьюлы кулларына урындыклар күтәргән алты кеше килеп керде. Минем тумбочкам өстенә алма, апельсин, колбаса, прәннек, кефир һәм башка азык-төлек өеп куйдылар. Килүчеләр арасында хатын-кыз милиция майоры, ир-ат капитан һәм башкалар бар иде. Соңыннан гына белдем: болар барысы да шушы Морозовски шәһәрендә яшәүче татарлар икән. Байтак кына җылы әңгәмә корып утырганнан соң, табибә ханым:

— Әйдә, якташ, җыр сүзләрен яздыр безгә,— ди.

Мин ашыкмыйча гына, иҗекләп диярлек сүзләрне әйтеп яздыра башладым.

Җырны яздырып бетергәч, кырыс укытучы шикелле, берәм-берәм кәгазь кисәкләрен алып, укып карыйм һәм «дөрес язылган диярлек» дип, яңадан якташларыма кайтарып бирәм. Аларны наданлыкта гаепләп, һич тә үпкәләтәсем килми билгеле, татарчага якын да килми, урыс хәрефләре белән язылган. Бу аларның ялгышы түгел, ә язмышы...

«Диктант» язылып бетеп, авырулар кичке ашка таралу белән, Зәйнәп һәм табибә ханым әкрен генә «Сарман» көен сузалар. Башкалар да аларга кушыла. Мин дә туган якларымны күз алдына китереп моңланып ятам:

Бергә яшәүләре бик күңелле,
Әмма аерылышу бик яман...

# Ак пароходларга утырып…

Идел—Дон каналын төзүгә әзерлек беренче бишьеллыкта ук башланган иде. Әлеге гомумхалык төзелеше бик күп кешеләр өчен чын мәгънәсендә төрмәгә әйләнде. Сугыштан соңгы авыр елларда биш миллион халык бирелә үз срогын тутырды.

Ике йөз меңле халкы булган Волгодонски хәзер нинди хәлдә? Әйтергә дә куркыныч, иң матурлардан саналган бу көньяк шәһәрендә тормыш тукталып калган кебек.

Тимер юл күперләре, Цимлян буасындагы гидроэлектростанцияләрнең, дамбаларның озынлыгы 13,5 чакрымга сузылган. Цимлян диңгезе исә Волгоградка кадәр җәелгән — Калач-Дон шәһәренә хәтле. Алга таба әлеге ясалма диңгезне мәшһүр Идел елгасына кушылдыручы катлаулы шлюзлар системасы урнашкан.

Монда Идел белән Дон елгасы арасында, безнең болгар бабаларыбызның сугыш гаскәрләре узган, Византия сәүдәгәрләре тауарлар ташыган, азатлык хәрәкәте җитәкчеләре Емельян Пугачев һәм Степан Разинның сугышчылары коры җирдән көймәләрен өстерәп барганнар. 1697 елда патша Петр I бу җирләргә дистә меңнән артык крепостной крестьянны һәм солдатларны куып китергән. Бу урын хәзерге көнгә чаклы Петр валы дип атала.

Әйткәнемчә, Идел — Дон каналын төзү беренче бишьеллыкта ук башлана. Төзелешне сугыштан соң дәвам итәләр. 1952 елның 31 маенда Идел белән Дон елгалары кушыла. Беренче июль көнне каналга беренче судно төшерелә. Ә шул елның 27 июленнән канал кулланылышка кереп китә. Аның гомуми озынлыгы 101 чакрым. Ул тирән су юлы белән Балтыйк, Каспий, Ак диңгезләрне Азов һәм Кара диңгезләр белән тоташтырды. Кара диңгез аркылы Идел, Днепр һәм Днестр елгалары системасы белән бәйләнде. Волгоградтан алып Волгодонски шәһәренә чаклы унбиш шлюз төзелгән. Бу эре төзелеш әлеге төбәкнең икътисадын тамырдан үзгәртте.

Эш күбесенчә кулдан башкарылган: көрәкләр, кәйләләр, тачкалар белән эшләгәннәр. Исән калганнарның сөйләүләре буенча, кешеләр ачлыктан һәм авыр хезмәттән күпләп үлгәннәр. Аларның гәүдәләрен зиратка җирләргә дә өлгермәгәннәр. Ул вакыттагы зиратлар сакланмаган да диярлек. Хезмәткә яраксыз авыру яки гариплэнгән тоткыннарның гәүдәләрен бетонга тыгып, дамбаларның нигезенә салып барганнар. Менә шулай гомумхалык төзелеше Волгодонскидан ул вакыттагы Сталинград шәһәренә кадәр сузылган «гомумхалык зираты»на әйләнгән.

Безнең көннәрдә исә бу төбәк эре промышленность үзәге булып тора. Илленче еллар азагына анда агач эшкәртү заводы төзелә. Алтмышынчы елларда монда инженер итеп Татарстан егете Исмәгыйлев Дамир Гарифҗан улы җибәрелә. Тиздән, җитештерүнең бөтен баскычларын узып, яшь инженер заводның җитәкчесе дәрәҗәсенә күтәрелә. Сәләтле һәм булдыклы инженерны тиздән Ростов-Дон шәһәренә Төньяк Кавказ төбәген материаль-техник чимал белән тәэмин итү буенча идарә башлыгы урынбасары итеп күчерәләр.

Җитмешенче елларда Цимлян диңгезендә атом станцияләрен җиһазлау заводы төзелә башлагач, Дамир Исмәгыйлев яңа постка билгеләнә. Ул Татарстанда гына түгел, бөтен Русиядә билгеле булган «Камснаб» үрнәгендә эшләгән Волгодонскснаб идарәсе җитәкчесе вазифасын үти башлый. Сүз уңаеннан әйтеп үтик, Волгодонски төзелешендә татар эшче көчләренең әһәмияте бик зур. «КамАЗ»ның һәм башка автомобильләрнең беренче чыгарылышыннан соң меңләгән эшче оешмалары, «Камгэсэнергострой» берләшмәсен ташлап, Волгодонски шәһәренә күчеп китте. Монда күпләгән Чаллы эшчеләре тарафыннан «Волгодонскэнергострой» төзелеш-монтаж идарәсе төзелде.

Волгодонски шәһәренең хәзерге хәле бик аяныч. Митинглар, демонстрацияләр нәтиҗәсендә атом электр станциясен төзү туктатылды. Чернобыль вакыйгаларыннан соң реакторлар эшләп чыгару һәм атом-төш җиһазлау дәрәҗәсе бик түбән яки бөтенләй дә юк. Ничә еллар инде бу заманча корылган һәм бик үзенчәлекле завод эшсез тора. Ә бит аңа бөтен дөньяда тиңнәр юк иде.

Минем күп кенә якташларым кабат Чаллыга кайтып киттеләр. Күбесе вахта белән Чечняны төзекләндерү эшенә йөри. Грозныйдагы ГЭЦны аякка бастыручы 28 эшченең 20 се — Волгодонски егетләре — тотсакка (заложник) алынган. Ләкин кешеләр һаман да «кайнар нокта»га барудан туктамыйлар. Беренче көнне Чечняга эшкә йөрүчеләр саны биш тапкырга арткан. Гаиләне туйдырырга, яшәргә кирәк бит, сәбәбе менә шул.

Шулай да Волгодонски халкы өметсезлеккә бирелми. Иран белән Кытайдан атом-төш җиһазлауга заказлар килгән. Бу хәбәр дә сөендерде шәһәр халкын. Атом станциясен дә сафка бастырачаклар дигән сүзләр йөри. Димәк, шәһәр тагын җанлана. Донда су юлы иртә, мартта ук ачыла. Яз көне рейста суднолар күп була, ерак рейсларга да йөриләр. Ап-ак төстәге теплоход палубаларыннан туристлар агыла: Пермьнән, Яр Чаллыдан, Казаннан һәм башка шәһәр-авыллардан. Барысы да шушы яшь, матур Волгодонски шәһәренә карап сокланалар. Зәвыклы төзелгән архитектура корылмаларына, күпләгән су юллары челтәренә карап гаҗәпләнүләрен яшермиләр. Теплоходтан А. Пахмутова һәм Добронравовның дәртле җыры агыла:

Будут плыть пароходы,
Будут годы друг-друга вспоминать.

# Әмирлекләрдәге очрашулар

### *Бүләк түбәтәй — минем виза*

Шулай инде ул... Башка милләт вәкилләренең таркаулыгы, битарафлыгы безгә дә күчкән, кызганыч, күпме теләсәк тә шуннан котыла алмыйбыз. Бу юлы да әлеге «күркәм» сыйфат үзен сиздерде. Без Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә Ростов-Дон аэропортыннан сәгать биштә очып китәргә тиеш идек. Сиксәнгә якын пассажир инде таможня тикшеренүләрен дә узды, кыскасы, очып кына китәсе калды. Ә самолет юк та юк, Мәскәүдән килеп җитмәгән, диләр. Хәер, «Ту-154» килде килүен... тик җиде сәгатькә тоткарланып.

Без Ростов-Доннан очып киткәндә, урамда 10 градус салкын иде. Дүрт сәгатьтән соң Әл-Айн аэропортына килеп төштек. Эссе, 33 градус. Мин, тиз генә сумкадан табып алып, Актаныш күчтәнәчен — түбәтәемне киеп куйдым.

— Суйган да каплаган мөселман инде үзең,— дип көлемсерәделәр ростовлы юлдашларым.

— Чыраең барыбер Рязань чырае инде,— диде шунда берсе.

— Рязань түгел, Казан чырае,— дип төзәттем аны.

Шәрекъ стиле белән корылган заманча аэропорт бинасына килеп кердек. Таможня үз эшен төгәл башкара. Менә минем чиратым да җитте. Таможняда торучы яшь кенә гарәп документларымны игътибар белән өйрәнде дә Ростов аэропортының Әмирлектәге вәкиленә инглизчә нидер әйтте.

— Сезгә керү визасы ачылмаган икән,— диде ростовлы.

— Ничек инде,— дип гаҗәпләндем мин.— Ростовта бернинди проблема да булмас, диделәр бит.

— Әйе, барысы да тәртиптә, тик сезнең фамилияне виза кәгазенә кертергә онытканнар. Сезгә залда кунарга туры киләчәк.— Һәм дә елмаеп өстәп куйды: — Кәнәфиләр шәп монда, күннән... Бер кичкә кер мичкә, диләр бит. Хәзер Ростовка факс җибәрәчәкбез, иртәгә төш вакытына җавап килеп җитәр...

Юлдашларым зур залга уздылар. Башымдагы Актаныш түбәтәе белән (миңа аны туганнарым бүләк иткәннәр иде) мин берүзем моңаеп тикшерү залында калдым.

Шулай аптырап басып торганда, ап-ак тешләрен ялтыратып яныма пакистанлы полицейский килде. Үзе минем түбәтәйгә карый, үзе елмая.

— Мин — мөселман,— дигән булам, түбәтәемә бармак белән төртеп.

Пакистанлы һаман да елмая. (Әмирлекләрдә пакистанлылар полицейский булып килешү буенча эшлиләр.) Тәрәзә аша күрәм, әле минем юлдашларым Дубайга китмәгәннәр, һәммәсе дә ни булыр икән дип мине күзәтәләр. Үзләре хихылдыйлар, әйе, әйе, көлмиләр, ә хихылдыйлар:

— Эләктеңме, татар...— янәсе.

Мин һаман: «Мөселманмын»,— дип кабатлыйм, үзем түбәтәемә төртеп күрсәтәм. Шулвакыт исемә балачактан ук өйрәнгән дога килеп төшә һәм мин үзем дә сизмәстән кычкырып шуны укый башлыйм: «Әгүзе билләһи минәш-шәйтанир-раҗим...»

Шулчак полицейскием елмаюдан туктады да ашыга-ашыга каядыр китеп барды. Биш минутлап вакыт узгач, полицейский униформа кигән гарәп һәм Ростовның «Донавиа» авиапредприятиесе вәкиле белән кире әйләнеп килде. Үзара нидер сөйләшкәннән соң, миңа таба юнәлделәр.

— Әйдәгез зур залга, юлдашларыгыз янына,— диде «Донавиа» вәкиле.— Полицейский һәм виза буенча җаваплы кеше сезне кызгандылар, иртәгә визаның факс белән киләчәгенә ышандылар.

— Вәт, татар,— дип каршы алдылар мине ростовлылар, шау-гөр килеп.

— Кадерле партиябезгә бәхетле балачагыбыз өчен рәхмәтләр яусын! — дидем мин, янә дә түбәтәемне капшап.

### *Бунгало*

Дубайның Насыйр-плацы бик күркәм. Бу мәйдан Мисырның беренче Президенты Гамәл Габделнасыйр хөрмәтенә шулай аталган (Насыйр — Советлар Союзы Герое. Заманында аңа бу исемне Н.С. Хрущев биргән иде). Әлеге мәйданның зиннәтле биналарында дөньяның эре банклары, халыкара оешмаларның офислары урнашкан. Бу мәйданнан әлеге гүзәл башкаланың берсеннән-берсе матур проспектлары башлана. Ә шәһәрнең тын яшел урамнарына һәрберсе заман архитектурасы үрнәге булырлык 4—5 йолдызлы кунакханәләр тезелешеп киткән.

Насыйр-плац элеккеге Советлар Союзының төрле республикаларында яшәүче урыс телле халыкның очрашу, аралашу урыны булып та тора. Мәйданнан ике кварталда кибетле, лавкалы урамнар башланып китә. Анда безнең «челнок»ларга уптым тауар саталар. Урамнар базарлы мәйданга килеп терәлә.

Базар тирәләрендә халык аеруча күп. Баш киеменә карап, кемнең кем икәнлеген бик тиз аерырга була. Мәсәлән, башына хатын-кыз яулыгына охшаган озын ак тукыма ябып йөри икән, ул гарәп булыр. Әгәр «яулык»та бер бөҗра бар икән, аның хуҗасы Мәккәдә бер тапкыр булган, ике бөҗра — ике тапкыр хаҗ кылган... Һиндлы мөселманнар исә тюрбан киеп йөрергә яраталар.

Пакистанлылар түбәтәй-«пилотка» кия. Ә Әфганнан чыккан әфганлылар кайчандыр Политбюро әгъзалары кигән бүреккә охшаган түгәрәк башлык киеп йөриләр.

Ә инде Дубайда нәкышләп эшләнгән, матур бизәкле түбәтәй кигән урта яшьләрдәге ир-ат күрсәгез — бу мин, ягъни Актаныш татары булырмын...

Шәһәрдә йортлар, нигездә, җиде катлы. Әмма һәрберсендә үзенә генә хас үзгәлек, бизәк бар.

Биредә мәчетләрне аеруча матур төзиләр икән. Алар Дубайда бихисап. Намаз вакытында урамнар бушап кала.

Шәһәрдән Әл-Айн аэропортына кадәр (180 чакрым) бик шәп автобан сузылган. 20—25 чакрым саен автозаправка станциясе. Андый юл Русиядә кайчан булыр, һәрхәлдә, мин үзебездә андый трассаларны күрә алмам инде.

Тирә-юньдә иксез-чиксез чүл. Дөяләр, барханнар... Ә автозаправка станциясе янында пальмалар, хөрмә агачлары үсеп утыра. Туфракны биредә бөтен дөньядан китерәләр икән. Ә станциянең үзендә бер генә май, ягулык табы күрмәссең. Якында гына «шоп». Керәбез. Кондиционерлар шаулый. Безнең бәя буенча уртача кибет. Иң мөһиме шул: чүл уртасында юк кына бәягә дөньяның төрле илләрендә эшләнгән җаның ни тели, шул тауарны сатып алырга мөмкин. Гаҗәп бит!

Автозаправка станциясенең икенче ягында ап-ак манаралы кечкенә генә мәчет. Автомобилең станция хезмәткәрләре карамагында булганда, мәчеткә кереп намаз да укып чыгарга була. Мәчет каршына, ни гаҗәп... бәдрәф ясап куйганнар. Анда, чүл уртасы булуга карамастан, кондиционеры да, җылы суы да, комганы да, хәтта кәгазь сөлгесе дә бар. Барысы да бушка.

Күптән түгел генә мин үзәк журналларның берсеннән АКШның элеккеге илчесе Джон Мэтлокның Русия буйлап сәфәре тәэсирләре хакындагы язманы укыган идем. Ул: «Мин Л.Н.Толстой, А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, Ф.М. Достоевский кебек гениялар алдында баш иям, И.Е.Репин, В.М. Васнецов, А.М. Герасимов кебек рәссамнарның әсәрләренә сокланам, әмма... Великие Луки аэропортындагы бәдрәфне гомеремдә дә онытасым юк»,— дип яза.

«Әй-йе,— дим мин үз-үземә.— Великие Луки гына булсачы. Әмма Русия бик зур шул».

Әмирлекләрдән сәфәр йөреп кайткач, миңа Ростов аэропортында тагын бер урыс кешесе очрады.

— Әмирлекләрдән кайтуыңмы? Анда чума йә холера эләктермәгәнсеңдер бит?

— Җаным,— дидем мин уфтанып,— холера белән чуманы Русиядән Әмирлекләргә илтеп таратуы ансатрак. Бездә аның өчен шартлар җитәрлек...

Әмирлекләрдә үзеңнең мөселман дөньясында икәнлегеңне тоеп яшисең. Юллардагы шәһәрләр исемнәре күрсәткечләре шуны раслый: Әл-Кувейт, Әбү-Даби, Мәдинә, Мәккә, Әр-Рияд, Җидда...

Биредә бездә өзлексез чәйнәлгән мөселман, ислам фанатизмы да, ислам фундаментализмын да сизмисең. Берәү дә сине көчләп мәчеткә кертеп намаз укырга мәҗбүр итми, башыңа чалма, тюрбан, түбәтәй кигезми. Ислам биредә — яшәү рәвеше, фикер йөртү рәвеше.

Шәрекъ илләрендә булгач, исламның агрессив түгел икәнлеген, аның киләчәк буын дине булуын тоясың, сиземлисең.

Мин шулчак Татарстаным турында уйладым. Анда да бит җир мае чыгарыла. Күп кенә түгел, бик күп. Ә ничек яшибез? Байлыгыбыз «Дуслык» нефтьүткәргечләре Ангола, Мозамбик, Никарагуаның якты киләчәге хакына каядыр төпсез упкынга акты да югалды...

Әмирлекләрнең үзенең төп унҗиде гаилә-кланы бар. Илнең калган халкы төрле гарәп, мөселман дәүләтләреннән җыелган халык. Әмма алар төрле илләрдән килгән булсалар да, гарәпчәдән тыш инглиз телендә дә иркен аңлашалар. Соңгы вакытларда биредә рус теленә дә игътибар көчәйде. Русиядән килгән «челнок»лар белән аралашырга, тауарны тиз арада үзеңә ятышлы бәядә сатып җибәрергә кирәк бит.

Дүрт йолдызлы зиннәтле «Флат-отел» кунакханәсенең холлында йә булмаса бассейн янында мин әлеге кунакханәнең хезмәткәрләре — Һиндстаннан килгән мөселманнар белән гәпләшергә ярата идем. Аларны, әлбәттә, Татарстан кызыксындыра: «кяферләр» белән уратып алынган «атау»да яшәвебезгә шаккаталар.

— Синең нефтең бармы соң? — дип сорап куя шунда бер һиндлы мөселман.

— Бар, ник булмасын! Нефть суырту җайланмалары бәрәңге бакчасында гына...

Әңгәмәдәшләремнең гаҗәпләнүдән күзләре зур булып ачыла.

— Ә нәрсә ул бәрәңге бакчасы? — дип кызыксына икенчесе.

Ә мин уйлап-уйлап торам да телемә килгән беренче сүзне әйтеп калырга ашыгам:

— Бунгало...

— О, Аллаһ! Синең бунгалоң бар?! Болай булгач, син — әмир...

Һиндлыларның гаҗәпләнүләре тагын да арта төшә...

Кызганыч, алар без авылдан «бәхет эзләп» чыгып киткәндә җимерелеп, аварга торган өч алачыгыбыз калганын белмиләр шул. Ә нефтькә килгәндә, ул Актанышта күптән түгел генә чыгарыла башлады. Ни өчен, кем өчен чыгарыла, Алла үзе генә белә торгандыр. Ә менә безнең элеккеге бәрәңге бакчасында әлегә эшләмәүче бер скважина тора. Дөнья хәлен белеп булмый, бәлки, аннан да җир маен суыртырлар.

### *Шуравилар*

Бу бай шәһәрдә мин бер генә хәерчене дә күрмәдем дип әйтер идем, ялган булыр. Ике кешене күрдем, алар миңа элеккеге совет чынбарлыгын хәтерләттеләр.

...Ул базар мәйданында, Шәрекъның җәннәт җимешләре сатылачак кибет янында утырып тора иде. Ике аягы да юк, югары сыйфатлы күннән, ялтыравыклы никельдән эшләнгән протез. Узып баручылар бу адәм алдындагы пластмасс савытка ара-тирә дирхәмнәр, долларлар ташлап китәләр.

— Дух! — диде аны күргәч, Виктор Казаченко үзенең юлдашы Сергей Фроловка.— Аның әфган тюрбаны бу адәмнең безнең иске танышыбыз булуы хакында сөйли...

Юлдашларым, кайчандыр әфган сугышында катнашып, могҗиза белән генә исән калган ир-егетләр иде.

Аяксыз шунда безне күреп алды:

— О-о, шурави! — диде ул. Аннан күкрәгенә төртеп: — Дух, дух, мөҗаһид...— дип кабатлады.

Белмәүчеләргә аңлатып китәм: мөҗаһид — әфган сугышында совет гаскәрләренә каршы көрәшкән әфганлылар, ә шурави — совет сугышчылары була инде.

— Пуштун? — дип сорап куйды Казаченко.

Дух «юк» дигәнне аңлаткан ишарә ясады.

Чираттагы сорауны Фролов бирде:

— Таҗик?

— Үзбәк! — дип җавап кайтарды кичәге «дух».

— Ну, егетләр, сездән мөгәрич! — дигән булдым мин.— Тылмачыгыз булам. Татарча белгәч, үзбәкчә дә аңларга мөмкин.

Шуннан гәп кора башладык.

Кәрим (аяксыз әфганлының исеме шулай булып чыкты) Кандагар янында шуравиларда өч ай әсирлектә булган икән. Шунда берничә урыс сүзен хәтеренә сеңдереп калган. Аякларын сугыш тәмамланыр алдыннан гына совет снаряды кыйпылчыкларына өздергән. Афәт вакытында барча туганнарын югалтып, япа-ялгыз калган. Озак вакытлар дәвамында Пакистанда дәваланган. Америкалылар үзенә менә дигән протезлар ясап биргәннәр. Хастаханәдән чыккач, сугыштан, ыгы-зыгыдан туеп, Әмирлекләргә килгән.

Әңгәмәнең иң кызган чагында безгә тагын бер мөҗаһид килеп кушылды. Анысына кырык яшьләр чамасы булыр, бер кулы юк. Үзе Әхмәт исемле икән. Язмышы Кәрим язмышына охшаш.

— Менә бу очрашу! — диде шулчак Казаченко.— Бу хәлне юмыйча булмый...

— Ара-кы,— дип елмаеп куйды Кәрим дә.

— Хә-рәм! — дип үз сүзен әйтеп калырга тырышты бер куллы Әхмәт кырыс кына.

— Синең хәрәмең белән ерак барып булмас,— диде Казаченко кискен генә һәм, юлдашының җилкәсенә сугып, бәхәскә нокта куйды.

— Бар тизрәк, кунакханәгә чап, анда запас бар бит.

Сергей Фролов, урыс аракысы кыстырып, бик тиз килеп җитте. Кибетче духларның якташлары икән, шунлыктан аның склад кебегрәк җиренә кереп, шешәдәге аракыны өчкә бүлделәр дә. Күпме кыстасалар да без Әхмәт белән «шайтан суы»ннан баш тарттык. Кәрим исә аракыны шуравиларда әсирлектә вакытта эчәргә өйрәнгән икән.

Эчтеләр, кабымлык кабып куйдылар. Аракы исә һәрвакыттагыча җитмәде. Фроловка янә дә кунакханәгә «акбаш» артыннан барып килергә туры килде...

Бу вакыйгадан 15 минутлап вакыт үтмәгәндер, базар мәйданында Фроловны пакистанлы полицейскийлар тоткарлады. Мескенне күз ачып йомганчы такси белән каядыр алып та киттеләр.

Ни булганын кичкә таба гына белдек. Фроловны спиртлы эчемлекне пропагандалаганы өчен кулга алганнар икән. Үзе дә ахмак инде, кунакханәдән аракыны челтәр сумка белән ташыган икән.

Әйе, Әмирлекләрдә теләсә нинди спиртлы эчемлекне пропагандалау, куллану тыела. Моның өчен җәза бик кырыс. Фроловны да 30 көнгә төрмәгә ябып куйдылар. Дубай шәһәре үзәгендә Әфган сугышы ветераннарының очрашуы әнә шулай күңелсез тәмамланды. Ә без Ростов-Донга Сергей Фроловсыз гына очып киттек.

...Иртән, багаж өчен акча түләргә дип, авиапредприятие кассасында чират торам. Халык шактый гына. Чиратым килеп җитте дигәндә генә, алдыма ниндидер майор килеп керде дә кәгазьләрен касса тәрәзәсенә төртте:

— «200 нче йөк». Ике урынга. Новгородка кадәр.

Мин, хәрбинең тактсызлыгына хәйран калып, үземне яклап сүз әйтергә уйлаган идем, хәрби үзе:

— «200 нче йөк» — табутларда безнең солдатлар. Аларны Чәчәнстаннан Ростовка тимер юл белән рефрежератор вагоннарда китерәләр, ә аннан соң без бөтен Русия буенча туганнарына таратабыз. Шундый махсус батальон бар,— дип аңлаткач, үземә оят булып китте. Шушы көнгә кадәр «200 нче йөк»нең ни икәнлеген белмәгәнмен икән... Ирексездән хәтеремә Берләшкән Гарәп Әмирлекләре башкаласы Дубайның базар мәйданында очраган кулсыз Әхмәт белән аяксыз Кәримнең дөньядан туйган күзләре, нурсыз карашлары килде.

## Менә сиңа кодагый!

Яңа көн туды. Кояшның беренче нурлары тәрәзә каршындагы каен яфраклары белән шаярды, иркәләп-назлап аларны уятты. Ягъфәр бу каенны моннан ун ел элек шәһәр читендәге нарат урманына ук терәтеп салынган йорттан алган фатирга гаиләсе белән күчеп килгән көнне утырткан иде.

Әле генә күргән татлы төшеннән һәм каенга кунып сайраган кошлар тавышыннан зиһененә килә алмыйча, Земфира йокы бүлмәсеннән чыкты. Аш бүлмәсендә балкып ут яна, өстәлдә Яъфәрнең портфеле ята. Әй ул портфельнең күргәннәре! Ягъфәр йоклаганда гына хуҗасы кулыннан төшә ул!

Земфира аш бүлмәсенә үтте. Табуреткада Ягъфәр утыра. Кулына ручка тоткан, үзе, мөкиббән китеп, «Известия» газетасына текәлгән. Моны күргән Земфира тәмам аптырашка калды.

— Сәлам! — диде ул.— Беренче автобус белән үк башкалага китәсе кеше нишләп һаман өйдә утыра?

Ягъфәр ашыкмыйча гына газетасын читкә алып куйды. Күзлек өстеннән генә хатынына карап, бармагы белән ишеккә төртте һәм пышылдап кына:

— Ул! Анда ул утыра... Мөгаен, икенче рейс белән китәрмен инде,— диде.

Земфира йокысы ачылып бетмәгән күзләрен сыпырып куйды:

— Кем? Тагын кем утыра?

— Соң, кем дип, ул инде, Васька мәлгунь.

— Тьфү сине... Тәмам гарык иттең шул Васькаң белән! Чәчең агарып бетте, үзең һаман юк-барга ышанасың.

— Беренчедән, Васькаң түгел. Каян килеп минеке булсын ди ул? Икенчедән, мин түгел — ул кара шайтан җәзалый мине. Җаныма тиде — тәки үз башына ашкына, иблис.

— И-и-и, сөйләшә бит әле, черки үтерергә дә курыкканын белмичә,— дип йомгаклады әңгәмәне Земфира, ишектән чыгышлый. Ул да булмады, ишек артыннан хуҗабикәнең тавышы ишетелде: «Көш моннан, кара җен!» Подъезд ишеге ачылып ябылды.

Земфираның әллә юк-барга ышанучы иренә, әллә аларның ишек төбен үз иткән күрше подъезд песиенә ачуы килде, аңламассың. Иренә дә коры гына дәште:

— Бар, Нострадамус. Сиңа юл ачык.

Ягъфәр укыган газетыннан күзен алмыйча гына җавап бирде:

— Юк әле, чыкмыйм. Башта өстән берәрсе төшсен...

Бу кара песи Ягъфәрнең үзәгенә үтте. Юри үчекләгәндәй кылана бит! Аны хуҗалары, күрше подъездда яшәүче Затолокиннар, урамнан табып, кечкенәдән үстерделәр. Васьканы хәзер элеккеге беспризорник дип һич уйламассың: үзе зур, күзләре «Мерседес» фаралары шикелле янып тора.

Даими дежур тору урыны итеп, Васька никтер Ягъфәрләр фатирының ишек төбен сайлады. Юкса монда аны берәү дә сагынып тормый иде.

Еш кына Ягъфәр эштән соң кайта. Песи исә аны гел үз урынында каршы ала. Ягъфәрне күрүе була — яшен ташыдай [illegible] синең аркада Земфира белән тагын сүзгә киләбез икән...» — дип уйлый ул.

Песи аркасында ишетәсе әллә нинди яман хәбәрләр турында уйлап, борчылып, Ягъфәр ишек кыңгыравына баса. Ишек ачылырга да өлгерми, ир сорау бирә:

— Бар да тәртиптәме?

Земфирасының җавабы барлык шикләрне куып тарата:

— Бер дигән...

Ничә еллар дәвамында шушы сорау-җавап үзенә күрә бер парольгә әйләнде.

Васька гына тәмам азды. Ул Ягъфәргә иртәләрен дә тынгылык бирми башлады. Ягъфәрнең чыгам дип ишек ачуы була, Васька шул мизгелдә читкә ыргыла һәм әллә чын, әллә юри юлны кисә. Ягъфәр,

бу бәдбәхетнең кыланмышына игътибар итмәскә тырышып, кире борылмыйча командировкаларга китеп тә карады. Әмма юлы уңмый, эше эш булмый. Әллә нинди уңышсызлыкларга тап була. Шунлыктан, соңгы вакытта Васьканы күрсә, Ягъфәр бөтенләй ишектән чыкмый башлады. Песинең хуҗабикәсенә дә әллә ничә әйтте:

— Галя, шул кара тигрыңны фатирыңнан чыгарма әле. Ни дип һаман безнең ишек төбен саклый ул?

— Мин ни эшли алам, күршекәем! Песи бит ул — җан иясе, иркенлекне ярата. Подъездыгызда матур песиләр бардыр...

...Әһә, ишек ягыннан кемнеңдер аяк тавышлары ишетелде. Берәү ашыга-ашыга баскычтан төшеп китте, подъезд ишеге ачылып ябылды.

Ягъфәр дә урыныннан кузгалды.

— Ярар, киттем мин.

— Портфелең кала күрмәсен. Буш кул селтәп йөрмәссең бит, — дип шаяртты Земфира.

Портфеле дә бер могҗиза инде аның. Беренчедән, ул шактый гына тузып таушалган. Ягъфәр саран кеше түгел. Әмма бер яман гадәте бар — иялләшкән әйберсен ташлый алмыйча интегә. Бу аның өчен әйтеп бетергесез зур җәзага тиң. Үтмәсләнеп беткән лезвиеме, теше төшкән таракмы — Ягъфәр өчен барыбер. Ул аны үзенең бер кисәге шикелле итеп күрә һәм кадерләп саклый. Земфирадан үзенә эләгеп тора, «Плюшкин сыңары» дигән исем дә алды. Әмма моңа бер дә үпкәләми ул. Тик аңа карап, ватык диктофонын да, иске кассетасын да ташламый. Алар гынамы соң! Авылдан ук килгән иске балтасы да бар әле. Хатынының канәгатьсез мыгырдавына ирләрчә каты гына итеп: «Кирәксез балта б...к чабарга ярый!» — дип куя да, вәссәлам. Иске портфельнең дә язмышы шулайрак. Юкса кызлары туган көненә яхшы күңнән тегелгән, алтын каптырмалар белән бизәлгән бик шәп, затлы портфель дә бүләк иттеләр. Әмма Ягъфәр үзенең иске портфелен ташламады, зур начальниклар янына шул портфеле белән йөрүдән туктамады. Хатыны һәм кызларына җавабы бер булды: «Сезнең бүләкне кадерләп саклыйм».

Портфельгә бәйле тагын бер «юләрлек» аның күңелендә бик яхшы оя тапты. Ничектер бервакыт уртанчы кызы әйтеп куйды:

— Әти! Портфельне идәнгә куярга ярамый. Акча кача икән.

Кызы әллә шаяртты, әллә ишеткәнен әйтте. Әмма бу Ягъфәргә җитә калды, әлеге сүзләр аның интеллигент җанында тирән тамыр җибәрделәр. Шуннан бирле Ягъфәрнең берәр министр яисә академик кабинетына килеп керүе була, портфель шалт хуҗаның өстәленә йә булмаса янәшәдәге берәр урындыкка! Тик идәнгә генә түгел! Рәхмәт төшкере, юраганы юш килде, акча Ягъфәрне ярата башлады. Язмаларын һәркайда сорап алалар, теләп бастыралар, гонорарын да әйбәт кенә түлиләр.

Күптән түгел Ягъфәргә сәер төш керде. Имеш, аның портфеле ятим баладай ишек төбендә тора. Ягъфәр эсселе-суыклы булып уянып китте. Тизрәк утны кабызып, ишеккә таба китте. Җанына рәхәтлек йөгерде, Аллага шөкер, төш кенә икән, портфель монда юк. Сөенеченнән тын алуларына кадәр үзгәрде. Кабинетына керде. Менә бит, җанкисәге үз урынында — өстәл өстендә! Ягъфәр портфелен сыпыргалап алды һәм тыныч күңел белән йокы бүлмәсенә кереп китте.

Юк, Ягъфәр элек мондый түгел иде. Юрау-хорафатларга бөтенләй ышанмый иде. Әнисе белән бергә ураза тоткан хатынын да, син көне буе ачка тилмергәндә, мулла тәмле-тәмле ризыклар белән корсагын бүлтәйтә, дип үрти иде. Горбачевның үзгәртеп кору чоры Ягъфәрнең тормышка карашын да үзгәртте.

Туксан беренче елның август «путч»ына кадәр биш ел буе ул барлык иҗтимагый сәяси һәм әдәби журналларны укып барды. Җентекләп Ватан һәм милләт тарихын өйрәнде. Зур тарихны үзенең тормыш юлы белән чагыштыруда аны Виталий Коротичның «Огонек» журналы да этәрде. Танылган астролог һәм күрәзәче Мишель Нострадамусның 1555 елда ук дөнья күргән «Йөзьеллыклар» исемле китабы Ягъфәр өчен зур ачыш булды. Француз күрәзәчесе моннан биш гасыр элек Русиядәге 1917 ел вакыйгаларын да, 1941 — 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышын да, бөек КПССның таркалуын да белгән һәм күрсәткән.

Шул карт яһүд Нострадамус Ягъфәрнең тормышын төбе-тамырыннан үзгәртте дә куйды. Ул еш кына үз тормышындагы вакыйгаларны анализлый башлады. Эпоха намусы өйрәткәнчә яшәп никадәр ялгышуын аңлагач, тәмам пошаманга төште Ягъфәр.

Яшьлегендәге бер вакыйга исенә төшеп, тәмам һушын алды. Земфира белән өйләнешкән еллары. Яшьләр үз куышларын булдырырга — өй салып керергә ният итәләр. Ул елларда күпләп фатирлар төзү модада түгел иде. Шунлыктан төзелеш өчен җир алып, агач йә кирпечтән шәхси йорт җиткерелә. Земфира белән Ягъфәр дә шушы юлны сайлыйлар: бура бурап өй салырга уйлыйлар. Бирәм дигән колына — китереп куяр юлына: аларның бәхетләреннән урманда санитар кистерү оештырып, матур гына наратларны егып аттылар. Башланган эш беткән эш дигәндәй, күз явын алырлык бураны да бик тиз өлгерттеләр. Инде фундамент мәсьәләсен хәл итәсе калды. Кайсыдыр киңәш бирде. Нарат тавындагы җимерек чиркәү ташлары фундаментка бик шәп икән. Ягъфәр карап кайтырга уйлап, Нарат тавына таба китте. Менә ичмасам матурлык! Кама елгасы җәйрәп ята, шәһәре дә уч төбендәге шикелле. Элеккеге

чиркәүнең стеналарын йорт салучылар ташып бетергән, әмма бераз лом белән төрткәләсәң, фундаментлык кирпеч бар.

Яшьләр ике ялларын иске чиркәү хәрабәләрендә казынып үткәрделәр. Ягъфәр лом белән вата торды, Земфира кирпечләрнең матурларын гына сайлап тезде. Өченче көнне Ягъфәр редакциядәге иптәшләре белән аларны бура янына кайтарып аударды.

Кич белән Ягъфәрнең әнисе Мөнирә ханым килде. Шатлыгы йөзенә чыккан.

— Болай булгач, өегезне төзеп бетерәсез икән. Кирпечләре бик нык, матур булган. Иске кирпечләр. Каян юнәттегез?

— Нарат тавыннан, чиркәү кирпече бит, шуңа нык,— диде Ягъфәр.

Әнисе телсез-өнсез калды.

— Шулаймыни? Тәңре йортыннан алгансыз, хәерле булсын. Шайтан котырткан сезне.

— Ишелгән стена ташлары ул. Бар шәһәр халкы шуннан ташый бит. Әнә ташландык татар зиратының бетон коймасын да фундаментка ташып бетергәннәр.

— Ташуын ташыдылар да бит, улым, зират коймасыннан салынган нигезләр генә бәхетле булмады. Югары оч Иван Меркушевны хәтерлисеңме?

— Хәтерлим. Шуннан?

— Ул да шул коймадан фундамент салган иде.

— Соң, Иван бер дигән йорт җиткерде.

— Бер дигәнен бер дигән дә бит... Иван үзе Камага төшеп үлгән. Әле кичә генә.

— Кызганыч, әрәм булган. Бик эшчән мужик иде.

Ул арада күрше Рәүф карт та алар янына килеп баскан икән. Ягъфәр сүз белән мавыгып, сизмичә калган. Кечкенә генә чал сакаллы, ботинка бавы белән бәйләп куйган күзлекле (ул күзлек һәрчак борын өстенә кунаклый) бу карт ничектер әкияттәге кәҗәгә охшаган.

Рәүф карт татарлар арасында мулла булып йөри. Исем кушарга да, никах укырга да, ясин чыгарга да гел аны чакыралар. Берәүне дә кире какмый, һәр йоланы җиренә җиткереп үти. Кыскасы, Рәүф карт — шәһәрнең хөрмәтле аксакалы. Ул, туган авылында мулла булып йөргән өчен, Сталин лагерьларында нужа чиккән.

— Әниең дөрес әйтә, улым,— дип сүзгә кушылды Рәүф карт.— Ходай бәндәләренең изге йорты булган зират, чиркәү, мәчетләрне талап, үз ояңны корырга ярамый.

— Без материалист, атеистлар. Аннан килеп, бар да ала бит. Җимерек чиркәү ташлары, имеш... Мәчет булса бер хәл иде әле.

— Тәңре йорты Тәңре йорты инде, мәчетме, чиркәүме — барыбер,— диде Рәүф карт.— Үз тормышымнан бер вакыйга сөйлим әле сезгә.

Утыз беренче елның зәмһәрир гыйнвар көнендә безне — бер төркем Актаныш муллаларын, Татарстан, Удмуртия һәм Башкортостан чигендә урнашкан Камбарка тимер юл станциясенә китерделәр. Каракүл, Камбарка районы попларын да шунда ук җыйганнар. Беркөнне барыбызны бергә, тауар вагонына төяп, Себергә озаттылар.

Хрущев чорында — илленче еллар ахырында, без — кырым татарларын, чечен, ингуш, калмык халыкларын мәҗбүри рәвештә туган җирләреннән куып, кеше яшәмәгән урыннарга күчерүләр турында сөйли башладык. Дөрес сөйлибез, үткәннәрне онытырга хакыбыз юк. Үткәнен белмәгәннең — киләчәге булмас, диләр. Әмма бернәрсәне оныттык без: Сталин үз халкын депортацияләүне Бөек Ватан сугышына кадәр үк башлады. Утыз беренче елда ук дин эшлеклеләрен, кулакларны — бай крестьяннарны Себергә кудылар. Социализм җәннәте төзергә комачауламасыннар, янәсе.

Себергә нәкъ бер ай бардык. Юлда күпләр ачтан кырылды, туңып үлде. Һәр тимер юл станциясендә мәетләрне алып китү өчен җигүле атлар каршы ала иде. Шул вакытта без — татар муллалары һәм рус поплары — янәшә тезләнеп, һәркайсыбыз үзенчә Ходайдан ялвара идек. Соңыннан Свердловски өлкәсенең төньягына килеп төпләнгәч тә, бергәләп намаз укыдык, гыйбадәт кылдык. Теләгебез уртак иде — Ходайдан гомер сорадык.

Рәүф карт, мәрткә киткәндәй, күзләрен йомып тынып калды. Бераздан, кыйссасын дәвам итте:

— Христианнар Мөхәммәт пәйгамбәребез янына килгәннәр. Гыйбадәт вакыты җиткән. Шунда пәйгамбәребез: «Мәчеткә кереп укыгыз!» — дигән. Шулай, балалар. Мин сезгә бер генә нәрсәне әйтергә телим: Тәңре йортына кул күтәргән бер генә бәндәнең дә бәхетле булганы юк. Утызынчы елларда татар авылларында мәчет манараларын кистеләр. Манарага кул күтәреп, балта чапкан, пычкы тоткан бер генә адәм дә үз үлеме белән үлмәде. Кайсы үзенә кул салды, кайсы бәхетсезлеккә тарды. Хәер, берәү исән икән. Манара кискәндә башлап йөргән укытучы карчык исән әле. Туксан тулды үзенә. Яшәве яшәү булмады, гомере буе бума чире белән җәфаланды. Аллаһы үзенә дә алмый, рәтле тормыш та бирми...

Брежневның торгынлык һәм социализм нык чәчәк аткан чорында булды бу сөйләшү. Сиксәненче еллардан соң булачак коммунизм төшләргә кереп кызыктырган чак. Ягъфәр Рәүф карт философиясен дә, әнисен дә бик игътибар белән тыңлады да, икенче ялда үзенчә эшләп тә куйды: өмә ясап, чиркәү кирпеченнән фундамент салды.

Көзгә тәрәзәләре белән урам якка караган, гәрәбәдәй сапсары, тигез бүрәнәле йорт калкып чыкты. Яз көне яшьләр үз өйләрендә яши башладылар. Алар күчкәндә мич чыгарылмаган иде — соңрак анысы да булды. Әллә нинди бизәкләр белән сырлап, челтәрләп, верандасын эшләделәр. Күпне күргән бер карт журналист-пенсионер гына, әллә чынлап, әллә шаяртып, күңелгә шом салды: «Халык үзеңә атап өй салмаска куша, анда үзең яши алмассың»,— ди».

Яз уртасында җирдән пар бөркелгән бер көнне кайсыдыр дусты саргылт көчек күтәреп килде. Көзгә ул немец овчаркасына охшаган зур эт булып үсте. Бер танышлары бу йомшак борынны немец овчаркасы диде, икенчеләре овчарка белән кушылган башка токым нәселе дип сүз көрәштерделәр. Ничек кенә булмасын — шәп эт иде. Матур, усал. Хуҗа рөхсәтеннән башка бер генә чит кешене дә ишегалдына кертми. Исеме дә җисеменә туры килеп тора — Барс.

Шулай итеп, яңа нигездә яңа тормыш гөрләде. Әмма көтмәгәндә Барс авырый башлады. Башта арткы сул тәпие йөрмәс булды, соңрак эт ал аякларына гына калды.

Этне каралга килгән мал врачы, паралич, диде. Озак та үтмәде, Барс, бик азапланып, җан бирде.

Мөнирә ханым моны бер дә юньлегә юрамады. Матур фундаментка төртеп, өйгә бәхетсезлек аяк басуын әйтте:

— Менә чиркәү кирпечләре нишләтә...

Ягъфәр әнисенә кул гына селтәде:

— Җыен юк-барга ышанып үтә инде гомерегез.

Озакламый партия шәһәр комитетының беренче секретаре Мәскәүгә укырга китте. Аның урынына башкасын сайладылар. Әмма яңа секретарь шәһәр газетасының промышленность бүлеген җитәкләгән яшь журналист Ягъфәрне нигәдер өнәмәде. Янәсе, газетада промышленность тармагындагы Косыгин реформалары тиешенчә яктыртылмый, эшчеләр коллективында коммунистларның роле турында аз языла һәм башкалар, һәм башкалар.

Сарапулдан ике йөз чакрымлап ераклыкта яңа промышленность үзәге төзелә башлады. Ягъфәрне шунда газета редакторы итеп чакырдылар. Ул, ике дә уйламыйча, комсомол төзелешенә китәргә ризалык бирде. Күпме көч түгеп салган өен генә калдырып китәргә кызганыч булды. Земфирасы да җанга тия:

— Төзеп, мунчага да керә алмадык ичмасам...

Әнисенә охшарга тырышып, кызы өй янындагы чәчәкләрен кызганып йөри.

Фундамент мистикасы турында фикер материалист Ягъфәрнең башына да килми әле. Шәһәр йортыннан бар уңайлыклары булган яңа фатир алу мөмкинлеге җанга рәхәтлек бирә. Аннан килеп, өйләрен дә бушка калдырып китмиләр ләбаса!

Көлеп торган тәрәзәле, сап-сары нарат бүрәнәле, челтәрләп эшләнгән верандалы көяз йортка яңа хуҗалар тиз табылды. Ике балалары булган яшь урыс гаиләсе сатулашып та тормады, Ягъфәр сораган хакка риза булып, сатып алдылар.

Яңа шәһәр Ягъфәрне колач җәеп каршы алды. Килү белән өч бүлмәле фатир бирделәр. Икесенең дә эшләре гөрләп бара, кызлары мәктәптә укый. Яшьлек һәм балачак шәһәрен барып күрергә дә вакыт җитми. Әниләре генә килгәләп яңалыклар сөйләп китә. Бер килүендә ул өйне сатып алган гаиләнең Чайковскига күченеп китүен әйтте. Икенче килүендә әнисе Ягъфәр утырткан алмагачларның коймадан да биегрәк булып үсүләрен сөйләп шатландырды. Чайковскига киткән теге гаиләнең генә язмышы аяныч булган: алар, ирле-хатынлы автомобиль һәлакәтендә һәлак булганнар. Балалары ятим калган. Боларны да әнисе сөйләде. Тик улының кырыс холкын яхшы белгән ана фундамент турында дәшмәүне кирәк тапты.

Мөнирә ханым бер юлы Корбан гаетендә килде. Улы белән киленен күршеләре туган көн мәҗлесенә чакырдылар. Кунактан яшьләр соң кайтты. Мәҗлес булгач, билгеле, әзрәк эчкәннәр дә. Мөнирә ханым икенче көнне сүз арасында кыстырып куйды:

— Дини бәйрәмдә аракы эчү зур гөнаһ, балалар. Аллаһы Тәгалә барысын да күрә, белә...

Дингә чын күңелдән ышанган әнисен үпкәләтүдән куркып, Ягъфәр җавап кайтармады.

Көннәрне бер җепкә тезеп, еллар узды. Ягъфәр тормышта башкалардан калышмады. Гараж төзеде. «Жигули» машинасы сатып алды, бераздан аны яңасына алыштырды. Шәһәр янындагы авылдан егерме биш сутый җире белән йорт сатып алды. Көздән сөрдергән бакчасына бәрәңге утырту нияте белән, «Беларусь» кертте. Нияте бик изге иде — гаиләсен бәрәңге белән тәэмин итә, артыгын хәзерләү конторасына тапшыра, янәсе. Ягъфәр дуслары белән трактор сабаны эзенә бәрәңге салып йөри. Земфирасы өйдә табын әзерли. Сәер, шундый матур көнне берәү дә бакчада күренми? Баксаң, Пасха бәйрәме икән, православныйлар бәйрәм итә, аларга татарлар да кушылган. Һәр өйдә йомырка буйыйлар.

Ягъфәр күрше Василий Семеновичның ишегалдына керүен күреп кала.

Бераздан Земфира йөгереп чыкты.

— Ни булды? — дип сорады Ягъфәр, эштән тукталмыйча.

— Менә күрше әрли, башка көн таба алмадыгызмыни бәрәңге утыртырга, ди. Пасха көнне эшләү зур гөнаһ ул, ди.

Ягъфәр бакчаны яңгыратып, рәхәтләнеп көлде.

— Буялган йомыркаларын ашап, самогонын эчеп тик ятсын. Мин мөселман кешесе, Пасха бармы да юкмы миңа!

— Синең мөселманлыгыңны да әйтер идем инде,— дип, Земфира өйгә таба китте.

Бәрәңге эше бетүгә, ирләр өйгә керде. Өстәл артында булачак уңыш өчен дә, христиан бәйрәме өчен дә тостлар әйтештеләр.

Пасхадан соң ике атна үтүгә, бакчага зур китмән күтәргән ир-ат килеп керде. Хатынын һәм малаен да үзе белән иярткән. Аларның кулында кукуруз орлыгы белән тулы чиләкләр. Теге ир, өйдән берничә адым атлап, җирне үлчәгәч, китмән белән җир чокый башлады. Хатыны белән улы аның артыннан орлык чәчтеләр.

Ягъфәр бакчасы янына килеп тораташтай басып калды. Бераздан һушына килеп кычкырды:

— Әй, мужик, нишлисең син анда?

— Ничек нишлисең? Күреп торасың бит: кукуруз чәчәм.

— Нинди кукуруз? Бу бит минем бакча, мин монда бәрәңге утырттым.

Ул арада ир түш кесәсеннән кәгазь тартып чыгарды.

— Синеке түгел шул. Мә, укы! Сиңа, шәһәр кешесенә, закон буенча сигез сутый гына тиеш. Ишегалдың, каралты кураң белән бергә. Ә син бөтен бакчаны үзләштергәнсең.

Җен ачуы чыккан Ягъфәр йөгереп барып кәгазьне тартып алды. Чыннан да, анда авыл советы рәисе кулы белән авылның алдынгы механизаторына 17 сутый җир өстәмә бирелә диеп язылган. Имзасы да, пичәте дә бар.

— Менә сиңа кодагый...— дип куйды тәмам аптыраган Ягъфәр.— Соң, мин бит бакча тутырып иртә өлгерә торган бәрәңге утырттым.

— Чокып чыгардык инде. Китмәнебез бик очлы бит.

Ягъфәр кызды:

— Оятсыз син. Утырткан бәрәңгемне бир миңа. Күпме көч түктек бит...

— Синең бәрәңгең кирәк тә түгел миңа. Үземнеке җитәрлек. Ходайга шөкер, кырык сутый бакчам бар. Малга ашатырга кукуруз кирәк миңа.

Ике ирнең ачуланышуын ишетеп, күрше Василий Семенович чыгып җитте.

— Ну, нәрсә күршем? Әйттем бит сиңа, дини бәйрәмнәрдә эшләргә ярамый, дидем. Ходайны ачуландырасың, дидем...

Василий Семенович сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, Ягъфәр «шестерка»сына утырып, бар көченә газга басты...

Нәкъ шул көнне Ягъфәр «Огонек» журналын алды. Анда Мишель Нострадамусның тормыш юлы һәм эшчәнлеге хакында зур мәкалә басылган. Укып чыккач, Ягъфәрнең йөрәге чемердәп куйды. Бөтен тормышы, кино тасмасын әйләндергәндәй, күз алдыннан үтте. Бәрәңге утыртуын да, сөекле Барсының үлемен дә искә төшерде. Чиркәү стенасын лом белән ваткан мизгелгә килеп җиткәч, маңгаена борчак-борчак тир бәреп чыкты.

— Кирәк бит, ә,— дип пышылдады ул, өйдәгеләр ишетмәсен дигәндәй.— Ничек итеп бөтен гомеремне юрауларга, халык сүзенә ышанмыйча үткәргәнмен мин? Урысның Фома Неверующие кебек яшәлгән бит!

Нострадамус рәсеменә текәлеп, Ягъфәр озак утырды.

— Ну, Мишка, моңа кадәр кайда булдың соң син? — дип үз-үзенә сөйләнеп тә алды.

Ә Мишка Нострадамус үзенең сихерле күзләре белән Ягъфәрне бораулый иде...

Озакламый боз китеп, Камага метеорлар төште. Ягъфәр дә су юлы белән яшьлек шәһәрен күреп килергә уйлады. Сарапулдан чыгып киткәненә сигез ел тулган иде. Әнисенең өендә чәйләп алгач, үз куллары белән салган өен карап кайтырга булды.

Вакыт рәхимсез шул. Капка-коймалар ямьсезләнгән. Алма бакчасы да каралмаган. Бөтенләй чит кешеләр ишек ачты. Ягъфәр хуҗаларны үзе белән таныштырды, шушы өйне салган кеше икәнлеген әйтте.

— Яхшы итеп, матур итеп төзегәнсең бу йортны. Тик бәхетле нигез түгел бу. Хуҗалары еш алышына, төрле бәхетсезлекләр, авырлыклар килеп тора. Сездән соң бу нигездә без алтынчы гаилә,— диде йортның яңа хуҗалары.

Ягъфәрнең нигәдер тыны кысылгандай булды. Моннан тизрәк китәсе килде. Карашы өйнең фундаментына төште. Ул һаман элеккечә матур, төзек.

— Бәлки, өегезне изге сулар сибеп, чистартып алырга кирәктер?

Бу сүзләрне ишеткән карчык кызып китте:

— Ни сөйлисең син? Без бит мөселман кешеләре!

— Зинһар, гафу итегез.— Ягъфәр татарчага күчте.— Сезне христианнар дип уйлаган идем. Алай булгач, мулла чакырып, Коръән укытыгыз, азан әйттерегез.

— Үзебез дә шулай дип торабыз, улым.

Ягъфәр өч көн әнисе янында кунак булды. Хезмәттәшләре, дуслары, туганнары белән очрашты. Улындагы үзгәрешләрне әнисе бик тиз сизеп алды. Ягъфәр ничектер дингә, ырымнарга ышана башлаган. Ашаганнан соң, өстәлдән ипи валчыкларын җыя. Элек бер дә алай итми иде. Сөйләшкәндә «Алла боерса» сүзен күбрәк әйтә башлаган. Бу үзгәрешләр әнисенең күңеленә бик хуш килде. «Яшь үзенекен итә, улым да акылга утырган»,— дип сөенде әнисе. Пристаньда озатканда, кул болгап, имин юл теләде:

— Хәерле юл сиңа, имин йөр, улым!

Ягъфәргә кайсы Мишка: Нострадамусмы, әллә Горбачевмы күбрәк йогынты ясагандыр, әйтүе кыен. Әмма туксан беренче елда буласы ГКЧПны алдан сизде ул. Ырым һәм юрауларга ышануы шул дәрәҗәгә җитте ки, редакциядәгеләр үзеннән көлә үк башладылар. Тормышы да әле бер, әле икенче сюрпризны ясап кына торды.

Коммунистлар партиясе бетеп, СССР таркалу хәбәрен Ягъфәр партия шелтәсе белән каршы алды. Кирәк бит, 1991 елның язгы чәчү эшләре Пасха көнендә башланды. Бу көнне газетада берәр хата гына чыкмасын иде. Берүк Ходай сакласын дип йөрде көнозын баш редактор Ягъфәр. Газета битенә зур итеп «Вовремя начнем и кончим полевые работы» дип баш язарга ниятләделәр.

Бер көн алдан Ягъфәр, газетаның җаваплы хезмәткәрләрен җыеп, махсус киңәшмә үткәрде. Пасха көнендә эшлибез, җәмәгать, бик игътибарлы булуыгызны сорыйм, диде.

Әмма бу дөнья син уйлаганча гына бармый бит әле. Мондый җаваплы көннәрдә газетада хата китә шул. Иң гаҗәбе: бар да тикшерә, кат-кат укый, корректор төзәтә, бүлек мөдире, җаваплы секретарь, баш редактор караганнан соң гына газета бастырыла. Шулай энә күзеннән үткәргәч тә калган хаталар редакторны картайталар да инде.

Пасха көнендә дә шулай газетаны кат-кат тикшерделәр. Ягъфәр, кул куеп, тыныч күңел белән өенә китте.

Дүшәмбе эшкә җыенып йөргәндә, иртүк телефон шылтырады. Горкомның беренче секретаре үзенә чакыра. Нәрсә булды икән? Ягъфәрнең йөрәге жу итте.

Беренче сүзне коры башлады:

— Нәрсә, половой гигант?

Ягъфәрнең тавышы калтырап чыкты:

— Аңламадым.

— Ул аңламаган, имеш. Мә, укы! — Ягъфәр алдына газетаны җәеп салды.

Анда ике биткә зур хәрефләр белән «Вовремя начнем и кончим половые работы» дип язылган иде.

Баш редактор телсез калды. Бер мәлгә күз аллары караңгыланып китте. Бераздан телгә килеп, мәрт йокысыннан айныган кеше шикелле ышанычсыз гына әйтте:

— «О» хәрефе каян килгән монда? «Полевые» сүзе иде ләбаса...

Баш редакторга каты шелтә белдерелде. Бу горкомның бетерелер алдыннан соңгы шелтәсе булды шикелле һәм ул шелтәне күптән түгел генә бернәрсәгә дә ышанмаган, бүген исә халык юрауларының һәркайсын үтәп барган, аларга табынган Ягъфәр алды. Соңгы вакытта иренә Земфира да: «Каян ишетеп бетерәсең син боларны?» — дип шакката.

...Ире сөекле портфелен күтәреп, әле генә эшкә чыгып киткән иде. Инде борылып та кергән. Земфира аптырап:

— Син нәрсә? Ни өчен кире борылдың? — ди.

— Күрше Наталья буш чиләге белән каршыма очрады.

— Хәзер көне буе өйдә утырырга җыенасыңмы?

— Юк ла, көзгегә генә карыйм да чыгып китәм.— Үзе күз кырые белән генә Земфираны күзәтә.— Сиңа әйтәм, өстәлне кәгазь салфетка белән сөртмә, ачуланышуга ул.

Бүген дә Ягъфәр ашыкмыйча гына ишек ачты, игътибар белән як-якка карады, Васьканы күрмәгәч, подъездан чыкты. Башта сул якка, соңыннан уң якка төкерде, үзенә хәерле юл теләп, күпне күргән «туйдыручысын»-портфелен дәрәҗәле генә тотып, редакциягә китте.

* * *

Ягъфәр командировкасыннан икенче көнне кич белән кайтты. Бәдрәфкә кереп чыкты, кулын юып, сөлгегә сөртте. Земфирасына ничек итеп йөреп кайтуы турында сөйли башлады:

— Менә син бер дә ырымнарга да, мистикага да ышанмыйсың. Бүген юлда бер журнал укыдым. Пушкин турында бик кызык әйбер язганнар.

— И Аллам, Пушкинга ук барып җиткән,— дип кулларын җәеп җибәрде Земфира.

— Тыңла, сөйлим,— дип үзенекен тукыды Ягъфәр.— Александр Сергеевич 1837 елда үлгән. Аның «гений чистой красоты», «вавилонская блудница» дип йөрткән сөеклесе Анна Петровна Керн шагыйрьдән соң да дүрт дистә ел яшәгән. Ул 1879 елда Мәскәүдә вафат була. Керн мәете салынган гробны зи-

ратка алып барганда, Мәскәүгә Пушкин һәйкәлен китерәләр икән. Шулай итеп, Керн белән Пушкин тагын очрашалар! Менә бит ничек...

— Әйе, чыннан да кызык дөнья...

Ул да булмый, Земфира оста гына итеп сүзне үзенә борып куя:

— Әй, син, минем Пушкиным, әйт әле, кайчан зарплата алып кайтасың? Акча мәсьәләсе бик зур проблемага әйләнде бит әле...

— Шушы көннәрдә,— дия Ягъфәр, изге темадан көндәлек сүзгә күчкән хатынына канәгатьсезлек белдереп.— Сиңа ничә әйтергә була, унитаз капкачын ябып йөр, дип. Колагыңа элмисең дә. Унитаз капкачын ябык тотсаң, өйдә акча саклана, ди халык. Ничә керсәң дә авызын шар ачып утыра. Акча турында сөйлисең, җитмәсә...

## Биш бегемот

Үзегез беләсез, зур авылларда күп кенә кешеләргә кушамат бирәләр. Бәлки, бер үк исемле кешеләр күп булгач, буталмаскадыр. Кушаматны һич тә уйламаганда чәпиләр дә куялар. Шуннан соң кушамат бөтен гаиләңә яисә үзеңә ябыша да кала!

Бер зур гына мишәр авылында да берничә Сәлахетдин атлы кеше бар иде. Салихҗаннар да шактый. Боларны ничек аерырга? Кыскасы, кушамат кирәк. Ансыз яшәп булмый.

Көннәрнең берендә бер Сәлахетдин көтмәгәндә «Үпкә Сәләй» булып китмәсенме! Әйе, Сәләй генә түгел, ә Үпкә Сәләй!

Кушаматның тарихы болай икән. Сәлахетдин көмешкә куып ятканда, сиздерми генә күрше Салихҗан килеп кергән һәм арттан елмаеп кына карап тора икән. Исен сизеп кергәндер инде. Сәлахетдин кисәк кенә борыла да:

— Ой, йөрәгем чыгып китте. Участковый басып тора дип торам...— ди күршесенә.

— Син нәрсә, хәзер үпкә белән генә яшәрсең микәнни? — дип авызын ера күршесе Салихҗан.

— Шулай булып чыга инде,— ди Сәлахетдин уйламыйча гына һәм стаканга күрше хакын салып бирә.

— Ну, күрше, ясап та куясың инде! «Гимаевский»дан да әйбәтрәк бу! — дип, мактый-мактый Салихҗан ике стакан көмешкәне күтәреп куя да чыгып китә.

Урам аша гына утыргычта икенче күршеләр ләчтит сатып утыра. Салихҗан алар янына барып утыра да яңалыкны әйтеп куя:

— Карагыз әле! Сәлахетдин, безнең күрше Сәләй, йөрәксез яши икән, үпкә белән генә...

Шул ук көнне бу «яңалык» авылның бөтен урамыннан тәгәрәп китә. Кичкә таба Сәлахетдин абзый Үпкә Сәләй була да кала.

Кичен Салихҗанны капка янында очратып, Сәлахетдин күршесенә бик усал итеп карый да, ата каз сыман чыжлап:

— Ну и бегемот икәнсең син! — дип төкерә һәм шап итеп капкасын яба.

Бу сүзгә экзотик хайваннар һәм җәнлекләр турында берни белмәгән Салихҗан башын артык ватып тормый. Телевизордан бара торган «В мире животных» дигән тапшыруга игътибар иткәне юк аның. Ул аны, бегемотны, берәр чит ил телевизоры яисә үтүк дип уйлый. Бар бит шуңа охшаш исемле — «Бош» дигән җиһазлар.

Икенче яктан, Салихҗан белән аның гаиләсе моңа кадәр Песи, Песиләр дигән кушамат йөртәләр иде инде. Мишәрчә — мацы. Салихҗан абзыйны Ата Мацы дип йөртәләр. Кайчак Бур Мацы дип тә җибәрәләр. Хатынын Ана Мацы, диләр.

Авыл халкы телгә бик хәтәр. Мишәрләр бигрәк тә! Телевизордан мәче ризыкларын мактый башлагач, Салихҗан абзыйның үзенә һәм гаиләсенә «Вискас» дигән замана кушаматы да өстәделәр. Карагыз, нинди матур булып яңгырый. Вискас Салихҗан. Бур Вискаслар!..

Бу Песи-Мацы-Вискас дигән кушаматларның тамыры тирән. Салихҗан абзыйның һәм гаиләсенең бер гадәтләре бар: җай килгәндә колхозныкынмы, бүтән җирдәнме, бур песи өстәлдән ашамлык чәлдереп алган сымак, кулга нәрсә эләксә, шуны элек ат арбасына, хәзер инде автомобиль багажнигына ыргытырга гына торалар. Шуңа күрә инде боларга хәзер дә Бур Песи кушаматы тагылды. Шул кушамат аркасында Салихҗанның «В мире животных» дигән программаны принципиаль рәвештә телевизордан бер тапкыр да караганы булмады. Шуңа күрә ул бегемотның хайван икәнен дә белми калды. Үпкә Сәләй моңа «Бегемот» дигәч, артык пошынмады да.

Бу вакыйгадан соң биш ел үтте. Бегемот сүзе күршеләр арасында бөтенләй онытылды. Үпкә Сәләй белән Мацы Салих та сирәк-мирәк кенә исәнләшә башладылар. Кыскасы, Үпкә Сәләй әйтте, Мацы Салих онытты.

Ләкин сентябрь азагында, кырда игеннәр җыелып, бакчада бәрәңгеләр алынып беткәч, Мацы Салихын райсобеска чакырып, Кисловодски санаториена бушлай путевка бирү турында әйттеләр. Карт

Мацы шундук үзенең ризалыгын белгертте, чибәр кызларга рәхмәтләрен әйтте. Акча түлисе булса, бернинди санаторийга бару турында уйламас та иде. Буш булгач, ничек баш тартасың?

Салихҗан районнан кайтып җиткәнче, мишәр авылы гөрли һәм шау-шу килә: «Карагыз әле, Ата Мацы курортка китә икән. Алай-болай гына түгел, Бур Мацыга путевканы бушлай биргәннәр! Мацы мацы инде ул...»

Көннәрдән бер көнне Салихҗанның бер Вискас малае Казанга барып әтисенә Кисловодскига барыр өчен поездга билет та алып кайта. Вакыты җиткәч, Казан вокзалына илтеп тә куя. Ә Салихҗан Бур Мацы, Бур Вискас буларак, күрсәтми генә юл сумкасына ике ярты көмешкә тыгып куя.

Юл Мәскәү аша була. Кич белән Салихҗан «Татарстан» поездында башкалага юл тота. Күңеле күтәренке. Юлдаш күршеләр тимер юл чәен чөмергән арада, Салихҗан, бур песи сыман, өйдән алган яртыларның берсен урлап кына кәгеп бетерә дә шат күңел белән йокларга ята.

Мәскәүгә килеп җиткәндә, иртән: «Тиздән бәдрәфне ябам. Торыгыз!» — дип, проводник Салихҗанның аягын тарткалый.

Поезд Мәскәүдән Кисловодскига кич кенә китәсе икән. Нишләргә? Кичәге яртыдан башы ярыла. Кисловодскига да барасы килми башлый. Вокзал буфетына кереп башын төзәтә. Исни-исни вокзал сосискасын чәйни. Күңеле күтәрелеп китә, яшисе килә башлый. Кисловодскига да барасы килә. Ләкин кичкә чаклы буш вакытны кая куярга?

Шул вакытта карт Вискасның башына бер бик шәп фикер килеп төшә. Бу фикергә куанып, ул буш вакытын Мәскәү зоопаркында үткәрергә була. Башта метро чоңгылына чумып, сораштыра-сораштыра озакламый биек чуен коймалы зоопаркка да килеп җитә, рәшәткә артында утырган җәнлекләрне күзәтә башлый.

Менә сары, озын, пөхтә койрыгын сөйрәп төлке йөри. Салихҗан аңа сокланып карап тора да кисәк кенә авылдашы Төлке Сабри исенә төшә. Шаярып кына:

— Исәнме, Сабри? — дип дәшеп куя курортчы карт Вискас.

Төлке Салихҗанга карап тора.

— Әле һаман да хәйләкәрлисеңмени, абзый? — ди аңа Вискас. Чыннан да, авылдашы Сабри хәйләкәрлеге белән билгеле була.

— Бәтәч, исәнме, Хөсәен әзи! — ди кинәт кенә Вискас Салихҗан, күрше рәшәткә артындагы ата кабан дуңгызын күргәч.— Әле һаман да пычрак икәнсең, әзи. Синең язмышың шундый шул. Бөтен кеше маймылдан яралган, синең тамырың гына чучкалардан башланып киткән шул...

Бераз бара торгач, Вискас маймыллар читлегенә килеп җитә һәм шундук авылның түбән очындагы Идрисләр гаиләсе исенә төшә. Аларның кушаматы Маймыл иде.

— Исәнме, Саниюшка! — дип дәшә ул бер маймылга, Идриснең хатынын күз алдына китереп.— Сине нигә рәшәткә артына яптылар? Чибәрлегең өчендер инде. Кая соң синең Идрисең?

Карт Вискас бу сүзләрне әйтеп тә бетерә алмый, рәшәткәнең арт ягыннан култык асларын кашый-кашый зур гына маймыл килеп чыга. Аның артыннан вак-төяк маймылчыклар ияргән.

— Менә сиңа Идрис! — дип куя Салихҗан, бу маймыл көтүен күреп.— Ә-ә, сине дә рәшәткә артына япканнар икән. Дөрес шул, колхозны күпме таларга мөмкин?..

Карт Мацының күңеле күтәрелә. Рәшәткә артында авылдашларының кушамат хуҗаларын очратып, алар турында ачыктан-ачык бөтен уйларын әйтеп бетерә.

Бара-бара Салихҗанның «Семейство кошачих» дигән күрсәтмәгә күзе төшә. «Әһә, монда мацылар булырга тиеш, тугандашлар, имеш»,— дип уйлап куя ул.

Чыннан да, бер читлектә тигр утыра.

— Монысы мин үзем инде,— ди Салихҗан.

Икенче читлектә күзләрен ялтыратып, кырын-кырын гына карап, пантера утыра. «Монысы минем карчык,— дип уйлый Салихҗан.— Карале, ничек итеп карый? Валлаһи, минем карчыгым карашы...»

Күрше читлекләр эчендә селәүсеннәр һәм башка мацы «туганнар» утыра.

— Болары минем балаларым инде,— дип шаярып куя Салихҗан.— Матур җәнлекләр исемен кушамат итеп биргәннәр икән...

Йөри-йөри Салихҗан үзен күп кенә авылдашларын очратып сөйләшкәндәй тоя башлый. Ябалак, байгыш, күркә, казны да күрә. Кыскасы, ярты авыл кешеләрен күргәндәй була. Җәнлек кушаматы йөртмәгән Җәбрәй Ибрай, Алаша Апуш, Бастырык Гыйльми, Камыт Хәмит, Аркан Арыслан, Бульдозер Атаулла, Көпчәк Сәхип сыман авылдашлары гына тирән һәм җылы күңеленнән вакытлыча чыгып тора.

Шундый күтәренке күңел белән курортчы Вискас бер рәшәткә янына килеп җитә. Караса, исе китә: рәшәткәгә зур хәреф белән «Бегемот» дип язып куйганнар! Шул минутта биш ел элек ут күршесе Үпкә Сәләйнең аңа «Бегемот» дип әйткән сүзе хәтеренә килеп төшә.

— Әһә! — дип, Салихҗан кулы белән ботына чаба да, кем беләндер серләшкән шикелле, пышылдап кына тезеп китә.— Әһә, менә нинди икән ул бегемот. Кара әле, нинди мыскыллы кушамат тагарга мәтәшкән миңа Үпкә Сәләй! Ярый әле ябышмады. Нинди мәсхәрә булыр иде...

Салихҗан рәшәткәгә береккәндәй сыланып, күзләрен биш итеп, шул хайванны күзәтә башлый.

— Менә сиңа ичмаса бегемот тек бегемот! Үзе зур, үзе юан. Мышнап тора...— Курортчы Вискас исе китеп хайванны күзәтә-күзәтә дә, кырынырга дип алган көзгесенә карый башлый: — Чак кына охшаганмын да икән шул...

Чыннан да, Салихҗанның да бите кырылмаган. Хайванның күзләре искиткеч зур, чәчрәп чыгардай булып тора. Салихҗанның да күзләре махмырдан күкәй чаклы булган. Аптырагач, үзенең муенын, маңгаен тотып карый. Бегемотның маңгае юк икән, өске яктан башы муенга әйләнеп киткән. Салихҗанның да шулайрак булып чыккан. Кара әле, колаклары ничек? Да-а, бәләкәй генә икән шул. Салихҗан үзенең колакларын топкалый-топкалый көзгедән карый. Аның да колаклары бик кечкенә икән. Уф! Карагыз әле, бегемотның авызы нинди зур! Салихҗан зур итеп авызын ача да көзгегә бага. Бегемотныкы чаклы ук түгел инде түгелен, барыбер, үзенең авызы да шактый зур икән шул. Исән калган тешләре дә тәмәке тартудан саргаеп, бегемот тешләренә охшаган.

Салихҗан, аптырагач, көзгесен аскарак төшереп карый. Корсагын сыйпап:

— Бегемотныкына охшаган икән шул,— дип куя.

Аякларына караса, бегемотның да, Салихҗанның да аяклары шактый юан һәм кыска булып чыктылар.

Салихҗанның бөтенләй кәефе китә. Курорт кайгысы калмый:

— Менә сиңа Үпкә Сәләй! — дип куя ул.— Самогончы мөртәт! Тапкан кушамат бирергә, ә! Юк! Бу мыскылны болай калдырып булмый! Биш ел элек әйтелгән булса да.

Ачуыннан Салихҗан берникадәр башын кая бәрергә белмәгән шикелле аптырап тора да зоопарктан тимер юл вокзалына ыргыла. «Түлке өйгә, түлке авылга!» — дигән уй боргалый аның миен. Ул, тиз генә кайтып, күршесе Үпкә Сәләйне судка бирергә, дигән фикер белән билетлар кассасына атылып килеп керә һәм Казанга баручы беренче поездга билет ала. Курорт мәсьәләсе бөтенләй баштан чыга.

Поездда — автобуска. Менә якты туган район үзәге. Менә суд бинасы — гаделлек йорты! Секретарьга кереп кәгазь ала да гаризаны язып та бирә. Имеш, биш ел элек аны авылдашы Сәлахетдин мыскыл итте, Бегемот дигән кушамат бирергә маташты. Шуны җавапка тартуны сорыйм, янәсе. Мораль зыян китергән өчен биш мең сум акча түләсен! Гәҗит аркылы гафу үтенсен! Бераз уйлап торганнан соң гаризаны яңадан кучереп яза һәм биш мең урынына «ун мең» дип өстәп куя.

Салихҗан авылга юл уңаена туры килгән машина белән төнлә генә кайтып төшә. Кешегә күренми генә судка чакыру кәгазен көтә башлый. Авылдашлары инде моны курортта ял итә, сәламәтлеген ныгыта дип уйлый.

Көннәрдән бер көнне Салихҗан судка чакыру кәгазе ала. Шундый ук кәгазьне күрше Үпкә Сәләй дә ала һәм аптырап кала: «Нинди чакыру бу?!»

Судка күршеләр бер вакытта килеп керә.

— Ба-а! — ди Үпкә Сәләй, ут күршесе Салихҗанны күреп.— Син монда нишләп йөрисең?! Син бит курортта булырга тиеш...

— Тиеш, тиеш... Кергәч белерсең нәрсә тиеш икәнен,— ди Салихҗан.

Озакламый судья боларны үзенең бүлмәсенә чакыра һәм шунда Салихҗан гаризасын укый.

— Әйтегез, сез күршегезне «Бегемот» дип мыскыл иттегезме? — дип сорый судья Сәлахетдиннән.

— Билләһи, хәтерләмим,— дип җавап бирә Үпкә Сәләй.

— Әйтте, әйтте! — дип, урыныннан сикереп тора Салихҗан.— Биш ел элек әйтте!..

— Менә сиңа былтыр кыскан,— ди судья.— Биш ел элек сез әйткән мыскыл сүзегезне тикшереп, мин дә бегемот булыйммы инде?! Күп вакыт узу сәбәпле, мин бу гаризаны карамыйм. Болай гына килешегез дә тату гына яшәгез!

Авылдашлар авылга кайтып төшәләр. Икенче көнне үк авылда «Бегемот» яңалыгы тарала. Үпкә Сәләйгә дә, карт Мацы Салихҗанга да ныклап Бегемот кушаматы берегә. Район судьясын да Бегемот судья дип йөртә башлыйлар.

Шул вакытта Вискас, Бегемот Салихҗан, район судьясы карарына риза булмыйча, республиканың Югары судына гариза язып җибәрә. Имеш, район судьясы аның эшен дөрес карамаган.

Озакламый авылдагы ике Бегемотка да Казаннан судка чакыру кәгазе килеп җитә. Күршеләр башкалага юл тота.

Башкала судьясы Салихҗанның гаризасын укып чыккач көлеп җибәрә:

— Нәрсә сез, абзыйлар, картаеп беткәч башыгыз зәгыйфьләнә башладымы әллә? Сезнең «Бегемот» эшегезне карап, мин дә бегемот булыйм микән?..

Бераз ярдәмчеләре белән киңәшләшеп алгач, судья болай ди:

— Шундый карар чыгарам: Сәлахетдин абзыйга кешене мыскыл итеп Бегемот кушаматы биргән өчен бер мең сум штраф түләргә! Ул газета аша күршесеннән гафу итүен сорарга тиеш...

Озакламый район газетасының соңгы битендә түбәндәге белдерү басылып чыга: «Мин күршем Салихҗанны Бегемот дип ялгыш әйткәнмен. Ул Бегемот түгел. Салихҗаннан газет аркылы гафу итүен сорыйм».

Бу белдерүне укыгач, бөтен укучылар шаккатып кала. Имеш, мондый белдерүне Бегемот редактор гына газетка бирә ала. Шулай итеп, бегемотларның саны бишкә җитә. Бер көтү бегемот! Кыскасы, бегемот Африкада гына бегемот түгел икән. Ул безнең авыл-шәһәрләрдә дә бегемот булып кала...

## Ике якка да выжт…

Шәһәрдә бер татар бәндәсе туа һәм ул таш урамнарның бөтен сыйфатларын җыеп үсә. Яхшы гына урта мәктәпне тәмамлый. Политехник институтта укып, инженер дипломы ала.

Бу хәл социализм белән капитализм бер-берсен «үтүкләп» торган чорларда була. Әгәр онытмасагыз, ул көннәрдә заводларда НОТ (научная организация труда) дигән төшенчәнең бик популярлашып киткән вакыты була. Кызыл дипломлы татар егетен зур заводка шушы НОТ дигән хезмәт бүлегенә эшкә җибәрәләр. Егет техник һәм экономик тармакта бик зур уңышларга ирешә. Күп кенә рационализаторлык идеяләрен тәкъдим итә һәм тормышка ашыра. Газетларда аның турында язылган очерклар чыга башлый. Тора-бара бу егет зур начальникларның күз уңына килеп эләгә. Кыскасы, бөтен республикада атаклы НОТ инженеры булып китә.

Реформалар башланып, НОТлар бетә башлагач, бу билгеле яшь инженерны бер татар районына глава итеп җибәрәләр. Моңа кадәр аның шәһәрдән чыкканы булмый. Татар авылы түгел, урыс авылында да булганы юк.

Районда моңа олы кабинет һәм бик зур кара «джип» машинасы бирәләр. Гади халык күз күрмәгән бу машинага кушамат чәпәгән — «К-700».

Авылларда шаулап-гөрләп Сабантуйлар үтә. Халык печән чабарга керешә. Районның яңа хакиме, авылларга чыгып, печән чабуның барышын тикшермәкче була.

Бер зур авылның болынына килә дә, «К-700»тан төшеп, ирләрнең печән чабуын күзәтә. Көннәр матур. Кояш җылы гына елмая. Кигәвеннәр скрипкаларын тарталар. Тау башында авыл күренеп тора.

— Эх,— ди хаким, үз-үзенә генә пышылдап.— Мужиклар печәнне матур чабалар: выж, выж, выж!

Бераз карап тора да тагын пышылдый:

— Матур чабалар. Ләкин дөрес чапмыйлар. Выжт та выжт. Нигә болар бер якка гына выжлыйлар соң? Кире ягы холостой ход булып чыга бит. Нигә боларның чалгылары ике якка да выжламый? Бу бит НОТ таләбенә туры килми.

Глава-хаким чалгычылар янына бара да күкрәк тавышы белән исәнлек-саулык сораша:

— Ну, ничек баһадирлар, яшәп, булдырып буламы?

Бер телгә беткәне аптырамыйча гына җавап бирә:

— Яшәп тә ятабыз, булдырган чак та бар...

— Менә,— ди глава,— печәнне матур чабасыз. Ләкин дөрес чапмыйсыз...

— Дөресе ничек була икән соң аның? — ди теге печән чабучы тел остасы.

— Дөресен колхоз рәисеннән белерсез,— ди хаким һәм «К-700»ына утырып авылга таба юл тота.

Идарәдә глава-хаким колхоз рәисен өшкертә башлый:

— Печән чабучыларың дөрес чапмыйлар. Бер якка гына выжлыйлар. Син боларга срочно ике якка чаба торган чалгы ясап бир, панимаешь. Выжт сул якка, выжт уң якка. НОТ буенча эшләргә кирәк, панимаешь. Менә сиңа бер тәүлек срок. Мастерскоеңа әмер бир. Өлгермәсәң, Япониядәге мамаңны чакырып кайтарырмын. Япона мамаңны күрерсең...

Икенче көнне глава-хаким тагын, үзенең «К-700»ына утырып, бу авылның болынына килеп төшә һәм сокланып күзәтә башлый. Ирләр печәнне аның тәкъдиме, кичәге НОТ инженеры тәкъдиме буенча чабалар. Ике яклы чалгы тотканнар: выжт сул якка, выжт уң якка. Бераз сокланып карап торганнан соң, глава-хаким пышылдап куя:

— Матур чабалар. Ләкин дөрес чапмыйлар.

«К-700»ыннан төшеп район җитәкчесе печән чабучылар янына килә һәм сәлам бирә:

— Ну, ничек баһадирлар, яшәп, булдырып буламы?

Теге тел бете җавап бирә:

— Яшәвен яшибез әле. Булдырып булмый башлады. Бу чалгыдан соң.

— Менә,— ди җитәкче,— чабуын матур чабасыз. Ләкин дөрес чапмыйсыз. НОТны тулысынча кулланмыйсыз.

— Дөресе ничек була соң аның? — ди теге тел бете.

— Дөресен рәисегездән белерсез,— ди глава-хаким һәм, «К-700»ына утырып, авылга таба китеп бара.

Идарәгә керү белән, район җитәкчесе рәисне кабат пешерә башлый:

— Дөрес чапмыйлар. НОТ буенча эшләмиләр.

— Ничек инде дөрес булмасын,— ди рәис.— Төне буе бөтен авыл белән ике яклы чалгылар ясадык.

— Барыбер НОТны куллану җитеп бетми әле. Печән чабучыларның арт ягына тырма әләктер...

— Эшлибез,— диде рәис.— Иртәгә үк бөтенесенә дә тырма эләктерәбез. Япона мамадан башка сүземне бирәм...

Икенче көнне төш алдыннан болынга, үзенең «К-700»ына утырып, район җитәкчесе килеп төшә. Машинадан чыкмый гына сокланып күзәтә. Ирләр тулысынча НОТ буенча печән- чабалар: чалгылар выжт сулга, выжт уңга. Арттан тырма да үз эшен эшләп бара. Кыскасы, полный НОТ. «К-700»ыннан төшеп, глава-хаким чалгычылар янына юнәлә. Шул вакытта ирләр район җитәкчесен күреп алалар да, чалгыларын-тырмаларын ташлап, пыр туздырып әрәмә ягына йөгерәләр. Болар артыннан кычкыра-кычкыра район җитәкчесе дә йөгерә башлый:

— Иптәшләр! Сез кая качасыз? Мин бит сезнең главагыз.

Тегеләр йөгерүләрен дәвам итәләр. Болар артыннан мышный-мышный район җитәкчесе йөгерә.

Печән чабучылар, хәлдән таеп, әрәмә кырыендагы аланга тәгәриләр. Алар артыннан көчкә-көчкә глава да килеп егыла.

— Якташлар,— ди бу, көчкә сулыш алып.— Нигә сез миннән качасыз? Мин бит сезнең район җитәкчесе...

— Менә шуңа да качабыз инде,— ди теге тел бете.— Без сезне алдан чалбар каешына фонарь элеп куеп, НОТ буенча төнлә дә печән чабарга кушар дип уйлаган идек...

# Актанышта — метро

Беренче апрель көнне «Яңа гасыр» радиосыннан яңалыклар тапшыралар, имеш, Мөслимдә трамвай юлы салганнар. Анда кешеләр рәхәтләнеп трамвайга утырып кына йөриләр икән.

Актанышта берничә ветеран бу хәбәрне ишетеп хәйран кала. Ничек инде Мөслимдә трамвай йөри, ә Актанышта автобус та юк? Кайда дөреслек тә, кайда гаделлек?!

Бабайлар, җыелышып, Актаныш районының хакимият башлыгына киләләр һәм зарлана башлыйлар:

— Мөслимдә трамвай йөри башлаган. Нишләп Актанышта автобус та юк? Актанышлылар беренче булып трамвайга лаек. Республикада беренче булып авылларга газ кертүне башладык, беренче булып бу эшне бетердек. Кара әле, ел саен бер гектардан кырык центнердан артык уңыш җыябыз. Җитмәсә, Актаныш — Президентның туган районы. Ә трамвай юк. Нинди зур кимчелек, нинди мәсхәрә. Бигрәк тә мөслимлеләр алдында.

Район хакимият башлыгы бабайларны зур ихтирам белән тыңлый һәм бик туры җавап бирә:

— Нигә, бабайлар, болай нык борчыласыз? Менә без быел Адай авылында трамвай керттек. Беренче апрельгә эшен бетердек. Трамвайга утырып Асаф Вәлиев «Трамвай кузгала» дип җырлап йөри...

Бабайлар кызып китәләр:

— Нигә аны Адайда эшләдегез? Башта трамвайны район үзәгендә, Актанышта җибәрергә кирәк иде...

Хакимият җитәкчесе сиздермичә генә елмаеп куя һәм вәгъдә бирә:

— Бабакайларым, сүз бирәм: бер ел эчендә Актанышта трамвай юлы салабыз, чешский вагоннар җибәрәбез. Бу эшне киләсе елның беренче апрель көнне төгәллибез. Шул көнне, беренче апрель көнендә, сезне трамвайда утырып йөрергә чакырырмын...

Бабайлар күтәренке күңел белән таралалар.

Мин бу сүзләрне ишеттем дә үземнең проектымны тәкъдим иттем. Тапкансыз, имеш, Мөслим. Тапкансыз анда трамвай! Без Актанышта метро салабыз. Запросто! Бу эш монда бик җиңел булачак. Яңа район үзәге тау башында урнашкан. Хакимият урнашкан бина яныннан чокып китәбез. Беренче тукталышны Ирмәш авылы тирәсендә ясыйбыз. Чөнки монда ел саен районның гаҗәеп матур Сабан туен уздыралар. Ак костюм һәм ак босоножка гына киеп, метрода Сабантуйга килеп төшәбез. Менә шулай итеп, Актаныш таулары астында нинди ак бәхетләргә ирешәбез.

Икенче тукталышны Куян авылында ясыйбыз. Өченчесен Илчебайда, дүртенчесен Уразайда, бишенчесен Әҗмәт авылы башында эшлибез. Бу тукталышта бик матур мәрмәр тактага язып кызыл гранит стенасына элеп куябыз: «Бу урында социализм вакытында бик матур манаралы мәчет булган. Ул мәчеттә башлангыч мәктәп булган. Монда бу китап авторы бишлегә генә укыган».

Аннан соң Шәбез елгасы аркылы челтердәп торган күпер ясыйбыз һәм алга таба, чокып-казып, Бурсык авылына җитәбез. Беренче линияне Мәсәде авылында, Агыйдел елгасы буенда вакытлыча туктатып торабыз. Акча күбәйгәч, тагын да чокый башлыйбыз.

Метроның беренче линиясен 31 февральдә бетерәбез. Аннан соң Агыйдел буенда шашлык әзерлибез, зур банкет ясап җибәрәбез һәм бер ай гулять итәбез. Канишно, шундый зур эш эшләгәч, имеем полное право. Банкет — изге эш!

Беренче апрельдә теге бабайларны һәм бүтән якташларны җыеп, метро вагоннарына төялеп, Актаныш үзәгенә килеп төшәбез. Безне хакимият башлыгы һәм чибәр кызлар матур чәк-чәк белән каршы алалар. Зур митингтан соң тагын банкет башлана. Әлбәттә, банкет — изге эш! Ничек инде банкетсыз.

Беренче апрель көне уңаеннан бик каты гулять итәбез. Имеем полное право. Актаныштa — метро!

## Әтәчләрне өйләндерәбез…

Актаныштa шаулап-гөрләп мәдәният, әдәбият һәм сәнгать көннәре бара. Бик матур итеп төзелгән «Яшьләр» һәм «Игелек» үзәкләрен күреп чыккач, районның искиткеч матур мәдәният йортына килдек. Биредә балалар өчен сәнгать мәктәбе, зур гына китапханә һәм ЗАГС бүлеге дә урнашкан икән. Бөтенесе хәйран калырлык күңелле генә эшләп яталар. Бигрәк тә загс бүлегендә кәефебез нык күтәрелде.

Бүлекнең мөдире, яшь кенә туташ-ханым матур итеп сөйләп җибәрде:

— Монда, загска, никахларын рәсмиләштерергә, Актаныш шәһәрчегеннән генә түгел, ә бәлки пучылар да, этәчләр дә киләләр...

Актанышлылар арасыннан бер шаяны өстәп куйды:

— Куяннар да килә, бурсыклар да, качкыннар да...

Безнең елмайганыбызны күзәтеп, язучыларның һәм журналистларның яраткан туташ-ханымы, районның хакимият башлыгының урынбасары азактан төзәтеп куя:

— Пучы авылыннан да киләләр, Әтәч, Куян, Бурсык, Качкын авылларыннан да район үзәгенә загска никахларын теркәргә киләләр...

## Йә, хуш!

Авылның ике урамы булып, алар елганың ике ягында урнашкан. Елганың бер ягында баерак кешеләр яши. Шуңа күрә монда малны да күбрәк тоталар, һөнәрчелек белән дә күбрәк шөгыльләнәләр. Баюларының сәбәбе дә менә шулдыр инде. Үзләренең мәчетләре белән муллалары булуы да гаҗәп түгел.

Ә аның каршы ягында ярлырак кешеләр гомер итә. Мәчетләре булмаса да, үзләренә бер мулла да сайлап куйганнар.

Менә Корбан бәйрәме дә килеп җитә. Байлар урамында яшәүчеләр зур үгезне корбан итеп чалалар һәм мәчеттә бәйрәм ашы үткәрәләр. Мәҗлескә ярлы якта яшәүче мулланы да чакыралар. Зур бәйрәм өстәле артына җыелып, башта изге Коръән сүрәләрен укыйлар. Аннан соң корбан ашыннан авыз итә башлыйлар. Гадәттәгечә, мәҗлес азагында гәпләшеп, яңалыклар сөйләшеп алалар. Җаен китереп, ярлылар урамы мулласы, бөтен кеше ишетерлек итеп, байлар мулласына мөрәҗәгать итә:

— Менә, хөрмәтле хәзрәт, мәхәлләләрне гадәләтсез бүлгәннәр. Аны елга буйлап түгел, ә аркылыга бүләсе иде. Ул вакытта ике мәхәлләгә дә байлар да, ярлылар да керер иде. Әйдәгез әле, хөрмәтле хәзрәт, шулай эшлик...

Бай мулла сакалын сыйпап куя, бераз күзләрен йомып, тын алмаган сымак тора һәм ашыкмый гына әйтеп куя:

— Йә, хуш!..

Ярлылар урамы мулласы, форсаттан файдаланып, авылдашлары ишетеп калсын дип, бай муллага басымын дәвам итә:

— Сезнең байлар урамы безнең якта мәчет салып бирсә дә бик шәп булыр иде...

— Йә, хуш,— ди бай мулла, ихтирамлы гына итеп.

Ярлылар мулласы кызганнан-кыза бара:

— Менә сезнең байлар урамыннан өй саен ярдәм җыеп безнең фәкыйрьләргә таратсак та бик шәп булыр иде...

— Йә, хуш! — ди һаман да бай мулла.

Кунаклар тарала башлыйлар. Урамга фәкыйрьләр мулласы да чыга һәм, бай мулланы көтеп алып, аңа ташлана:

— И-и, зур рәхмәт инде, хәзрәткәем. Авылдашларыбыз алдында мине хур итмәдегез. Бөтен үтенечләремне хуплап утырдыгыз... Шунсын беләсе килгән иде, хөрмәтле хәзрәт, «йә, хуш» дигән сүз безнеңчә ничек була соң ул?

Бай мулла сак кына итеп тирә-ягына карап куя һәм тамагын кырып әйтеп җибәрә:

— Капчыгыңның авызын киңрәк ач дигән сүз була,— дип, өч бармагыннан комбинация күрсәтеп, өенә таба юл тота. Бераз үткәч, борылып: — Эшләргә кирәк дигән сүз дә ул.

## Күркәләргә дан!

Минем фронтовик этине колхозга рәис итеп куйдылар.

Әллә инде аңа сугыш, әллә власть мәшәкатьләре тәэсир иткән, безнең эти вакыты-вакыты белән сәер генә нәрсәләр дә күрсәткәләп куйгалый иде.

Әле дә хәтердә: әни тегеңә бер кисмәк атланмай бирде. Агыйдел белән Кама кушылган җирдәге Дербешка пристанена барып, шуны сатарга, ә акчасына ипи, конфет, тагын нindидер хуҗалык кирәк-яраклары алырга кушты.

Әти майны үтеп баручы пароход буфетына тапшырып, акчаның бер өлешенә «тамагын чылатып», калган акчасына миңа авыз гармуны ала. Тегенди-мондыен гына да түгел, трофейныйны. Гаҗәп матур иде ул. Перламутр белән тышланган иде. Иренгә куеп сыдырып җибәрүең була, тегенең авазына авылның бөтен малайлары җыела. Безгә ул ачлык елларны шул гармун гына җитмәгән иде. Шуның өстенә гармунның бер кимчелеге дә бар иде әле — ахыргы тишекләре аваз чыгармый. Әллә инде минем өреп кычкыртырлык сулышым җитмәгән, әллә инде немецның трофей гармуны безнең татарның моңлы, озын көен чыгара алмаган. Хәер, аның гомере бик озын булмады. Пыш-мыш итеп кенә череләүче музыка коралы этигә ошамады.

Кыйшаеп беткән тарантасына утырып, ул тагын Дербешкага китте. Бу юлы әни аңа бер кәрҗин йомырка тоттырды.

— Барып тапшыр да бер-ике көрәк, сәнәк ал. Миңа, персидәтел хатынына, ике япьле сәнәк белән кеше көлдереп эшкә йөрү оят. Калган акчага тозлы балык, ипи алырсың,— диде.

Кем әйтмешли, көтеп тор син аны. Бик алып кайтыр ди ул син әйткәнне. Шундый сәнәк тә бик ярап куйган, дияр. Шулай булды да. Кайтып кергәч, кыйшайган тарантасыннан тальян гармун тартып чыгарды. Күренеп тора, үзе бераз кызмача.

— Мә, улым, тот! Шәп итеп уйнарга өйрән...— диде ул миңа.

Әни күз яшьләре чыкканын тоймый да калды. Ә мин тальянка өчен шатланып бетә алмыйм. Берәүгә — шатлык, икенчегә — кайгы. Гомумән, күңеллесен күңелле инде. Ләкин көй чыкмый әле. Билгеле бер вакыты җитмичә, мин барыбер уйнарга өйрәнә алмадым.

Әни бераз тынычлана төште. Ә ул шулкадәр җырларга ярата иде, һич тыңлап туя алмаслык. Әти өйдә юк вакытта авыл хатыннары аны тыңларга, аңа кушылып җырларга яраталар иде.

Тальян гармунда уйнарга өйрәнү өчен, без әни белән мунчага киттек, югыйсә авылның кайбер хатыннары чәйни башларлар. Бакча уртасындагы ягылмаган кара мунчада утырабыз — тугыз яшьлек булачак гармунчы һәм әни. Әни татар халкының «Шахта» көен суза. Ә мин, аңа ияреп, уйнарга тырышам, тальянканың төрле төстәге күреген тартам, каты-каты итеп клавишаларга басам. Көйдән читкәрәк китә башласам, янтыкка төртүен көт тә тор. Шуннан соң репетиция яңадан башлана. Менә көн саен шулай дәвам итә. Эчемнән генә, бу батыр шахтер үзенең күмерен чабудан кайчан туктар икән, дим. Ике атналар кара мунчада тырыша торгач, мине шактый туйдыра башлаган «Шахтер егет күмер вата»ны алдырдым бит. Без әни белән моны сер итеп сакларга булдык. Шуннан соң без борынгы татар көе «Сарман»ны өйрәндек. Китте бит эшләр ходка. Буа китте дип уйларсың — берсе артыннан икенчесе бара.

Ә «Әпипә»не өйрәнгәндә, әни җырлап кына калмады, хәтта биеп тә җибәрде.

Кичләрнең берсендә, тальянны алып, капка төбенә чыгып утырдым да мунчада өйрәнгәннәрне сыздырып җибәрдем. Кешеләрнең йөзләрен үз күзләрегез белән күрсәгез икән! Бөтен авыл җыелды. Сугыштан соңгы ул елларда үзебезнең авылда да, башкаларында да бер гармунчы да юк иде. Электр да, радио да юк. «Барыня»ны, «Әпипә»не уйный башлагач, хәтта тирә-юньдәге авыл яшьләре дә уенга җыела башладылар. «Бас әле, Әпипә, син басмасаң, мин басам...» дигән җыр сүзләре бөтен авылга яңгырап тора иде.

Көзнең бер көнендә без сарык суйдык. Сатып, хуҗалыкка кирәк-яраклар алырмын дип, әти аны Дербешкага алып китте. Бу сәер кешенең монда да йөрәге түзмәгән, күрәсең, өч капчыкка тутырып, нindидер нәрсәләр алып кайткан.

Мин кызыксынып болдырдан карап торам. Әни, әби һәм минем кече туганнар тәрәзәдән күзәтәләр. Янәсе, бу председатель тагын ни белән шаккатырыр икән.

Әти бер капчыкны ачып күркә чыгарып җибәрде. Мескен кош әле бер якка, әле икенче якка барып сугыла. Капчыктан чыгып таныш булмаган ишегалдына килеп керү гаҗәп тоелган, күрәсең. Бер яктан икенче якка сикергәли.

Ул икенче капчыкны ачты. Аннан да күгелҗем зәңгәр канатлы күркә килеп чыкты. Кечкенә генә башындагы кызгылт күзләре белән бик усал карый. Менә өченче капчыкны ачты. Аннан ата күркә сикереп чыкты. Гаҗәеп зур үзе. Ямьсезлеккә ямьсез. Башлыгы кызыл, сакалы бар сымак, томшыгында да нindидер күгелҗем шеш. Карап торырга җирәнгеч. Тавышын ишетсәң иде: «Курлы, курлы, кур-р-р. Тяв, цяв-чур, мурлы-корлы». Менә бу кош ичмасам. Эттән дә болайрак. Канатларын җәеп җибәргәч, ул тагын да шыксызрак булып күренде. Күп тә үтмәде, этигә ташланды. Әти, үтеп баручы поезд тамбурына сикергәндәй, җәһәт кенә баскычка менеп өлгерде.

Урамдагы халыкны күрсәң иде, бөтен авыл җыелып өлгергән дип белерсең. Бөтенесе койма ярыгыннан карап торалар. Аларның «абау», «гыйбрәт», дигән сүзләре генә ишетелеп тора. Ә үзләре ишегалдына керергә куркалар.

Кырык сигезнең язы килеп җитте. Урамнарда сулар ага, кошлар кайта. Кәрҗинкәләрдән бер-бер артлы күркә бәбкәләре чыга башлады. Безнең мүкләк сыер бөтен авыл халкын гаҗәпләндереп, икесе дә бертөсле коңгырт кызыл бозаулар китерде. Маңгайларында хәтта йолдызчыклары да бар.

— Яхшыга түгел бу, ике үгез бозау туу яхшыга түгел,— дип сөйләнделәр авыл карчыклары.

Ә безнең күгелҗем канатлы ана күркәләр үзләренең кәрҗинкә ояларында ялангач бәбкәләре белән утырдылар. Шундый ямьсез һәм куркаклар икән үзләре.

Җәй дә бик тиз үтеп китте. Безнең теге хәлсез бозаулар сөзешә торган зур үгезләр булып җитештеләр. Ә кайчан гына кәрҗинкәдә яткан ялангач яшь күркәләр ишегалдының хуҗалары булып өлгерделәр. Аларның тавышына гына һич чыдар хәл юк. Алар кычкырыша башласа, хет өйдән чыгып кач.

Һәр авылның үз юләре була. Андый кеше безнең авылда да бар иде. Гыйльметдин исемле иде ул. Безнең авылча әйткәндә, Гыйлем инде. Бервакыт бу дивана безнең коймага менгән. Кулын честь биргәндәгедәй башына куйган. Хәрби парадларда маршал Ворошилов атка атланып йөргән кыяфәттә бар көченә командирларча тавыш белән кычкыра башлаган:

— Яшәсен ВКП бәләкәй «б» белән!

Ә безнең күркәләр төркеме Мәскәүдәге Кызыл мәйданда хәрбиләр колонналары ничек җавап бирсә, шулай гөлдери башлаганнар. Янәсе, алар маршалга сәламәтлек телиләр.

«Парад командующие» дивана Гыйлем «үзенең» армиясен яңадан тәбрикли:

— Яшәсен Чапаев колхозы!

Күркәләр армиясе моңа үзләренчә җавап бирәләр. Янәсе, сәламәтлек телибез, иптәш командующий!

— Мәңге яшәсен колхоз председателе!

— Гул-гул-гул-гла-гля,— дип кычкыралар канатлы армия солдатлары.

Әти иртән Актанышка киткән иде. Әни колхоз эшендә. Фәрхикамал әбинең яңакларында төерләр йөри башлады. Ачуланып читкә төкереп куйды.

— Бу шайтанны галәфиләр өйрәткән бит. Шулай, шулай. Хәзер мин аңа команданы күрсәтим әле.

«Галәфи»ләр дип әби фронттан кайткан солдатларны атый. Төсе киткән шундый ыштаннарны киеп авыл урамнары буйлап солдатлар йөриләр иде бит. Фәрхикамал әби зур гына бер бәрәңге ала да, йөгереп үк барып, аны койма өстендәге «маршал»га җибәрә. Төз ата. Тегенең колагына ук тондыра. Йөз елга бер тапкыр кисәү агачы да ата, дип юкка гына әйтмиләр, күрәсең. «Командующий» койма өстеннән атылып төшә дә, «үтерделәр, үтерделәр» дип, акырып урамның икенче башына чаба. «Хәрби парад»ны күзәтүче бала-чагалар да, өлкәннәр дә өйләренә кереп таялар.

Кичке аш вакытында әби өйдә иң зур хуҗа. Ул кыскача гына булган хәлне сөйләп бирде. Ә аннары:

— Бу армия белән нәрсә булса да эшләргә кирәк,— дип өстәде.

— Әйе,— диде әти сузынкы гына тавыш белән һәм башын кашып куйды.

Иртә белән, мәктәпкә китәр алдыннан, мин әтинең кыйшайган тарантасына менәм дә, командирлар кыяфәтенә кереп, күркәләрнең хәрби группасына күрсәтмә бирәм:

— Яшәсен Чапаев колхозы. Исәнлек телим, колхозчы иптәшләр! Ә күркәләр бөтен авылга ишетелерлек итеп:

— Гыл-гул, гыл-гыл,— дип җавап бирделәр. Янәсе, колхозга хезмәт итүләренә бик шатлар.

— Яшәсен колхоз председателе! — дип бар көчкә кычкырам. Ишегалды армиясе миңа карый да, тагын үзләренчә бертавыштан җавап бирәләр:

— Гыл-гыл, гул-гыл...

Читкә карап куйсам... Ой Аллакаем... Әтием, чыбыркысын тотып, минем янда басып тора. Мин тарантастан тиз генә сикереп төштем дә капкадан ничек чыкканмындыр, белмим, бакчалар буйлап мәктәпкә элдердем...

Өйгә кайтып керсәм, карыйм, зур кунаклар килгән. Үзенең коңгырт формасында портупеясына наганлы кобура таккан, хром итекләр кигән Актаныш НКВДсы начальнигы Бариев, безнең авыл буенча вәкил ВКП(б) райкомы инструкторы Сәлимов утыра. Анысы солдат гимнастеркасы кигән, аны каеш белән буып куйган, галифе чалбарының балакларын ялтырап торган төймәле ботинкаларга тыккан.

Чаршау белән генә бүлеп куелган почмактан әтинең дивана Гыйлем, күркәләр турында, аларның, бөтен авылга ишеттереп, командага җавап бирүләре хакында сөйләве ишетелә. Стаканнарның чәкелдәвеннән тегеләрнең аракы эчкәннәрен сизенәм. Әби биргән ашамлыклар белән авыз чапылдатып капкалап та куйгалыйлар бугай.

— Да-а,— ди сузып кына НКВД начальнигы.— Яшәсен ВКП кечкенә «б» белән дисез инде алай булгач? Бу бик мөһим мәсьәлә. Политик эш. Моннан илле сигезенче статья исе килә.

— Бик дөрес әйтәсез,— дип, Сәлимов аның сүзен куәтли.

— Нәрсә эшләргә соң? — дип, әтиебез авыр сулап куя.

— Ничек инде нәрсә? — дип хихылдап куя НКВД начальнигы.— Күркә командирының бугазына пычак салырга, авылга «басмач» килгән дип уйларлар югыйсә.

Кечкенә «б»лы ВКП райкомы инструкторы да, күзләрен дә йоммыйча, аның сүзләрен куәтли! Билгеле инде, «басмач» бугазына — пычак.

— Дөрес әйтәсез бит,— дип, әти дә шаркылдап көлеп җибәрә.— Ә мин җүләр шул турыда уйламаганмын. Казанга салырга билгеле андый «басмач»ны, советка, партиягә каршы нәмәрсәне.

Утыз җиденче еллардагы кебек монда да командир күркә язмышын «тройка» хәл итте: бугазын кисәргә, бетте-китте. Әти савытлар шкафыннан шундый вакытларда кулланыла торган озын пычакны тартып чыгарды. НКВД начальнигы белән вәкил Сәлимов бу вакытта инде ишегалдында рекогносцировка ясыйлар иде. Алар хәрби белемнәрен кулланып, «антисоветчик»ны, зур гаилә башлыгын әсирлеккә төшерү өчен, ике яктан кыса башладылар. Власть вәкилләренең хәрби хәзерлеге өстенлек алды. Әти күркәнең селәгәйле башын кыйблага каратып салды да, эченнән генә укыйсын укып, Актаныш җирендәге «антисоветчик»ның тормышына чик куйды.

Үзләренең кара эшләрен эшләгәннән соң, «халык дошманын» казанга салып пешерергә кушып, «тройка» колхоз идарәсенә китеп барды.

Өч сәгатьләрдән соң ике шешә аракы алып өйгә кайттылар. Берсе — НКВД начальнигының планшетында, икенчесе вәкил кесәсенә яшерелгән.

Өстәлгә токмачлы аш һәм подноста күркәләр командиры чыгарыла. Күркәне, нигездә, «тройка» ашады. Күп булмаса да, гаилә әгъзаларына да калды. Күркә ите бик тәмле булып чыкты. Америкалылар һәм аларның Президенты юләр түгел икән — ел саен күркә бәйрәме үткәрәләр. Минем үземә калса, каз ите әйбәтрәк. Хәер, кемгә нәрсә ошый бит.

Икенче көнне туңдырып җибәрде. «Тройка» карары белән башка күркәләрнең дә башына җиттеләр. Бер атналардан дивана Гыйлем тагын безнең коймага менеп атлана һәм бар авылга шәрран яра:

— Яшәсен колхоз председателе! — Ләкин ул ничек кенә кычкырмасын — ишегалдында үле тынлык. Ул мескен кайдан белсен инде аның «армия»сенең суелып беткәнен.

Ә председатель әтиебез үзе бу көннәрдә, аркасына капчык сымак нәрсә асып, салкын якларга таба атлый иде...

# Тай моннан, бабай!

Матур буласың килсә,
гусарлыкка кер.

*Козьма Прутков*

Шундый рәхәт вакытлар килеп җитте әле, мин сиңа әйтим. Капитал туплауның баштагы чорында ай-һай шәп яшәлә икән ич. Кая гына карама, базар мөнәсәбәтләре, базар ыгы-зыгысы. Тирә-юнь шаугөр килә. Урыс икътисадчылары аны «рыночные отношения» диләр инде. Ә без — татарлар өчен — хет чуртым дип ата, үзенә генә хас үзенчәлекләре белән базар базар булып кала инде ул.

Шулай бервакыт, түшәмгә төкереп, кәнәфидә ятам, телевизор карыйм. Ә үзем уйлыйм: «Бу фани дөньяда яшәве нинди рәхәт! Рәхәт яшәве — үзе бер рәхәт! Тагын да яхшырак яшәсәң дә зыян итми, билгеле».

Ә ничек яхшырак яшәргә? Аңлашыла лабаса. Әнә телевизор экранына гына кара: ничәмә-ничә банк, фирма, хәтта фирма гына булып килә торган бәләкәйләре дә акчаңны кесәңә салып, үзләренә чакыралар. «Бездә генә ул мең процент»,— ди берсе. «Миллиардка юл бары тик безнең фирма аша»,— дип ышандырмакчы икенчесе. «Без сезне алтынга күмәбез»,— дип исбатлый өченчесе. Дүртенчеләренең, бишенчеләренең дә теләге бер — сине баету. Шуларны тыңлыйм да уйга калам. Нигә соң әле тагын да яхшырак яшәмәскә? Ни өчен миллиардер, һич югында миллионер булмаска? Малай да әле менә фатир алырга дип, Камчаткадан акча җибәргән. Фатир эзләгән-ниткән арада, шундый юләр процентлар алып, мин мультимиллионер була алам ич, ә?!

«ТТТ» фирмасына барам. Сакчы, ягымлы гына елмаеп, мине эчкә кертеп җибәрә. Каршыга кызыл пиджак кигән, бит алмалары да пиджагы төсенә кергән алып гәүдәле, утыз яшьләрдәге бер кеше килә.

— Монда халыктан акча кабул итәләрме? — дип сорыйм кыюсыз гына.— Әгәр шулай икән, нинди процент белән?

— Монда, бабай, монда.— «Кызыл пиджак» шатлыгыннан кулын-кулга ышкып алды.— Мең, бабай, мең процент. Меңне салсаң, бер елдан унике меңне аласың, унны саласың икән — кесәңдә йөз егерме мең булды дип исәплә. Ничек күп салсаң, шулкадәр күп аласың.

Ишеткәннәрдән тәнгә салкын тир бәреп чыкты, күз аллары чуарланып китте. Бермәл тын торып, түбәтәй астындагы «аппаратымда» чама белән исәпләгәннән соң, пышылдап кына:

— Бусы шәп,— мин әйтәм,— фирмагыз нинди мәгънәне аңлата соң? Әллә, мин әйтәм, өч татар дигәннеме? Төшенәсе килә бит. Үзегез беләсез инде, картлар төпченүчән була. Аннан соң мине акчамның нинди максатларга юнәлдерелгән булуы да кызыксындыра әле.

— Юк инде, бабай, нинди өч татар булсын,— ди кызыл пиджаклы ир-ат.— «ТТТ» — «Трастетремтриумф» була ул. Яр Чаллы — Нефтекамск автобанын төзиячәкбез. Икенче төрле әйтсәк, Татарстан белән Башкортостанны ук шикелле туп-туры юл белән тоташтырачакбыз. Агыйдел аша салават күпередәй күпер салып куячакбыз. Ә автобан тирәли йортлар, йортлар гынамы соң, әкияттәгедәй матур-матур коттеджлар тезелеп китәчәк. Бу инде сиңа Потемкин авыллары гына булмаячак, бабай.

— Шулай да саклык банкын ышанычлырак дип әйтәләр,— дип бүлдерәм яңа гына дөньяга килгән финансистны.

— И бабай,— «кызыл пиджак» кулларын селти,— саклык банкы безнең белән чагыштырганда импотент ич ул, икътисади мәет. Ышан, бабай, бары без генә сине миллионер итә алабыз.

Мич башында гына утырып, кайсы гына совканың тагын да яхшырак яшисе килми икән?! «Кызыл пиджак» мине тәки күндерде бит. Салдым мин акчаны боларга. Бик зур эш башкарган кеше шикелле өйгә кайтып киттем. Юл уңаенда өч айдан алачак юктан бар булган табышымны исәплим. Шулай эшләми-нитми генә керем алып яшәү рәхәтнең дә рәхәте ич. Ничек кенә әле!

Барган уңайда турфирма «Жираф» дигән вывескага күзем төште. Кызык өчен генә булса да кереп чыгыйм әле, мин әйтәм.

— Сезгә, бабай, кая? — Калашников автоматыннан аталар диярсең, тырылдата башлады бит куе кызыл төстәге пиджак кигән яшь кенә бер ир заты.— Анталиягәме? Хургадагамы? Майоркагамы? Шоп-тур яки ял өченме?

— Хургадага! — дим, каты итеп кычкырып, өзлексез такылдаучыны туктатырга теләп.

— О-о, Хургада! — Мисырның Кызыл диңгез буендагы менә дигән курорты ул,— дип такылдавын дәвам итә «кызыл пиджак».— Хургада — ул менә дигән пляжлар, мәрҗән рифлары, Нил буйлап пароходта йөрүләр, крокодиллар, Мисыр патшалары үзәнлеге, әкияттәгедәй пирамидалар...

— Күпме тора? — дигән булып тагын бүлдерәм такылдаучыны.

— Биш йөз доллар! — дип ярып сала «кызыл пиджак».— Ике атна оҗмахның үзендә буласыз. Бөтенләе биш йөз долларга! Арзанрагы инде аның, бабай, бушлай гына була.

Һе, ике атна гына булса да оҗмахта яшәп алырга кем генә теләмәс икән? Эх, беткән баш беткән, мин әйтәм, биш йөз доллар да акча булдымы? Өч айдан «ТТТ»дан әнә күпме юләр акчалар алачакмын. Процентлар акча өстәп торган арада барып кайту зыян итәрмени? Ху... Ху... Ничек соң әле? Ә-ә, Хургада диде бит әле. Әнә шунда. Кем әйтмешли, без рәхәтләнеп гуляйт итә торабыз, акчалар килә тора. Эх-ма!

Нәкъ биш йөз долларга тигез эквивалент тоттырдым мин турфирма кешеләренә.

— Бер айдан китәбез,— ди автомат кебек такылдаучы «кызыл пиджак» мине ягымлы гына озатаозата. Аннары: — Группаны җыеп бетерү белән,— дип өстәп куйды. Әйтәселәре калган булган икән, ишекне ябып чыгып киткәндә кычкырып калды:

— Түлке, бабай, шорт белән панама алырга онытма!

Аның соңгы сүзләре колакны ярып кергәндәй булды. Каян ишеткәнем бар иде соң әле «панама» дигән мондый матур сүзне?

Ни генә булмасын, минем күңел хәзер беркайчан булмаганча күтәренке. Кем әйтмешли, борын күккә чөелгән. Туганнар, дуслар, таныш-белешләр хәл-әхвәл сораша башласалар, баш бармакны гына күрсәтәм һәм шатлануымнан елмаеп җавап бирәм:

— Тормышы да бик әйбәт, яшәве дә күңелле! Котырынкы акчалар ясый торган станок таптым әле менә. Банкнотлар пачкалары белән очып чыгалар...

Минем танышларның борын төпләрендә шөпшә безелди дип уйларсың, күзләрен зур ачып миңа карыйлар да тиз-тиз таю ягын карыйлар.

— Ялган акчалар ясый башладыңмыни? — Бу аларның әллә сораулары, әллә инде җирәнеп шелтәләүләре иде, шайтан белсен.

— Юк инде, шаярып кына әйтәм.— Мин әшнәләрнең җилкәләреннән каккалыйм.— Фирмаларда акча әйләндерәм. Кайсында мең процент белән, кайсыларында ике мең белән.

Шулай да танышлар минем яннан тиз-тиз китү ягын карыйлар. Көнләшәләр, мин сиңа әйтим. Хәерле булсын, көнләшәләр икән, димәк, минем эшләр начар түгел.

Менә шулай, түшәмгә төкереп, кәнәфидә ятам, күңелемнән «ТТТ»дагы процентларны һәм Хуга... Нәрсә әле? Ә, әйе, Хур-гадага китәргә ничә көн калганын исәплим. Тыела алмыйча, «эх-ма!» дип кычкырып ук җибәрәм. Алай да бу дөньяда яшәве әйбәт! Әйбәтрәк яшәве аның тагын да әйбәтрәк, билгеле. Тагын да яхшырак яшәсәң дә яхшы булыр иде.

Минем матур уй-хыялларымны мәктәптән кайтып кергән җиденче сыйныфта укучы оныгым Ринат бүлдерде:

— Бабай, әй, бабай! «Запор»ыңны нигә чит кешеләргә бирдең?

— Ничек инде бирдем? — Өскә кайнар су сипкәндәй булды. Мин кәнәфидән сикереп үк тордым.— Беркемгә дә бирмәдем. Подъезд каршында тора ич ул.

— Тү-тү, бабай, синең «Опель-хохол»ың,— дип көлүен дәвам итә шайтан малай.— Өч исерек утырып китте аңа.

— Урлаганнар, хәшәрәтләр! — дим һәм ашык-пошык киенәм.— Алып киткәннәр, бурбоннар. Мине туендыручыны урлаганнар, убырлар. Мин ул иномарканы алу өчен гомер буе тир түктем.

— Нигә соң әле син, бабай, шундый кыйммәтле иномарка сатып алдың? — Шайтан малай, мыскыл итеп, миңа һаман төрттерә тора. Каян килгән аңа шундый үткен тел?

Үзебезнең милиция бүлегенә киләм. Пыяла артында яшь кенә бер лейтенант «Сникерс» кимереп утыра. Ияге буйлап шуның сөңге кебек җепләре сузылган. Беренче карашка хезмәт хакын аңа милициядә эшләгән өчен түгел, ә нәкъ менә «Сникерс» кимергән өчен түлиләрдер дигән фикер туа. Тазалыгын күрсәң иде аның. Соңгы тапкыр хезмәт хакын моннан ярты ел элек алган дип кем уйлар? Симез лейтенант Пиночетның да Пиночеты инде. Бер сүз белән әйткәндә, хунта!

— Машинамны урлап алып киткәннәр,— дим, пыялада уелган тишеккә пышылдап.— Сүз уңаеннан шунысын да әйтим әле, иномарка иде. «Опель-хохол» дип атала.

— Нинди генә урыс татары тиз йөрүне яратмый икән,— дип мыгырданды Хунта пыяла аша.— Машинаң страховайт ителгәнме? Противоугонные бар идеме?

— Страховать ителгән, тегесе дә бар иде,— дим Хунтага.

— От винта, бабай! — ди яшь Пиночет. Үзе һаман «Сникерс»ын кимерә.— Страховкасын алырсың. Үзең эзлә инде иномаркаңны, бабай. Тапсаң, безгә хәбәр итми калма.

— Сезгә хәбәр итәргә? — дим, ачуым килеп.

— Ә син ничек уйладың? Син, бабай, бездә эленеп торган тагын бер нәрсә булуын телисеңмени?

— Нинди эленеп торган нәрсә ул тагын? — Гаҗәпләнеп Пиночетка карыйм.— Кайда, нәрсә эленеп тора?

— Эх, син,— дип, тирән сулап куйды Хунта һәм ияген дәге «Сникерс» валчыкларын сөртеп алды.— Надан! Әгәр син юклы-барлы «Опель-хохол»ыңны тапмасаң, ул ачылмаган җинаять булып безнең өстә эленеп торачак. От винта, бабай! Эзлә үзеңнең иномаркаңны. Мин журналга язып куйдым.

Ул шулай диде дә мине урамга чыгарып җибәрде.

Кайгыга чумып, шау-шулы урам буйлап өйгә кайтып киттем. Карыйм — вывеска. «Чековый ваучерный фонд» дип язылган. И-и-и, Аллам, авыр минутларда син ярдәмгә килдең түгелме соң, ваучер фонды! Менә мине нәрсә коткарачак. Шөкрана кылып, шунда кереп киттем.

— Миңа Ваучерайсны күрергә кирәк иде. Теге җирән чәчле яшь мужикны,— дип, яшел төстәге француз пиджагы кигән яшьрәк кенә бер ир-атка мөрәҗәгать итәм.— Минем «Опель-хохол» маркалы машинамны урлап алып киттеләр...

— Бу милиция түгел,— дип, «яшел пиджак» тәкәбберлек белән кире какты мин әйткәнне.— Без — ваучер фонды.

— Вәт-вәт,— дип, уңайсызланып кына куәтлим тегенең сүзен.— Миңа нәкъ сезнең фонд кирәк тә инде. Мин заманында сезгә почта аша ике чубер җибәрдем — үземнекен дә, хатынныкын да.

— Чубер түгел, вау-че-ер! — «яшел пиджак» көлеп куйды.— Ә бик беләсең килсә, син әйткән җирән чәчле яшь мужикны да Ваучерайс димиләр, ә Чубайс дип атыйлар.

— Әйе, әйе,— дип кабатлыйм,— шул иде шул, Чубайс. Үзәк телевидениедән һәр ваучерыгызга икешәр «Волга» алачаксыз дип ышандырган иде. «Опель-хохол»ымны урлап киткәч, «Волга»сымы, акчасымы — бик кирәгеп куйды әле.

— Ярар, бабай, тикшереп карыйк әле,— ди «яшел пиджак». Ул компьютерын кабызды, ниндидер хикмәтле кнопкаларына басты.— Тәк, тәк... Эһе, чыннан да, бабай, син үзең дә, карчыгың да бу штуковинада утырасың.— Ул компьютер экранына имән бармагын куйды: — Менә дивидендлар белән дә эш тәртиптә. Шушы көннәрдә алырсыз. Кичә генә почта аша сезнең адреска акча күчерелгән.

Акча керәм дисә, ул тишеп тә керә, дип, юкка гына әйтмиләрдер инде.

— Вәт яхшы булган, мин әйтәм.— Шатлыгымнан кулны кулга ышкып алдым. Суммасын тизрәк беләсе килеп, тиз-тиз сорыйм тегеңәрдән: — Күпме? Машина алырга җитәме?

— Һәр ваучерыгызга икешәр сум,— ди «яшел пиджак», борын астыннан гына пышылдап.— Икегезгә дүрт сум була.

— Нәр-сә-ә-ә? — Авызымны ачып, баскан урында тораташ булдым.— Бу, бу... бер туңдырма алырга гына җитә ич. Теге, кем әле, Чербайсмы, Чубайсмы, бер билетка ике «Волга» диде ләбаса.

— От винта, бабай! — «Яшел пиджак» җилкәләремнән эләктереп, мине ишеккә каратып бастырды.— Бөтенесе дә дөрес исәпләнгән, дөрес җибәрелгән. Хыяллану, бабай, зарар итми.

«Хәшәрәт прихватизаторлар! Комсыз капитализм акулалары! Яңа туган буржуиннар! «Яңа урыс татарлары»! Кайда ул Чубайс дигәннәре — финанс Чикатилосы? Кая минем дүрт «Волга»м? Ярар, сезнең комсыз капитализмыгыз да черер әле бервакыт»,— дип, эчемнән генә бөтен дөньясын тиргим. Ачудан үземне кая куярга белмичә, хатын янына кайтам.

Бераз тынычланганнан соң, кылт итеп, «Жираф» турфирмасы искә төште. Шунда таба юнәлдем. Анда мине күн куртка кигән сакчы каршылый. Курткасы андый-мондый гына түгел, Төркиянең үзендә тегелгән.

— Миңа директор янына керергә кирәк иде,— дим «күн куртка»га.— Белергә иде, Ху... Хуга, нәрсә әле?.. Әй, Хургадага дигәнем, кайчан китәбез икән?

— Директор булды да юкка чыкты. Көн күрде, кояш алды, диләрме әле? Бар иде директор, хәзер юк инде,— ди «төрек куртка»сы ачу катыш.

— Ничек инде... Бар иде, хәзер юк? — дим, сагая төшеп.— Кая китте соң ул? Теге куе кызыл төстәге «пиджак»ны әйтәм...

— Крокодиллар ашады,— дип акыра «күн куртка».— Нил крокодиллары. Качты директор. Бөтен акчаларны алып тайды.

— Ә-ә... Ху... Ху... Хургада? — Көтелмәгән бу хәбәрдән тынычлана алмыйча, тотлыга ук башладым.

— Менә сиңа Ху, Ху. От винта, бабай! — дип кычкыра сакчы.— Тай моннан тизрәк. Билгеле, хыялллану зарар итми ул.

Бәла ялгыз йөрми, диләр. Минем пенсионер башыма төшкән ниткән казалар әле бу?! Бөтенесенең асты өскә килде. Бу «шоп-тур» шап итәр дип күңел сизгән иде аны. Ләкин бу дәрәҗәдә үк түгел. Капиталистик Русиянең каһәр суккан яңа талаучылары, сазлыктагы кызыл пиджаклы канечкеч озынборыннары!

Кем әйтмешли, өметсез шайтан, диләр. «Ярар,— дим эчемнән генә,— «ТТТ» фирмасыннан үземнең процентларны алырмын да югалтканнарымны каплармын».

Көннәр уза торды. «ТТТ» фирмасыннан акча алыр вакыт та килеп җитте. Тимер ишекне шакыйм. Алып гәүдәле берәү ишекне ача. Кеше шулкадәр үссә дә үсәр, юанайса да юанаер икән — нәкъ антресольле кием шкафы инде. Башын күр әле син аның, зур гына кабак утыртып куйганнар диярсең. Бу «шкаф» мине алгы бүлмәгә кертеп җибәрде. Анда «Ташиба» дигән телевизорлары, янәшәдә генә видиклары тора. Бөтен шартларына туры китереп, шуннан секс турында кино карыйлар икән. Миңа оят булып китте. Безнең совет чорында мондыйларны түгел, открыткаларын да күрсәттермиләр иде. Аның ишегә күнегелмәгән. Менә бит нәрсәгә китереп җиткерде чыкылдаган бу демократлар.

— Процентларны алырга дип килгүем иде,— дим, «шкаф»ка мөрәҗәгать итеп,— «Опель-хохол»ымны да урлап алып киттеләр. Ху... Ху... Хургадага сәяхәтем дә барып чыкмады. Минем гел шулай инде, балачагым да бик авыр булган иде.

— Хыяллану зарар итми, бабай,— ди «шкаф».— Акча юк. Булмаячак та. Син әйткән «кызыл пиджак», хәшәрәт, акчаларны алып качты. Әллә Кипрга, әллә Аргентинага, әллә Кытайга инде шунда.

— Ай Аллам! — Аның бу сүзләреннән соң аяк буыннары тотмый башлады. Көч-хәл белән стенага сөялдем: — Инде нәрсә эшләргә соң?

— Өеңә кайт, бабай! — «шкаф» карашы белән бораулап тишәрдәй итеп, күзләрен миңа төбәде.— Чәй эч, ярдәм итә, диләр. Мин үзем дә төп башына утырып калдым. Өч айлык хезмәт хакын түләмәде, хәшәрәт.

— Алай булгач, бәлки, миңа видик белән бергә шушы телевизорны бирерсез. Акчаларның бер өлеше исәбенә диюем,— дип пышылдыйм әзмавергә.

— Менә моны күргәнең бармы? — «шкаф» ырылдап өстәл өстеннән резин таяк алды. Милиционерларда була бит әле, менә шундыйны.— Бу «демократизатор» дип атала. Кычытмаган җирне кашу өчен кулланыла. Телик белән видикның хуҗасы бар инде. Үзем. Хезмәт хакы исәбенә алам.

— Ә миңа? — Һаман да әле үҗәтләнеп маташам.

— От винта, бабай! — «шкаф» шулай дип кырт кисте дә урамга төртеп чыгарып җибәрде. Арттан кычкырып калды: — Әй, син, акча яратучы, кара аны, дөреслек эзләп йөргән булып маташма тагын...

Шулай шул, яхшы яшәүдән берәүне дә тыеп булмый. Өйгә кайттым. Күргәннәрне, ишеткәннәрне хатын белән оныгым Ринатка сөйләп бирдем. Янәсе, базар могҗизалары турында сөйләп, боларны нык гаҗәпләндерәм. Ә алар базар икътисадын миннән алданрак үзләштергәннәр икән.

Йокларга вакыт җитте. Карыйм, йокы бүлмәсеннән миңа таба мендәр, юрган оча.

— Үзең генә йокла. Әнә диванда! — дип чәпчи бергә кырык биш ел яшәгән хатын.— Синнән барыбер рәт юк.

«Рәт юк» дигәнне нинди мәгънәдә әйткәндер, анысы аңа гына билгеле. Акчанымы, әллә башка нәрсәне күз алдында тоттымы? Һ-м-м! Кызык! Бераздан хәл ачыклана төште.

— Хәсрәт эшмәкәр! — дип кычкыра йокы бүлмәсеннән хатын-прокурор.— Бушка акчалы булырга теләгән аңгыра бәндә. Синең белән консенсус бетте, все. Әнә башка бабайлар хатыннарын презентацияләргә алып баралар, презентлар сатып алалар. Ә син соңгы акчаны туздырып бетергәнсең, башсыз.

Йокы бүлмәсе ишеген ябар алдыннан «карт себер кукесе» усал итеп миңа карап алды да елан шикелле ыжгырып куйды:

— От винта, бабай! Диванда үзең генә йокла. Финанс импотенты. Гомумән...

Менә сиңа тагын «гомумән»! Ишет менә ишетәсең килсә.

— Безнең әби спонсор тапкан, ахрысы,— ди оньк заговорчы сымак.— Курыкма, бабай, исән булсак, үлмәбез.

Иртә кичтән хәерлерәк. Шундый сүзләре өчен оныкка рәхмәт инде. Яхшы варис үсә. Чын егет.

Оныгымның мәктәптә вак-төяк алыш-биреш эшләре белән шөгыльләнгәнен һәм азмы-күпме акчасы барлыгын белә идем. Иртә белән сорыйм тегеңәрдән:

— Оныккаем, ә, оныккаем! Пенсиягә кадәр генә коткармассыңмы? Кесә расходларына егерме биш сум гына булса да бир,— дим. Ә ул гаҗәпләнүдән күзләрен бозландырып миңа карый.

— Бир Бирмага китте, бабай. Бүләк — хәзер инде аны эшлиләр түләп. Базар икътисады, брат, базар икътисады! Процентка гына бирә алам. Бигрәк тә хәзер миндә форс-мажор...— ди.

Күрәсезме, хәзер инде мин аңа бабай түгел, брат икәнмен ич.

— Э-э-э, теге форс-мажор дигәнең нәрсә була инде ул? — дип сорыйм онык-браттан.

— И-их, карурман син, бабай.— Үзе уйга калып, ана сөте кипмәгән иреннәрен чыпылдата.— Мин унынчы класста укучы Вовага бер пачка контрацептив төрттем, ну, Баков резина әйберләре заводында эшләнә торган нәмәкәйләрне инде, аны «английская шапочка»дип тә йөриләр. Менә шуларны чит ил күшәменең иероглифлар төшерелгән ялтыравыклы кәгазенә төрдем дә японнарныкы дип саттым. Хәзер ул миннән халыкара сыйфат сертификаты сорый. Көннәр санала башлады инде. Мин каян алырга тиеш ди ул халыкара сертификатны? Менә сиңа форс-мажор, бабай. Әгәр болай да аңлашылмаса, гади итеп әйтәм: алдан күрелмәгән хәл, значит.

— Ә син миңа процентсыз биреп тор,— дип дәвам итәм фикеремне.— Ни әйтсәң дә мин синең бабаң.

Оньк авызын ерып көлә.

— Бабай, әгәр син шундый акыллы икәнсең, нигә бай түгел соң? От винта, бабай,— дип бетерде ул үзенең тәрбия миссиясен.— Процентсыз бирмим.

Кая барасың? Шул шарт белән алырга туры килде. Кызганды бугай. Процентын беркадәр киметергә булды. Рәхмәт инде үзенә, коткарды.

Әйе, иртәрәк мактанганмын таныш-белешләр алдында. Акча ясый торган станок брак булып чыкты. Нәрсә эшлисең, кем әйтмешли, әле эңгер-меңгер генә, тормыш дәвам итә. Андый вакытларда йөрәк януын классиклар бастыралар. Урыснықылар да, татарныкылар да. Аерма юк, күңелне генә тынычландырсыннар. Менә мин тагын Антон Павлович Чеховны искә төшерәм. Ул баштарак язылган әсәрләренең берсендә оптимизм турында бигрәк тә рухи күтәренкелек белән әйтә: «Йә, нәрсә, күзне чыгардылармы, икенчесе исән бит. Шатлан! Кул өзелдеме — икенчесе исән бит. Яшә һәм шатлан! Хатының хыянәт итә, диләр. Нәрсә булган?! Ул Ватанга хыянәт итми бит!»

Классиктан да әйбәтрәк итеп кем әйтә алыр?! Классиклар күңелне тынычландыралар. Үземнән чыгып әйтәм.

Нормадан тайпылган, кем исәбенәдер яшәүчеләр иленең тупас һәм гади хакыйкатен үземнән өстим: бай яшәмәдек, бай яши башлауның да кирәге юк.

От винта, әфәнделәр, иптәшләр! Аллаһу әкбәр! Аллага шөкер, ул һәрвакыт әкбәр. Бөтен өмет аңарда. Ә урыслар ни өчендер моңа тагын өстәп куялар: «Ә үзең хата җибәрмә!»

## Бүгенге һәм кичәге иблисләр

*(Михаил Булгаковка ияреп)*

«Иптәш Коротков эшли торган аерым бүлмәнең ишеге ачылып китте. Аннан елаган тавыш белән бер хатын:

— Иптәш Коротков, хезмәт хакы алырга барыгыз,— диде.

— Ничек? — диде Коротков шатланып һәм, «Кармен»нан увертюра сызгыра-сызгыра, «Касса» дип язылган бүлмәгә ашыкты. Ул кассир өстәле янында туктады да, ни әйтергә белми, авызын зур итеп ачарга мәҗбүр булды. Сары пачкалардан торган ике өем акча түшәмгә кадәр өелгән иде. Тиргә баткан һәм дулкынланган кассир, мөгаен, бер сорауга да җавап биреп тормас өчендер, ассигновканы кнопка белән стенага ябыштырды. Анда яшел кара белән язылган өченче язу тора иде: «Җитештерелгән продуктлар белән бирергә».

Коротков кассир яныннан ни әйтергә дә белмичә, юләрләрчә елмаеп чыкты. Аның кулында сары төстәге 4 зур кап, 5 яшел, ә кесәсендә зәңгәр төстәге 13 кап шырпы иде».

*(М. Булгаков. «Искитмәле хәл». 1921 ел, 20 сентябрь.)*

* * *

«Сарафан радиосы» дигәннәре цехта күптәннән ишетелмәгән хәбәр таратты: узган елның декабре өчен хезмәт хакы бирәләр икән. 1998 елның көзе иде. Цехта тып-тын. Цех мастеры, элекке тормышта коммунистик хезмәт ударнигы булып йөргән Кәримов, тирә-якка карана-карана, һәм, «Алтын чәч» ариясеннән кайсыдыр өлешен борын эченнән генә көйли-көйли, завод идарәсенә юл алды. Очраганнарга горур гына сәлам бирде.

Менә рәшәткәле амбразура янына килеп җитте. Аның як-ягында камуфляж формасы кигән ике әзмәвер басып тора иде. Кулларында элекке тормышыбызда — социализмга юл күрсәтүче, ә хәзерге көнебездә «демократизатор» дип йөртелгән резин таяклар. Мастер аларга елмаеп сәлам бирде һәм, сүз арасында гына әйткәндәй, сорап куйды:

— Хезмәт хакы бирәләр дигән булалар...

— Бирәләр, бирәләр,— диделәр рәшәткә янында торучылар бик җитди генә. Камуфляж кигәннәрнең берсе ни сәбәптәндер «демократизатор»ы белән итек кунычына сугып куйды, ә икенчесе социализмга күрсәтүчесе белән амбразура өстенә ябыштырылган кәгазьгә төртте. «Хезмәт хакы шырпылата бирелә» дигән сүзләрне укыды Кәримов.

— Нишлисең бит, алырга туры килә инде,— дип мыгырдады Кәримов.— Ел буена берни дә алмаганчы, шырпылы булу хәерлерәктер. Может, сатармын да әле...

— Сатарсың, сатарсың,— дигән тавышы ишетелде кассирның.— Бәлки, тагын нинди дә булса навар ясарсың...

Шунда Кәримовның хәтеренә кинәттән генә бер карт яһүд сөйләгән мәзәк килеп төште. Имеш, яһүд пешкән йомыркалар сата икән. Икенче яһүд сорый моңардан: «Мойша, күпмедән сатасың йомырканы?» «Дистәсе ун сум». «Ә чиләрен күпмедән аласың?» «Уннан». «Аннан сиңа нәрсә кала соң?» «Беренчедән, мин һәрвакыт эштә, икенчедән, навар,— дип җавап бирә карт Мойша.

Кәримов амбразура аша өсләренә «Макарон» дип язылган зур-зур катыргы тартмаларны күреп алды.

— Бәлки, макарон белән бирерсең, ә? — Үтенечле караш ташлады ул кассирга.

— Юк! — диде кассир коры гына.— Производство ветераннарына гына макаронлата бирәбез. Ә сине, Кәримов, шырпы алучылар ведомостена язганнар.

— Һм,— дип уйлап куйды Кәримов.— Аларга шул токмач дигәннәре хәзер төшкә генә кирә.

Кәримов завод идарәсеннән алпан-тилпән чыгып китте. Аның кулларында һәм җилкәсендә шырпы белән тулы дүрт катыргы тартма иде. Бу минутларда аның инде бернинди арияне сызгырасы да, җырлыйсы да килми иде. Ул, телдән калган кеше кебек, ләм-мим бер сүз әйтмичә, күпмедер вакыт завод идарәсе каршында басып торды. Әйтерсең лә ул барыр юлыннан язган иде.

— Хезмәт хакы алдыңмы әллә? — Кемдер аның аркасына төртте. Артында күршесе Батыров басып тора иде. Аның да кулларында шырпы тулы тартмалар. Күршесенең ичмасам күңеле күтәренке иде.

— Син нәрсә? Еларга торган кеше шикелле. Шатланырга кирәк, әнә күпме алгансың. Киттек. Үземнең «копейка»да алып кайтам.

Башта «хезмәт хакы»н калдырырга дип, Батыровлар гаражына керделәр. Кәримов мондагы күренешне күреп гаҗәпкә калды. Гараж дигәннәре уртача бер предприятиенең склады зурлыгында иде. Шушында ук унитазлар, обойлар, кәнәфиләре белән диван, балалар караватлары.

— Гаилә зур бит,— дип акланырга кереште Батыров.— Туган-тумачалар да җитәрлек. Барысының да гаражы юк бит. Барысы да үзләренең «хезмәт хакларын» шушында китерәләр. Кайчан сатарлар менә. Сата алсалар әле...

Кәримов үзенең «хезмәт хакы»н өенә алып кайтып китте. Бөтенесе күрсеннәр. Гаилә подряды ысулы белән, бәлки, сатарга да мөмкин булыр.

— Ай Алла! — Каенанасы ботларына чабып куйды.— Кая куярга бу кадәр шырпыны?

— Хезмәт хакы ич! — Нindидер бер горурлык белән җавап бирде кияү һәм сату өчен җайлы булсын өчен төрле өемнәргә бүлеп куя башлады. Сынап карар өчен генә берсен сызып караган иде, янмый. Икенчесен сызды, шайтан, анысы да янмый. Өченчене, дүртенчене, бишенчене сызып карады... Юк инде. Шырпы кабының бер ягын мунчалага әйләндереп бетерде — хет нәрсә эшлә, юк. Ник берсе «безгә дип» карасын. Кыскасы, «җылы хезмәт хакы» да производствода эшләүче кече командирының өен җылытасы килмәде.

Шырпылар брак булып чыктылар.

Икенче көнне, озак уйлап тормыйча, Кәримов шырпылар тутырылган дүрт катыргы тартманы кирәдән заводка алып китте.

Овчарка кебек усал секретаршаны узып, бөтен тартмаларны да төп акционер кабинетына — генераль директорның үз янына тартып кертте. Һәм шырпыларны хезмәт хакын уйлап табучының үз өстенә сибә башлады.

— Мә, хәшәрәт, минем хезмәт хакымны да ал. Сиңа җитми бит...

Батыровның эше тагын да күңелсезрәк беткән икән. Аның шырпылары (ягъни, хезмәт хакы) үзләреннән үзләре кабынып китә торган булганнар икән. Төнлә алар үзләренең эшләү сыйфатларын күрсәткәннәр — гаиләсенең һәм туган-тумачаларының бөтен хезмәт хакы янып беткән.

Соңыннан завод комиссиясе ачыклады: Кәримовка брак партия эләккән, ә Батыровка экспортка дигәннәрен биреп җибәргәннәр.

Гауганы зурга җибәрмәс өчен, генераль директор-акционер янган һәм бракка чыгарылган хезмәт хакын акчага алыштырды.

— Алла бирсә, калганнарын да бирербез,— дип тынычландырды акционер завод кешеләрен.

*(Россия. 1998 ел, 20 сентябрь.)*

* * *

«Коротков чыкты һәм гаҗәпкә калды. Вакытыннан элек эшеннән кайткан Александра Федоровна, өс-башын салмаган килеш, идәндә чүгәләп утыра иде. Алдында газетадан ясалган бөке белән томаланган әллә никадәр шешә. Аларның һәркайсына кызгылт сыекча тутырылган. Александра Федоровнаның бите яшькә чыланган.

— Кырык алты,— диде ул һәм Коротковка таба борылды.

— Исәнмесез, Александра Федоровна, язу карасымы бу? — дип сорады күргәннәрдән таңга калган Коротков.

— Чиркәү шәрабы,— диде үксеп күршесе.

— Сезгә дә шуның беләнме? — дип сорады Коротков.

— Сезгә дә чиркәү шәрабымы? — дип гаҗәпләнде үз чиратында Александра Федоровна.

— Безгә — шырпы,— диде Коротков ишетелер-ишетелмәс тавыш белән һәм пиджагындагы төймәсен борып куйды».

*(М. Булгаков. «Искитмәле хәл». 1921 ел, 21 сентябрь.)*

* * *

Кичен, үзенең «копейка»сын көчкә-көчкә генә янган гараж-складына кертеп куйганнан соң, Батыров күршесе Добряков гаражына керде. Ул санитар носилкалары белән тулы иде.

— Әллә санитар булып сугышка җыенгансың инде?

— Менә хезмәт хакы алдым әле, шуларны өеп кую иде,— диде Добряков.— Ярты елга хатын белән икебезгә — ярты гараж носилка. «Син, Добряков, җитез кеше, ничек тә булса сатарсың әле» диделәр.

Добряков хатыны белән бик күп еллар медицина җиһазлары җитештерү заводында эшләде. Менә бәхет тә озак көттермәгән — никадәр носилка.

— Икенче ай сатам инде. Хәзерге көндә кемгә кирәк соң ул? Аның белән нәрсә ташыйсың? — ди еларга җитешеп Добряков.

— Мөселман җәмгыятьләренә мөрәҗәгать иткәнең булмадымы соң? Мөселманнарның мәетләрне табутсыз күмгәннәрен син белергә тиеш ич.

— Итмәгән кая инде,— ди Добряков кулын селтәп.— Берне алдылар. Бөтенесен алмаслар бит инде. Ул вакытта шәһәрдәге бөтен мөселманны берьюлы күмеп бетерергә туры килер иде.

— Анысы да дөрес,— дип килеште аның белән Батыров.

— Берсен менә «бакчага кирәк булып куюы бар» дип, сәеррәк кеше килеп алып китте. Бакчадан бәрәңге ташырга ярар шикелле, ди.

— Эв-ри-ка! — дип кычкырып җибәрде Батыров.— Башка менә дигән фикер килде әле. Әйдә, без синең белән Халыкара Кызыл Хач җәмгыятенә язабыз. Бөтенесен алып бетерәчәкләр. Ничек кенә алачаклар әле!

Фикер Добряковка ошады. Хәтта артыгы белән. Билгеле булганча, фикер өчен америка буржуиннары да түлиләр. Добряков та яшергән җиреннән бер «Столичный»ны тартып чыгарды. Кышка дип әзерләнгән бер банка тозлы кыярны да ачтылар. Кыярны шытырдата-шытырдата фикерне көчәйткәннән-көчәйтә бардылар.

Батыров белән Добряков, зур эш майтаргандай, өйләренә кайтып киттеләр. Кызыл Хач турындагы фикер аларның икесенә дә бик ошады. «Столичная»сы да начар түгел иде. Ирләр беравыздан дәртләнеп кычкырып җибәрделәр: «Карагыз әле, тормыш яхшыра бит, әй!»

*(Россия. 1998 ел, 21 сентябрь.)*

* * *

«Эш башкаручы бер күз белән генә пеләшнең язганнарын укып чыкты. Кәгазьдә кәкре-бөкре сүзләр сызгаланган иде: «Бөтен машинисткаларга һәм хатыннарга, гомумән, үз вакытында солдат кальсоннары биреләчәк».

— Менә бу шәп ичмасам! — дип, шатланып кычкырып җибәрде Коротков һәм Лидочкасын солдат кальсонында күзаллап, шатлыгыннан дерелдәп куйды. Тиз арада кәгазь кисәге тартып чыгарды һәм өч минут эчендә хәбәрен дә язды:

«*Телеграмма*.

Комплектлаштыру бүлекчәсе мөдиренә нокта. Сезнең 19 числодагы 0,15015(6) санлы мөрәҗәгатегезгә җавап итеп, өтер, Главспимат бөтен машинистларга һәм хатыннарга үз вакытында солдат кальсоннары биреләчәге турында хәбәр итә нокта. Мөдир тире имза эш башкаручы тире Варфоломей Коротков нокта».

*(М. Булгаков. «Искитмәле хәл». 1921 ел, 21 сентябрь.)*

* * *

Кәримовның энекәше, шулай булгач, ул да Кәримов инде, институтны тәмамлаганнан соң, Волгоградка тегү фабрикасына инженер-технолог итеп җибәрелгән иде. Безнең Чубайс чорында аны акционерлаштырдылар һәм кыска, кызыклы, шул ук вакытта матур да итеп, «Армина» АҖ дип атадылар.

Ләкин аның ямьле урыннары соңыннанрак күренә башлады.

Күпмедер вакыттан соң Кәримовка хезмәт хакын фабрика продукциясе — бюстгальтерлар белән бирә башладылар. Кече Кәримовның хезмәт хакы югары — 180 сум. Номинациягә кадәр әле тагын дүрт ноль өстәлгән иде. Бер сүз белән генә әйткәндә, миллионер иде. Менә берничә айлар инде бу миллионер өенә даими рәвештә ун бюстгальтер алып кайта.

Сүз дә юк, хуҗалыкта ул бик кирәкле әйбер, аннан башка мөмкин түгел. Ир-атка кая куеп бетерергә соң шулкадәр бюстгальтерны?

Шуның өстенә соңгы ике айда иң зурларын — алтылыларын бирә башладылар. Ә аның хатыны икенчене кия. Берзаман кунакка абыйсы килде һәм фатирдагы бюстгальтерларны күреп шаккатты. Өлкәннәр, гомумән, белебрәк эш итүчән булалар. Абыйсы энекәшенә бик тә гади, ләкин бик тә гениаль фикер әйтте:

— Син, энекәшем, алардан яңа туган балалар һәм карчыклар өчен чепчикләр, мөселманнар өчен түбәтәйләр тек. Үзең беләсең, Волгоград — туристлар Мәккәсе. Шундук алып бетерәчәкләр.

Абый белән энемнең хатыннары ике көн эчендә ярты елда җыелган бюстгальтерларның профилен үзгәрттеләр дә бетерделәр. Менә дигән челтәрле чепчикләр, кырыйлары тасмалы бик матур түбәтәйләр барлыкка килде.

Кечесе, инженер Кәримов, бер түбәтәйне үрнәк өчен башына киде дә данлыклы Волгоград елга порты янына барып басты.

Менә өч палубалы гүзәл теплоход килеп туктады. Порт мәйданы төрле телдә сөйләшүче чит ил кешеләре белән тулды. «Кәримов һәм К» фирмасы продукциясе дә бер минут дигәндә сатылып бетте.

Бара-тора кече Кәримов бюстгальтерларны, иптәшләреннән очсызгарак алып, үзгәртеп тегеп сата башлады. Шулай итеп, боз кузгалды. Менә бит абый кешенең вакытында килеп, файдалы киңәш бирүе ни тора».

*(Россия. 1998 ел, 22 сентябрь.)*

* * *

«Аның күз алдында яньчек һәм кечкенә булып күренгән өй түбәләре, трамвайлар сөйрәлеп йөргән һәм коңгыз шикелле генә булып күренгән кешеләр йөргән мәйдан ачылды, тыкрыктан подъездга таба йөгерүче соры фигуралар, алар артыннан алтындай ялтырап торган торбалы зур уенчык пәйда булды.

— Чолганышта калдык! — диде Коротков уфтанып.— Янгын сүндерүчеләр».

*(М. Булгаков. «Искитмәле хәл». 1921 ел, 23 сентябрь.)*

* * *

Тугыз катлы йорт төзелешендә төшке аш төгәлләнде. Ташчылар, монтажчылар, эретеп ябыштыручылар кранчы Дания Кашапованың кулына плакат тотып, бик ыспай гына, алай гына да түгел, кыргаяк сымак кран угы буйлап үрмәләвен куркып та, гаҗәпсенеп тә карап тордылар. Дания кранның горизонталь хәлгә куелган ук очына барып җиткәч, плакатны ачып җибәрде: «Ярты еллык хезмәт хакымны шушында менгерми торып, төшмим!»

Прораб Никишин чүпкә баткан баскыч буйлап тиз генә тугызынчы катка күтәрелде. Төзелеш әлегә шунда тукталган иде.

— Дания, шаярма! Тиз төшкән бул! — Яхшырак ишетелсен диптер инде, Никишин кулларын рупор ясап авызына куеп кычкырды.

— Көтеп торыгыз! Ярты ел өчен өч «лимон»ны менә шушында менгезегез, аннары төшәрмен.

Никишин үзенең прораб вагонындагы рациягә йөгерде. Дания металл укка яткан хәлдә биектән түбәндә барган ситуацияне күзәтә. Кем әйтмешли, югарыдан күренә төшә бит. Башта аңа хәтта көлке дә булып тоелды. Кешеләр юан лилипутлар кебек күренделәр, тараканнар шикелле арлы-бирле йөриләр шунда.

Прорабның ук астына килеп туктаган «техпомощь» йөк машинасыннан аның ире Кашапов чыкты. Аның артыннан соңгы модельле «Волга» килеп җитте. Аннан төзелеш идарәсе башлыгы, баш бухгалтер, Кашаповларның ике баласы — унике яшьлек уллары һәм җиде яшьлек кызлары чыкты.

«Менә бит, хәшәрәтләр, беләләр ничек тәэсир итәргә кирәклеген»,— дип уйлап алды Дания. Чыннан да, балалар шунда ук кычкырышырга, елашырга тотындылар: «Әни, әни, төш, төш инде...» Ире, югарыга карап, нәрсәдер уйлый иде бугай.

— Дания, ташла халыкны болгатуыңны. Төш! — Идарә башлыгының мегафоннан кычкыруы әллә кайларга яңгырый.

— Хезмәт хакын бирегез! — Монысы инде начальство колагына тонык кына булып килеп керә.

Милициянең «УАЗ»игы белән озын баскычлы янгын сүндерүчеләр машинасы килеп җитте. Җыелган халыкны күрсәң, гаҗәпкә калырсың — Мәскәүнең Кызыл мәйданында Ильич мавзолеендагы каравылны алыштырганны карарга килгән халык кадәр. Күзләрен югарыга текәгәннәр дә үзара фикер алышалар. «Егылып төшәрме? Юкмы?»

Сабан туе мәйданына чыккан батыр сымак, ук турысына кулына пакет тотып, зур гәүдәле бухгалтер чыкты.

— Дания,— ди ул, үзенә генә хас бер тавыш белән кычкырып,— менә кара, алты айлык хезмәт хакыңны синең ireңә — Кашапчикка тапшырабыз.

Ук астындагы мәйданда көчле кул чабулар, «ур-ра» авазлары яңгырый. «Акча бирәләр икән» дигәннәре дә ишетелеп тора. Шул арада бухгалтер ханым Кашаповка акча санап бирә. Төзелеш идарәсе башлыгы:

— Әйт инде хатыныңа, төшсен, акчаны тулысынча бирдек бит...— ди.

— Пес итәсе килсә, үзе дә төшә ул,— диде Кашапов һәм хатынының эш хакын кесәсенә салып, төзелеш мәйданыннан читкә китеп барды. Ә Кашаповның балалары «әни, әни» дип, һаман такмаклап елыйлар иде.

Ә төзелеш идарәсе башлыгы һаман кычкыра, сүгенүен дәвам итә:

— Ни пычагыма ятасың анда, шулай иткере, төш давай!

— Булдыра алмыйм, куркам,— дигән сүзләр ишетелә күк йөзеннән.

Янгын сүндерүчеләр чыгармалы баскычларын урнаштыра башладылар. Ләкин ул биш кат биеклегендә туктап калды. Янгын сүндерүчеләрнең икенче машинасын көтә башладылар. Ләкин Даниянең түземлеге беткән иде инде. Әллә куркудан, әллә чыннан да терәлгән булган, стрела астында авыз ачып торучыларның өстенә җылы яңгыр ява башлады. Кайдан икәне билгеле иде инде. Идарә начальнигына кранчыларны памперслар белән тәэмин итәргә кирәк икән дигән уй килде.

Янгын сүндерүчеләр Данияне җиде кат күктән алганда, йөзе ап-ак иде. Шатланганлыгы барыбер күренеп тора иде.

— Хезмәт хакыңны ireңә бирдек бит. Нишләп төшми тордың? Төшәсең килмәдемени? — дип сорады идарә начальнигы, мәсьәләгә ачыклык кертәсе килеп.

— Анда мин ачудан мендем, куркуның әсәре дә булмады,— диде кыю кранчы, үзенең иң зур начальнигына интервью биргән сымак.— Эш хакын биргәнне күргәч, усаллык югалды, курку барлыкка килде. Әгәр ышанмасагыз, үзегез шулай эшләп карагыз.

— Мин нәрсә, стрелага менәргә, әллә...— диде башлык гарьләнеп.

— Ул үзе акчасын вакытында алып бара, нәрсәгә аңа стрелага менәргә? — Ир-атлар, шулай диядия, мәйданнан таралыша башладылар.

Әйе, һәркемнең үз кайгысы. Кем әйтмешли, ярлының ашы сыек, байның энҗесе кечкенә.

*(Россия. 1998 ел, 23 сентябрь.)*

* * *

«Шул ук минутта кабинетка кулына портфель тоткан аксыл йөзле егет килеп керде. Көлүдән шул мәлдә үк Дыркинның битендә җыерчыклар барлыкка килде.

— Ә-ә! — дип кычкырып җибәрде ул төчеләнеп.— Артур Артурыч. Бездән сезгә...

— Тыңла, Дыркин,— диде үсмер, үткен тавыш белән,— син Пузыревка язгансың, янәсе, мин эмеритур кассада үземнең диктатураны урнаштырганмын һәм май акчасын сыптырганмын. Синме? Җавап бир, хәшәрәт...»

*(М.Булгаков. «Искитмәле хәл». 24 сентябрь, 1921 ел.)*

* * *

Ремонт-төзелеш участогы буяучысы Катя Батырова «Океан» радиоалгычын чиләккә салды да, чыбык очларын яшереп, чиләкне буяуга каткан чүпрәк белән бәйләп, завод идарәсенә китте. Завод директорының, ягъни мәсәлән, акционерлык җәмгыяте генераль директорының «Джип-Черокки»га утырып китүен көтеп, бер кулына чиләк, икенчесенә зур гына пумала тотып, Папаның (хуҗаны шулай дип атыйлар иде) кабул итү бүлмәсенә керде.

— Мине участок начальнигы Папаның бүлмәсендә плинтусларны буярга җибәрде,— диде ул кабул итү бүлмәсендә буянып-сөртенеп утыручы мини күлмәкле секретарь кызга.

— Рәхим ит,— диде тыныч кына «мини юбка» һәм башта бер ишекне, аннан икенчесен ачты. Аннары әледән-әле шалтырап торучы телефоннары янына ашыкты.

Катя, бу гаять зур вокзал-кабинетка беренче тапкыр кергәндә, аптырап, гаҗәпләнеп калды. Ул каяндыр күктән килеп төшкән сымак тоелды. Мондагы ялтыравыклы кабинет мебелен, төрле-төрле телефоннарны, хрусталь савытларны, түшәмдәге люстраны күреп, чак кына һушыннан язмады.

Бишенче разрядлы буяучы Катя бик тиз аңына килде һәм югары сыйфатлы күннән эшләнгән кәнәфидән урын алды. Чиләген директорның шомартып ялтыратылган өстәленә куйды. Чакыру кнопкасын эзли башлады Ләкин ул юк иде. Кайсы телефоннан ничек кая шалтыратасын Катя белми иде. Ул итек олтаны белән әледән-әле идәнне ышкыды, буяуга каткан куллары белән нидер эзләде. Ниһаять, өстәл кырыенда нindидер түгәрәк нәрсә күзенә чалынды. Ул аңа берничә тапкыр нык кына басты. Сынып төшәргә торган керфекләрен шыпылдата-шыпылдата секретарь йөгереп керде һәм ни әйтергә белми, бишенче разрядлы буяучы Катяга аптырап карап тора башлады.

— Миңа, директора давай! Бик тиз! — дип әмер бирде Екатерина.— Югыйсә бөтенләйгә юкка чыгарам гарипләр йортыгызны.— Шуны раслагандай, ул чиләктән чыгып торучы чыбыкларны селкеткәләде.

Секретарь бүлмәдән ук кебек атылып чыгып китте. Папаның зур бүлмәсендә тагын сәер тынлык урнашты.

Ун минутлардан соң кырый өстәлдәге телефоннарның әле берсе, әле икенчесе шалтырый башлады. Екатерина аларның тавышын бермәл өйрәнеп утырды. Аннары бер трубканы күтәрде.

— Але,— дигән таныш тавыш ишетелде трубкада. Бу Катяның производстводагы турыдан-туры җитәкчесе — ремонт-төзелеш участогы начальнигы иде.— Син нәрсә эшлисең анда, шалюга? Сине кем җибәрде анда? Мин синнән сорыйм.— Каян килгән циркач диген?!

— Әйтер идем инде мин сиңа кая китәргә кирәген... Син үзең циркач. Директорны җибәрегез минем янга, тиз генә. Генеральныйны.— Батырова кискен генә итеп шулай әйтте дә трубканы урынына бәрде.

Папа кая йөргәндер, билгесез. Ләкин ярты сәгатьләрдән ул, тыны кысылып, шампан бөкеседәй атылып, үзенең вокзал хәтле кабинетына килеп керде һәм иң яраткан күн кәнәфиендә пычрак спецовкада кулына ике чыбык очы тоткан хатынны күрде.

— Баскан җиреңдә тик тор! — дип кычкырды бишенче разрядлы буяучы.— Тик тор, дим, кузгалма! Безнең участокның ярты еллык хезмәт хакыннан кайда навар ясадыгыз? Уйларга бер сәгать вакыт бирәм. Яки сез ярты елга участокка тиешле акчаны китерәсез яки мин сезнең деловар конторагызны шартлатам.

— Ярар, эшләрбез! — диде Папа-деловар.— Хәзер эшләрбез, хәзер...— Ул маңгаена чыккан тир бөртекләрен яулыгы белән сөртеп алды.

Екатерина күтәрелеп тәрәзәдән карады. Анда төрле якка пальтоларын төймәле-төймәле контор кешеләре йөгерәләр иде. «Шартлаталар» дигән сүзләр хәтта Катя утыра торган кабинетка кадәр ишетелде.

Директор сүзендә торды. Бер сәгатьләр чамасы үткәч, кайсысыныңдыр калтыраулы кулы Катя кабинетына зур гына брезент капчык ыргытты. Бишенче разрядлы маляр капчыктагы купюраларны директорның ялтыравыклы өстәле өстенә бушатты. Янында ремонт-төзелеш участогы эшчеләренең фамилияләре язылган ведомость ята иде.

Батырова тагын каты итеп кнопкага басты. Папа-деловар йөгереп-керде.

— Басып тор! — дип кычкырды аңа Катя каты итеп.— Бүген деловарларга имтихан. Берәм-берәм бирегә минем участокның эшчеләрен кертегез.

— Хәзер була,— диде ул, бу юлы авыз эченнән генә мыгырданып, һәм күз-кабакларын сикертә-сикертә чыгып китте.

Бер сәгатьтән иң соңгы кеше булып Катяның начальнигы ведомостька кул куйды һәм пышылдап кына:

— Молодчина, Катюша, югыйсә гомер буе акча күрәсе юк иде,— диде.

Екатерина производство мәйданына чыкканда, аны участок эшчеләре көтеп тора иде. Арырак милициянең мигалкалы «бобиг»ы басып тора иде.

— Алай, директорның эше авыр икән,— диде бишенче разрядлы буяучы «бобик»ка утырганда.— Директорлык итү эше буяучы эше түгел.

*(Россия, 1998 ел. 24 сентябрь.)*

* * *

«Йозак колагында язу эленеп тора иде. Коротков эңгер-меңгердә укыды аны.

*«Хөрмәтле күрше!*

*Мин әни янына Звенигородка китәм. Сезгә бүләк итеп шәраб калдырам. Кинәнеп эчегез — аны барыбер берәүнең дә аласы килми. Шунда почмакта ул. Сезнең А.Пайкова».*

Цилиндр һәм канделябрны әйләнеп, Коротков галәмәт зур ишекләрдә урамга килеп чыкты, кызган һаваны авыз тутырып сулап, урам буйлап йөгерде. Ак әтәч сасы ис калдырып җир астына төшеп китте, ә кара пальто итәге, һава белән үрелеп, Коротков белән бергә сөйрәлде һәм нечкә озын тавыш белән кычкырды:

— Иптәш, артельщикларны кыйныйлар!»

*(М. Булгаков. «Искитмәле хәл». 1921 ел, 25 сентябрь.)*

* * *

Механика заводы эшчеләренә эш хакын бартерга алынган тавык йомыркалары исәбенә бирә башладылар. Токарьлар, слесарьлар, эретеп ябыштыручылар, инженерлар, контор «деловар»лары үзләренең буш көннәрендә, ә андый көннәре аларның атнага дүрт көнгә кадәр җыела иде, бөтен шәһәрне тавык йомыркасы белән тутырдылар. Алар кибет тирәләрендә, автобус тукталышларында көннәр буе басып тордылар, фатирлар буйлап йөрделәр. Механика заводы шәһәр халкын тавык йомыркасы белән шулкадәр туендырды ки, һәркемгә әтәч булып кычкырырга гына калды. Шулай итеп, механика заводының профильле булмаган продукциясе дә үтми башлады.

Кәримовның заводта фрезеровщица булып эшләүче өлкән кызы Сания чираттагы хезмәт хакына ике зур чиләккә тутырып ап-ак йомыркалар алды. Ике чиләген кулына тоткан килеш, завод конторы янында торучы директор «Мерседес»ы янына килде. Бер чиләк йомырканы немецларның гаҗәп оста ясалган әкәмәт машинаның бер ягына һәм пыялаларына сугып ватты.

Икенче чиләге белән ул секретарша яныннан шома гына үтеп, йомыркаларны директорга җибәрә башлады. Лайлалы масса гендиректорның бите, костюмы буйлап акты. Гомумән, директорның йомырка сыекчасы тимәгән бер җире дә калмады.

Кәримовның кече кызы, усалланып, ләкин заводның ял базасындагы тирда аткандай бик төз җибәрде йомыркаларны. Гендиректор, бу һөҗүмгә түзә алмыйча, үзенең алагаем зур өстәле артына кача башлады. Шуннан соң йомыркалар директор артындагы стенада гомер-гомердән эленеп торган Ленин портретына очтылар. Дөресрәге, фрезеровщица хәзер йомырка-«снаряд»ларны ике юнәлештә җибәрә — Ильичның башындагы пеләшенә, өстәл артыннан ара-тирә күренеп алган гендиректор маңгаена.

Гендиректор чыдамады, өстәл артыннан:

— Каравыл, ка-ра-выл! — дип кычкырды.

— Ах, сез, «деловар»лар, безнең исәпкә акча ясыйсыз, безгә иписез йомырка ашатасыз, мә! — Сания, директорның башын чыгарганын көтеп, тегенең уң күзенә төбәп, тагын бер йомырка җибәрде.

Тавышка секретарша йөгереп керде һәм:

— Әфәнделәр, акционерларны кыйныйлар,— дип кычкырды.

Берничә йомырка тегенең «а ля Скоуфорд»дип ясалган чәченә дә эләкте. Секретарша, елан чаккандай кычкырып, бүлмәдән чыгып тайды.

Контордагы акционерлар кабинетка кергәндә, Саниянең эше беткән иде инде. Ильич портретыннан аксыл-сары лайлалы масса ага иде. Кабинеттагы зур өстәл артыннан шешенгән фараонны хәтерләтеп, Сания Кәримованың эш хакына буялган мөхтәрәм гендиректор күтәрелә иде.

— Йөзеп килеп җиттек.— Гендиректор үзен гаепле сизептерме, юләрләрчә елмаеп әнә шулай диде.— Репинның картинасы шулай дип атала.

— Әһ-е, килеп җиттек! — дип, атучы-фрезеровщица, усал теллеләнеп, аның сүзен җөпләде һәм, буш чиләкләрен шалтырата-шалтырата, бик горур рәвештә чыгу юлына атлады. Артына борылып өстәп куюны кирәк тапты:

— Йомырка салучы «деловар»лар...

— Монда Ильичның нинди гаебе бар инде? — дип сорап куйды конторда эшләүче хатыннарның берсе.— Изгеләргә хәтле, Владимир Ильич Ленинга хәтле барып җиттеләр люмпень-пролетариатлар.

— Чыннан да, изге Ленинның монда ни катнашы бар инде? — дип, кабинет хуҗасы да аның сүзен куәтләде, инглизләр теккән затлы һәм йомыркага буялып беткән пиджагын сала-сала.

*(Россия. 1998 ел, 26 декабрь.)*

***Соңгы сүз***

Волгоград мачталар җитештерү заводы директоры өчен хезмәт хакы алмаудан ачуы чыккан эшчеләр белән очрашу гадәти булмаган травма белән тәмамланган.

Байтак кына ачуланышканнан соң, предприятие директоры кабинетыннан чыгып китү максаты белән ишеккә юнәлгән. Завод ветераны, пенсионерка Анна Николаева аның юлына аркылы төшә. Элеккеге эшче 1995 елдан бирле үзенең бер миллион сигез йөз мең сум акчасын (иске акча белән) ала алмый икән. Директор ачуы чыккан хатынны читкә этәрмәкче була, мөгаен, тегесенең нервысы чыдамый, тешләре белән җитәкченең кулына ябыша.

# Базар, командир, базар!

Бөтен үскән әйберне
кыркып бетермә...

*Козьма Прутков*

Көтмәгәндә уйламаганда, радикулит билгә китереп бәрде бит әле, җәмәгать! Табиб билдән түбән йомшак җиргә укол кадарга дигән кәгазь язып бирде. Шунысы яман, ничек инде тимер лом йоткан кебек бөтен шәһәр аркылы сырхауханәгә укол кадатырга йөрисең ди.

Минем бәхеткә, күршем Мөршидә шәфкать туташы булып шифаханәдә эшли. Шуңа мөрәҗәгать итәргә уйладым.

Иртән кадый Мөршидә, кичен кадый. Тишексез урыннар калмады, ахры. Бишенче көнне шәфкать туташым майлы күзләрен бер ачып, бер йомып, болай ди:

— Синнән ике йөз сум, күршекәем.

— Аңламадым,— дидем мин тилегә сабышып.— Кабатлачы тагын...

— Кара әле, бөтенләй томана булып кылана,— дип мыскыллап көлә Мөршидә.— Мәрхәмәтлек, рәхимлек чорлары үтеп китте шул, абзыкай. Һәрбер уколны кадау егерме сум тора. Димәк, ун укол — ике йөз сум. Базар, күршекәем, базар. Урысча әйткәндә, рыночные отношения...

«Ну, б... бәгърем»,— дигән сүзләр электр тогы бәргәндәй баш аркылы чыгып киттеләр. Шул арада бу токның укларын күршемә юнәлтәм:

— Рынок, базар, дисеңме? Алайсам, синнән өч йөз сум инде. Йөз сум сдача бир.

— Нинди сдача тагын? — ди Мөршидә, күзләрен дүрт итеп.

— Телефон өчен, җаным-бәгърем. Телефон өчен. Син бит аз дигәндә көнгә өч тапкыр телефоннан шалтыратырга безгә йөрисең. Әле мин сиңа соңгы өч айныкын гына чутладым. Теге үткән елларныкын төзеп бетерә алмаган коммунизм чыгымнарына калдырам.

— Ну ты даешь! Ну ты даешь,— ди күршекәем, аклы-күкле килеп. Һәм куллары белән саубуллашкан кыяфәт чыгарып ишектән чыгып тайды.

— Базар, Мөршидә! — димен туташ артыннан.— Рынок, күршекәем. Рынок... Нигә миннән качасың? Бөтен подъездга телефон бит миндә генә. Барыбер безгә керәчәксең.

Юк. Мөршидә бүтән безгә кермәде. Көннәрдән бер көнне балконда вак-төяк эш белән мәш киләм. Подъезд төбендәге утыргычны мин «диспетчерская» дип йөртәм. Шунда өч пенсионер һәм бер алкаш җыелганнар да «разборка» ясап маташалар: кемнәргә кем килгән, кем нәрсә алып кайткан, кемнең фатирыннан нинди ис килә, кем нәрсә пешерә. Кыскасы, чәйниләр һәммәсен. Көтмәгәндә, йорт башыннан йөгерә-йөгерә Мөршидә килеп чыкты.

— Кая бара безнең күрше ашыга-кабалана? — диләр «диспетчер» әбиләр, Мөршидәгә карап.

— Менә телефон-автоматтан шалтыратырга барган идем,— дип зарлана башлады Мөршидә һәм минем балконга бармагын төбәп дәвам итә: — Телефон өчен теге комсызга биргәнче, лутчы автомат йотсын акчаларымны. Каян килгән «новый русский татарин».

Соңгы вакытта икенче күршебез — Хөршидәләргә кереп чыгарга туры килде. Бераз бурычка акча алган идем. Телевизор сатып алганда җитмәгән иде.

— Рәхмәт инде, Хөршидәкәем,— димен.— Менә әҗәтемне керттем. Тиенен тиененәчә...

Хөршидә бөтен биргән әҗәт акчаларымны ашыкмыйча гына санап чыкты да миңа усал карашын юнәлтте:

— Җитми бит, күрше...

— Бик әйбәтләп санаган идем инде,— димен кыенсынып кына.

— Ә процентлар? Айга унбиш процент. Мин бит инде болай да үзәк банк процентыннан азрак чутлыйм,— диеп, миңа күрше ханым лекция укый һәм азаккы сүзе белән нокта куя.— Базар, күрше, рынок дип атала ул.

Нишлисең инде, базар кагыйдәләре каты. Процентлар белән түләргә туры килде. Ләкин бит тормыш дигәнең кызык нәрсә. Кичен хатыным белән телевизор карап утырабыз. Көтмәгәндә ишек кыңгыравы чылтырап куймасынмы? Карасам, ишек төбендә стакан тотып ут күршем Хөршидә басып тора.

— Менә ай чамасы элек сездән бер стакан кер юа торган порошок алып торган идем. Гөнаһысы булмасын дип, әҗәтемне керттем... Ярты стакан. Рәхмәтчик инде. Спасибецо дип атала.

— Ничек инде? Син бит тулы стакан алган идең,— ди минем хатыным аптырап.

— Соң, бу бит «Ариэль»,— ди Хөршидә, күзен биш итеп. Үзе теге телевизордагы рекламада чыга торган Эмма Петровнага охшап куйды.

Нишлисең, бу хәлгә миңа да тыгылырга туры килде:

— Ул Эмма Петровнаныкы гына кер юарга ярты норма җитә. Яле, тиз генә тулы стакан итеп алып кер! Һәм процентын да онытма...

— Хәзер! — диде дә Хөршидә һәм пуля сыман ишектән очты.

Әй ли, Хөршидә,
Һәй ли, Мөршидә,
Кызлар тора күршедә,—

дип, бер куплет җыр да җырлап бетерә алмадым, кулына порошок белән тулган ярты литрлы банка тотып, фатирга, уктай атылып, Хөршидә килеп керде:

— Җитәме?

— Менә хәзер булды,— димен мин.— Процентлары белән.— Хөршидәне озата-озата, тегеңә кыскача гына юл догасы укыйм: — Гаеп итмә инде, Хөршидәкәй. Базар бит, күршекәем. Рыночные отношения дип атала...

Базар, егетләр! Рынок, иптәшләр! Шушы арада бераз сырхау сукты. Кибеткә ипигә барып килергә дә хәл юк. Балконнан күршеләрнең бишенче сыйныфта укучы Равил исемле малаен күреп алдым да:

— Әй, Равильчик, улым! — дип кычкырам балконнан.— Зинһар өчен, кибеттән ипи генә алып кайт әле.— Аңа пакет эченә акча тыгып балконнан ыргытам.

— Айн момент,— ди Равильчик һәм ук кебек ишегалдыннан чыгып атыла.

Бу егетнең намуслы, тәүфыйклы булып үсүе хакында уйлап та өлгерә алмадым, Равильчик, култык астына пакет кыстырып, минем ишек төбендә басып тора.

— Бер рубчикны үземә калдырдым,— ди күзләрен ялт-йолт итеп.— Хезмәтем өчен. Рынок, командир! Рынок...

— Синең рәхимлелек, шәфкатьлелек дигән сүзләрне ишеткәнең юкмыни,— димен бу булачак эшмәкәргә.

— Әй, бабай,— ди бу кулларын уа-уа.— Тимуровецлар Аркадий Гайдар исемле язучы уйлап чыгарган әкияттә генә бит алар. Без икенче Гайдардан, аның оныгы Егорушка малайлары. Тимуровецлар түгел без. Тимурчиклар! Тамерланчиклар, командир. Базар, бабай! Рынок называется.

«Тукта әле, эләгерсең син, тамерланчик-тимурчик,— дип озаттым мин Равильчикны.— Исеңә төшерермен әле мин сиңа рынок-базарны».

Чыннан да, ике-өч көннән соң гаражымда вак-төяк эшләр белән шөгыльләнеп маташканда, яныма Равил килеп туктады.

— Чаво-то алгы тәгәрмәчнең рәте юк. Бәлки, карарсың, командир?..

— Әлбәттә, әлбәттә,— димен,— нинди проблема булырга мөмкин. Салдыр тәгәрмәчеңне.

Самокатын җайладым, көйләдем дә һәм... гаражның арткы почмагына кертеп куйдым.

— Синнән ун сум, тимурчик-тамерланчик,— димен Равилгә.— Базар, командир! Рынок дип атала, шеф.

— Ну ты даешь, бабай! Кармакка эләктердең. Молодчина,— ди яшь эшмәкәр, озын керфекләрен селкетә-селкетә.— Әгәр дә син теге үлгән социализмны яклаган булсаң, бер тиен дә бирмәс идем. Баш миләрең бераз хәрәкәттә булган өчен, сиңа ун сум кызганыч түгел инде.— Әнә шундый лекция укыйукый, әллә кайдан, ерактан, күлмәк эченнән ун сум тартып чыгарды да шап итеп минем уч төбенә салды егеткәем.

Менә шундый хәлләр. Базар көннәре, иптәшләр. Рыночные отношения дип атала…

## Эчтәлек

Каләм очында — халык язмышы. *Госман Садә* ..

**Повестьлар**

Хуш, Агыйдел! ...................
Калаларда таш казарма... ............

**Хикәяләр**

Алимент ......................
Бер алдашкач... .................
Өй алдында шомыртым ла... ...........
Зифаның алтын бармаклары ...........
Дустым Газинур ..................
Васыять .......................
Ишан хәзрәт наратлыгы ..............
Вакытлы качаклар .................
Татар язмышы ...................
Әмма аерылышу бик яман... ...........
Ак пароходларга утырып... ...........
Әмирлекләрдәге очрашулар ............
Менә сиңа кодагый! ................

**Юмористик хикәяләр**

Биш бегемот ....................
Ике якка да выжт… ................
Актанышта — метро ................
Әтәчләрне өйләндерәбез… ............
Йә, хуш! .......................
Күркәләргә дан! ..................
Тай моннан, бабай! .................
Бүгенге һәм кичәге иблисләр ...........
Базар, командир, базар! ..............

Заказное издание

*Шафиков Ягсуф Долмоганович*

**КАМЕННЫЕ ТЕМНИЦЫ**

*Повести, рассказы, юморески*

(на татарском языке)

Мөхәррире *Ф.М.Хафизов*
Рәссамы *Р.Г.Шәмсетдинов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *А.С.Газизҗанова*
Корректоры *Г.М.Хәбибуллина*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 26.02.2004. Форматы 84x108 $^1/_{32}$. Офсет кәгазе. «Kudriashov» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 10,92 + рәс. 0,84 + форз. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 15,54. Нәшер-хисап табагы 12,37 + рәс. 1,05 + форз. 0,36. Тиражы 1000 экз. Заказ Э-130.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
**http://www.tatarstan.ru/books/ E-mail: tki@books.kazan.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе. 420066. Казан, Декабристлар ур., 2.